**Кадыйр СИБГАТУЛЛИН**

# БЕР НОКТАДА

*Шигырьләр, поэмалар, баллада*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
С38

**Сибгатуллин К.И.**

Бер ноктада: шигырьләр, поэмалар, баллада. / Кадыйр Сибгатуллин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.— 560 б.— 2000 д.— ISBN 978-5-298-01518-9

Арабыздан иртәрәк киткән күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның бу җыентыгына төрле елларда иҗат ителгән әсәрләре урын алды.

ISBN 978-5-298-01518-9
© Татарстан китап нәшрияты, 2007

## «ӘМАНӘТ» китабыннан

(1963 — 1971)

*Күңел тулса тулсын,*
*мөлдерәп торсын.*
*Тамчысына кадәр кадерле.*
*Без — табигать таҗы,*
*бөре чыга,*
*чәчәк чыга*
*тишеп бәгырьне!*

### Әманәт

Тормыш, безгә язмыш-юллар юрама.
Нишлисең, дип сорама син, сорама.
Килү әле, син каршыла гадәти,
вакыт әйтер: көчебез ни, халәт ни.

Бизмәннәргә салып бәя итмәгез,
бәяләнми торган заттан икән без.
Җир-анадан гомер алган, җан алган,
заманына зарур булып яралган.

Бирелгәне бирелгәндер хаҗәткә,
барысын да алып торган әҗәткә.
Сарыф итсәк — ничәнче кат Җир әрнер,—
яшәү дә бер, гомер дә бер, без дә бер.

Туу белән әйткән булыр Җир-ана:
«Менә тагын юлга чыга бер бала.
Туры гына, тугры гына атласын,
кеше исемен эше белән акласын».

Адарындык инде гомер итәргә,
Җир-ананың әманәтен үтәргә.
Суык таштан кояш ясый алмасак,
без үткәндә үлән шытып калмаса,

йөрәктәге йөрәкләргә күчмәсә,
безнең сүздән кеше рухы үсмәсә,

бәхет теләп текәлмәсә кешеләр,
яшәде дип, безнең хакта кем сөйләр!

Йөрәк җитеп чыктык әле юлларга,
Җир-ананың әманәте уйларда.
Кабул иттек әле менә әзерне,
Җиргә булсын гомерләрнең әҗере!

1970

## Ике сүз

Шатлык сүзен кат-кат әйтәм бугай,
хәсрәт сүзен телгә еш алам.
Гаепләмә, дөнья,
урталыкта
бәрелә-сугыла үсте бу балаң.

Шуңа күрә җаным мескен түгел,
икесен дә татып чыныккан.
...Туңган мәче,
эт баласы күрсәм,
изүемә алып җылытам.

Елар чаклар, бәлки, булыр әле,
елак итә күрмә гомергә.
Көлеп кенә йөрүләре рәхәт,
кеше елаганда көлдермә!

Гаепләмә күңел нечкәлектә,
синнән җыйган, дөнья, барысын.
Мирас итеп бирдең Җиребезнең
шатлыклары белән сагышын.

Җир бәхеткә чумса,
бу сүзләрем
чүп-чар булып бетсен сибелеп.
Мең шатлыктан,
мең хәсрәттән туа
тары бөртегедәй игелек!

Кайгылары бәгырьләргә сеңгән,
шатлык сүзен телгә еш алам.
Хәсрәтләре аз булса да җитә,
шатлыкларга мохтаҗ бу балаң!

1970

## Кырларым күмелгән рәшәгә

Тәпигә басарга тырышып,
без монда камылга ябышкан.
Буыннар ныклыгы,
тазалык —
учларда уылган арыштан.

Иркәләп күтәреп йөртмәде,
ят итеп артка да типмәде.
Ачлыктан шиңәсе идек без,
яшәтте туган як икмәге.

Телләргә гүзәл җыр салынган,

асыл моң сеңгән бу якларга.
Иң гади,
иң бөек сүзләрне
без монда өйрәндек ятларга.

Дулкынга ташланган кызлар күк,
кырларым күмелгән рәшәгә.
Җырчы да,
шагыйрь дә булма, ди,
монда ту,
монда үс,
яшә дә!

1971

## Эзләмәгез әллә кайлардан

Ямь беткәнен тоеп бар да китте;
сандугач та качты таллардан.
Сагышыннан сары яфрак кына
аерылып калды алардан.

— Туган җирем шушы,
китмим,— диде,—
җәен күрдем, күрим кышын да,
нәселем монда туган, монда торган,
дәвам итәм аны шушында.

Өзелеп җиргә төште, җиргә ятты,
кыш өстенә япты, йоклатты...
Ә яз килеп, аны сыйпады да
яшел бөре итеп уятты.

Сандугач та очып кире кайтты,
яшел яфрак күрде талларда,
һәм җырлады:
бәхет туган якта,
эзләмәгез әллә кайлардан...

1966

## Туу

Буыннарның миндә дәвамы,
алар җаны миндә яңарды.
Әтиләрем миңа калдырган
Җиргә карап күзем таң калды.

Аяк бастым йомшак чирәмгә,
җылы җилгә сөрттем йөземне.
Үлән исен тойдым, җир исен,
тере итеп тойдым үземне.

Чәчәкләрдә төсләр җырлыйлар,
күкләрендә — зәңгәр тирәнлек.
Арыш басулары эченнән
киләчәккә карыйм кинәнеп.

Тәмнәр тоям, ишетәм авазлар,
сизә, күрә күңел күзләрем.

Рәхәтенә чыдап тора алсам,
михнәтенә генә түзәрмен.

Һәр тузаны яши, һәр ташы,
урын юктыр монда үлемгә.
Яшел үлән булып, без булып
әтиләрем кайта бүгенгә.

1968

## Бәхеттер

Бер түгел микәнни һавалар,
җирдәме, күктәме аерма?
Фатиха биргәндә әйткәннәр:
илеңнән, ягыңнан аерылма!
Авылның төтенен күрим дип,
каерылып бер карап алганнар.
Чаналар шыгырдап тынганчы,
хатыннар озатып калганнар.
Кагарлар, сугарлар дигәндер,
кәҗәсен читләргә сатмаган.
Иң алдан иманын яклаcа,
аннары якташын яклаган.
Бүрек тә, бишмәт тә бер тузган.
Юллыкка алмашып катасын,
картузын батырып кигән дә
шакыган авылы капкасын.
Йөргәндер, күп җирләр күргәндер,
шушыннан якын җир тапмаган.
Зимагур әйләнеп кайтса да,
бәхете ияреп кайтмаган.
Бер түгел микәнни һавалар,
аерым, үзгәме җире дә?
Бәхеттер
туу да,
яшәү дә,
үлү дә
үз газиз илеңдә!

1964

## Авылым

*(Эскизлар)*

***

Чынлап торып бер карагыз әле,
каерылып,
борылып карагыз...
Көннәр,
айлар,
еллар үткән саен,
ераклашмый микән арабыз?!

Плацларны җилдә селкедек тә
эшләпәдән кактык тузанын.
...Катык белән каймакларын гына

яратабыз мәллә без аның?

Һавасы бар,
суы,
чишмәләре,
тагын нәрсә бар соң, дисезме?
Ана исеме белән бер үк рәттән
йөрсен иде авыл исеме.

Чынлап торып бер карагыз әле,
каерылып,
борылып карагыз...
Барыбыз да аның күкрәгеннән
аерылмый торган бала без!

***

Чабатадан.
Тездән суга батып.
Язгы чәчү җитәр алдыннан
чыгып киткән икән симәнәгә
хатын-кызлар безнең авылдан.

Сыерлары юлда ятып калган,
җилкәләргә күчкән симәнә.
Бу турыда сөйләгәндә әле
әни һаман елап җибәрә.

Кырык-илле чакрым.
Язгы суда.
Кайталмасаң, илең ач кала.
Хатыннарда тик бер генә хәсрәт:
һәр йорт саен көтә ач бала.

Әтиләрнең сугышып йөргән чагы
безнең яңа туган ел булган.
Капчык аскан егермеләп хатын
басуларга кайтып егылган.

Орлык кайткан,
безгә гомер булып...
Без ни бирдек икән кайтарып?
...Әниләрнең әле яшәр чагы,
китәләр шул иртә картаеп.

***

Бер шырпысыз түзгән,
керосинсыз,
чәй-шикәрсез түзгән авыл ул.
Сыер боты кадәр малайларга
туйдыруы илне авыр ул.

Тәпи йөрер-йөрмәс бала-чага
буразнада билчән утаган.
Илгә — икмәк.
Авыл үзе өчен
көлчә салган алабутадан.

Көлтә төшсә, көлтә ега алган
ул чордагы нәни хуҗасын.
Олылар күк күтәргән бит шулар
Ил хәсрәтен,
Ватан нужасын.

Булган кадәр нигъмәтләрен куеп,
әзерләгән илгә өстәлен.
Мәрхәмәтле ана кебек, авыл
үзе генә белгән үз хәлен.

Зарланмаган.
Туендыручылар
олы җанлы була, түземле.
...Син кайгырткан кебек итеп, авыл,
кайгыртырга кирәк үзеңне!

***

Авылымны уйлап уйга талсам,
хыялларым баса чиратка;
хатын-кызга — җәннәт,
һәйкәл кирәк
исән вакытта ук ир-атка.

Кунак йорты аңа кирәк түгел,
һәр тәрәзе өйгә чакыра.
Шәп театр салып куйсаң иде
авылыңның берәр чатына.

Урамнарга тигез асфальт җәйсәң,
ак туфлиләр килешә кызларга.
Җәйләүләрдән «Волга» белән генә
кайтып керсен иде кыз бала.

Игенчене җәүһәр табучы күк
бик кадерле күрә илебез.
Килер көннәр,
бер чабышкы өчен
бер самолет ясап бирербез.

Авыл хакында дип,
шигырь диеп,
такмак әйтеп йөрмәс исәрләр.
Ул бит үзе иң беренче шагыйрь,
үзе үлчәр,
үзе исәпләр.

Барыбыз да бурычлы без аңа
үткән гомер,
шушы көн өчен.
Хыялымда минем — яңа авыл,
бүгенгесе — минем сөенечем.

***

Авыл һаман шулай олы җанлы.
Бәйрәм итә буразнасында.
Бер генә дә буш юл табалмассың

игенченең елъязмасында.

Кул юарга калса, кала вакыт,
каравыллап йөри таңнарны.
Без беләбез инде,
улларыбыз
ипи тәмен менә аңлармы?

Яшәү юлы булып ята һәрчак
авыл юлы,
авыл урамы.
Изге җаннан икән кешеләрнең
иген игеп яши торганы.

Йөз кат төшсә,
йөз кат алыр идем
түбәтәен аның иелеп.
Игенченең маңгай сыры саен,
җыерчыгы саен игелек.

...Нигъмәтләре бетмәс өстәлләрнең,
авыл исән-имин чагында.
Аңа рәхмәт укый-укый гына
утырыгыз, зинһар, табынга!

## Таң алдыннан агачларның шавы

Болытларга карап ята юллар,
караңгылык йоткан биек тауны.
Кырлар япкан төннән кара юрган,
ишетелә агачларның шавы.

Таң алдыннан яфраклары шаулый,
бер уянгач йоклый алмый микән?
Яфрак булып яфрак нидер даулый,
таңда йоклау безгә хәрәм икән.

Зур бурычын тоеп йөри йөрәк,
үсә миндә һаман уйлар тавы.
Юкка түгел, юкка түгел, димәк,
таң алдыннан агачларның шавы.

1968

## Өлкәннәр

*Хәсән Туфанга*

Юлларга чыгыйк әле без,
бер нужа күрик әле.
Рәхәтен, азабын бергә
тигезләп бүлик әле.

Аркада — кадерле биштәр,
көн кыска, барыйк, барыйк.
Кемнәрнең хәлләре ничек —
юлларга чыгып карыйк.

Киткәннәр һаман барамы
өметләр өеп алга?

Йөрәкләр юлда ара бит,
җитәрләр микән бар да?

Шырпысы юктыр берәүнең,
яңгырда чылангандыр.
Утым юк, учагым юк дип,
ялгызы моңайгандыр.

Ут бирик.
Учак ягарга
бер шырпы җитә бит ул.
Дөньялар, шырпы сызсаң да,
ялт итеп китә бит ул.

Юлыннан язганнар булса,
әрнидер, сүгенәдер.
Тауларга менеп кул изик,
биектән күренәдер.

Нурларын күрми таңының
ятадыр берәү оеп.
Сызгырып китик яныннан,
уянсын, торсын тоеп.

Үзебез арсак, өшәнсәк,
күрерләр, булышырлар.
Юлларга чыгыйк, юлларга,
юлда гел узучы бар.

1971

## Иске ярда

Гигант үрмәкүчтәй карт тамырлар
каерылып комда кырын ята.
Иңләп-буйлап аккан киң агымнар
тынып китә ярдан, ярсып кайта.

Зур усаклар монда торган сакта,
камыш шавы күчкән елдан-елга.
Бар көченә ташып аккан чакта,
үз ярларын басып киткән елга.

Ярсулары беткәч, кире кайткан,
ташкын тынган, сүнгән гайрәт-көче.
Ә усаклар егылып буйга яткан,
бер елганың бер дулавы өчен.

1969

## Имән

Кәүсәләре соры сөяк булган,
кабыклары төшкән картайгач.
Тирәсендә ярык төпләр генә,
мәйдан уртасында — карт агач.

Давыл килде.
Урман башын иеп
әзер тора кебек аварга.

Ә имәндә тере ботаклар юк
кара-кучкыл булып шауларга.

Хәлсезләнгән кәкре тамырларын
соңгы куәт белән батырып,
Җирне кочты...
...Мәйдан уртасында
басып калды урман батыры.

Урман ире ауды давыл тынгач,
бер сискәнеп куйды агачлар.
Үлеме дә аның бер гөрелте,
адәм белән имән — адашлар.

1963

## Иргә чыкмый калган апалар

***Өч кулъяулык болгап өчәү китте...***

Печәннәре чәбәләнеп калды,
чабылып бетми калды өч алын.
Чалгыларын онытып калдырдылар,
пакусларга кадап очларын.
Китәселәр киткән.
Соңгы озату.
Авылдагы соңгы өч егет.
Бер болында өч кыз басып калды,
күзләрендә калды өч өмет.
Урамнардан чыгып китте җырлар,
яшьлек шаулап тынды озакка.
Дугадагы кыңгыраулар чыңы,
гармун тавышы калды колакта.
Китте...
Китте...
Чак-чак өлгерделәр
кайнар билләренә кул салып.
Калды...
Калды...
чынлап үбелмәгән
сусыл иреннәре турсаеп.
Өч кулъяулык болгап өчәү китте,
очып киткән кошлар төслерәк.
Читлектәге асыл кошлар кебек
талпынышып калды өч йөрәк.

***Үкседеләр кызлар капланып...***

Хатлар язды өч кыз бер өстәлдә,
терсәкләрне терәп терсәккә:
«Ташламагыз безне, ташламабыз,
ниләр язса, ниләр күрсәк тә».
Иреннәре белән ябыштырып,
өч кат үбеп бергә салдылар.
Өч тәрәздән карап өч кыз көтте,
өч егеттән өч хат алдылар.
Ә беркөнне килде ике җавап,
ә беркөнне килде соңгы хат.
Хатлар язды өч кыз бер өстәлдә,
бер егеткә өч кыз соңгы кат.

Яшелләнеп, куе булып үсте
алар чабып киткән алыннар.
Киң-киң атлап чалгычылар үтте:
күз алдында таныш адымнар.
Өч кыз йөрде бергә болын ярып,
яшь талларны кочып үттеләр.
Кайтмаска ук киткән егетләрен
болыннарга чыгып көттеләр.
Туры басып, кемнәр чалгы янап
сызгырдылар? —
Бу да истә бит.
Алар тавышы белән дәште болын,
өч кыз йөрде тыңлап,
сискәнеп.
Бер-беренә вәгъдәләшкән кебек,
сыенышып үскән үләннәр.
Аермагыз, без — бер дигән сыман,
кыякларын бергә үргәннәр.
Дер селкетеп үтсә астан елан,
аерылып кала пар үлән...
Ташламам дип вәгъдә биреп кенә
кавышып булмый икән яр белән.

Яшь малайлар чапты инеш буйлап,
алар җиккән атка атланып.
Күз яшьләрен сөртеп үләннәргә,
үкседеләр кызлар капланып.

***Еллар белән бергә яшьлек үтте...***

Үтте...
Үтте...
Еллар елга тоташ...
Җилкенешеп алган чакларда,
сандык ачып, кызлар хат укыды,
тик үзләре юк шул хатларда.
Алар ташлап киткән алыннарны
кызлар ел да бергә чаптылар.
Егетләрен кабат күргән кебек,
унсигезгә борылып кайттылар.
Кызлар хисен инде яшьлек түгел,
дуңгыз фермалары исертте.
Кышкы кичтә алар тальян моңын
абзар аша гына ишетте.
Үтте...
Үтте...
Бөтен авылына
сугыштан соң ике аксак бар.
Ике кулсыз йөрде җиңен селкеп,
кабер кырыенда — аксакал.
Толлар да тол,
калган кызлар да тол,
никах күрми китте кияүләр...
Егетләрдән калган бүрекләрне
сеңелләре эшкә кияләр...
Үтте...
Үтте...
Егет кулы түгел,
тормыш тотты нәфис куллардан.

Дүрт баласы бергә елаганда,
көнләштеләр кызлар толлардан.
Ач баласын иске шәлгә төреп,
толлар мичкә тизәк якканда,
кияүгә дә чыгып калмадык, дип
көрсенделәр кичен ятканда.
Калган иде өч кыз,
егетләре
өч кулъяулык болгап киткәндә.
Еллар белән бергә яшьлек үтте...
Үтмәгән дә кебек,
үткән дә!

***Илле яшьлек кызлар чигү чигә...***

Аулак өйдә кызлар чигү чигә,
колакларда — сәгать тавышы.
Сәгать кебек келт-келт итеп кенә
гомерләрнең үтеп барышы.
Арттан бәйләп куйган ак яулыктан
күренеп тора бераз ак чәчләр.
Ут шәүләсен таң дип белә микән,
сөрән сала малай әтәчләр.
Ишекләрне һаман шакучы юк,
егетләргә, ахры, иртәрәк.
...Алларында көрән песи ята,
бераз шаян, бераз иркәрәк.
Яулык чигә өч кыз кич утырып,
күзлекләре түбән салынган.
Яулыкларда — болын чәчәкләре,
чәчәк урталары — сарыдан.
Битләрендә бераз кызыл шәүлә,
яңаклары бераз кызарган.
Хушбуй микән, иннек, пудыр микән,
чәчәк исе килә кызлардан?
Төшеп беткән инде сәгать гере,
күтәрерләр әле, күрсәләр.
Унсигездә шиңгән чәчәкләре
яулык почмагына үсәләр.
Илле яшьлек кызлар яулык чигә,
дулкынлана яулык читләре.
Ишекләр дә ачык,
егетләре
бүген тагын кайтып җитмәде...

1971

***

Карга оялары җирдә ята,
җитмәгән күк дулый җил әле.
Бала кошлар тынган күккә карап,
томшыкларда калган җимнәре.

Җилләр белән очып китте микән
бу бичара бала кош җаны?
Җилләр алар үтәүчеләр генә

үзләре дә язмыш кушканны.

1970

## Кыйшык йорт тәрәзәсе

Үзе тузган, үзе кыйшык,
сыңар тәрәзәсе кыек.
Салам башын кыңгыр салып,
иске йорт тора оеп.

Нәрсә яшәртте кич белән,
дисәм, бу иске йортны...
Ут кабынды,
тәрәзәдә —
япь-яшь кыз силуэты!

1971

## Кызлар ташу карый

Актарылып ага, ургый, ташый —
инеш диңгез сыман.
Күкрәкләрен язгы бозлар ашый, —
ярлар горур, чыдам.

Сөйгән ярлар кебек китә бозлар,
бераз моңсу, кыен.
Тезелешеп баскан ярга кызлар,
ярда язгы җыен.

Йөрәкләргә кага яз сулары,
ургый, урый, камый...
Тыя-тыя йөрәк ярсуларын,
кызлар ташу карый,
кызлар ташу карый.

1971

## Мәҗнүн

Мин — бер ялгыз.
Җаным җылы сорый,
су сораган коры кыр сыман.
Танырмы дип үземнекен көтәм,
җырлаучысын көткән җыр сыман.
Мин — тоташ моң.
Көзге кичләр төсле
бер яктырып алам,
бер — болыт.
Күгем иркен,
мәңге якты булып,
кемнәр чыгар икән Ай булып?
Мин — зур өмет.
Бәхетлеләр өчен
тиңсез сөю бар дип ышанам.
Кайларда ул?
Кайгысына кайгы,
шатлыгына шатлык кушалам.
Мин бит Мәҗнүн,

гашыйк кына түгел.
Гашыйклар да сүнми, кабынса.
Мин бит Мәҗнүн!
Аны эзләп йөрим.
Ләйлә генә таныр таныса!

1969

## Җәйге төн*

*(Җыр)*

Ай яктысы су кебек,
нурлар төшә бөркелеп.
Кызлар яна кочакта,
бер моңаеп, бер көлеп.

Кушымта:
Килә шомырт исләре,
чәч исләре татлырак.
Күзләрендә ни икән соң
ай нурыннан яктырак?

Чыклар да төшеп килә,
әйтелмәгән сүз генә.
Күз белән күз сөйләшә:
«Бәхетледер без генә!»

Кушымта.

Капка тоткалары ак,
көмеш явып үткәндер.
...Чыңгырдады тимер бик,
сорамыйча үпкәндер.

Кушымта.

1971

## Имәннәр әле көтә

Җирдә бер тылсым бар сыман,
ачылган бөтен яме.
Каеннар яшелгә чумган,
имәннәр шәрә әле.

Яз икән инде, яз икән,
дөньясы шуңа чибәр.
Китмәскә килгән яз икән,
бөреңне ачып җибәр.

Салкыннар килеп орынса,
яфраклар туңмас микән?
Сабыр итәргә тырыша
имәннәр шуңа икән.

Каеннар инде яшәргән.
Имәннәр әле көтә.
...Көтсәң дә,
көтмәсәң дә, бер —
яз ул килә дә китә.

1969

## Әйт әле

Әйт әле миңа дөресен,
әйт әле яшермичә:
яраткан көннәрең күпме,
сөймәгән көнең ничә?

Вакланып киткәлим микән
кыбырсык чакларымда?
Җебеп тә аламдыр әле
бу тормыш чатларында.

Усал да булып куяммы?
Гел юаш булмам инде...
Гадел булмаган чакларда
күргәнең бармы мине?

Кешелекле, игелекле
вакытым буламы соң?
Әйт әле миңа дөресен,
эшләрең торып торсын.

Әйт әле күземә карап,
беләсем килә хәзер.
Мин дә бит адәм баласы,
үксеп еларга әзер.

## Кадерлем

Оныта алмам, диеп китеп бардың,
мин дә онытмыйм ич, хәтерлим.
Үткәннәрне уйлап сагынганда,
исемеңне сөеп әйтермен.

Йөрәгеңне тоткан учым кайнар,
мин хәтерлим әле, хәтерлим.
Янулары үкенечле түгел,
ут булырга үзем әзер мин.

Утлар ягып суын алып киттең,
мин хәтерлим, һаман хәтерлим.
Су эчергән кызлар шактый булды,
ут йоттырган кеше кадерлем.

1967

## Саубуллашу*

*(Җыр)*

Текәлеп карыйм күзеңә,
сереңне алыйм әле.
Сурәтем калсын күзеңдә,
текәлеп карыйм әле.

Яшермә миннән күзеңне,
карашың якты, ачык.
Йә, күрсәт инде үзеңне,
керфекләреңне ачып.

Тартынып кына карыйсың,
янасың, көясеңдер.
Аерылу хәлен аңлыйсың,
читендер, түзәсеңдер.

Текәлеп карыйм күзеңә,
сереңне алыйм әле.
Сурәтем калсын күзеңдә,
текәлеп карыйм әле.

## Көтәм әле*

*(Җыр)*

Килерсең дә кебек,
килмәссең дә кебек.
Көтәм әле, көтәм,
газапларга күнеп.

Кушымта:

Аһ, бу билгесезлек,
аһ, бу көтүләре.
Яратулар үтмәс,
яшьлек үтәр әле.

Киткәннәр дә кайта,
юк, син алай итмә.
Тик бер генә кил дә,
бер тапкыр да китмә.

Кушымта.

Килерсең дә кебек,
килмәссең дә кебек.
Көтәм әле, көтәм,
газапларга күнеп.

Кушымта.

## Кама ярларыннан эзлим сине*

Кама буйларыннан эзлим сине,
дулкыннарга карап юксынам.
Шушы ярда сине тапкан идем,
озатып калдым сине шушыннан.

...Итәгенә басып таш ыргыттык,
ачуланып түгел,
шаярып.
Йолдызларны санап,
айга карап,
уйга талдык, ярга таянып.

Яр буена ялгыз килеп бассам,
телгә килеп әйтер шикелле:
«Син берүзең йөрмә монда, егет,
мин күнеккән күреп икене».

Ташында да, соры комында да
юылмаган безнең эзләр бар.

...Кама ярларыннан эзлим сине,
мин дә китсәм, безне эзләр яр.

Кама ярларыннан эзлим сине,
дулкын өсләрендә күләгәң.
Мәхәббәтне юк диюче булса,
андый кеше сине күрмәгән!

1968

## Көзге күктә болыт бар...*

*(Җыр)*

Көзге күктә болыт бар,
әллә яңгыр, әллә кар.
Болытлар үтәр әле,
аяз калыр офыклар.

Болытлар авыр инде,
бер килгәч явар инде.
Болыты үтеп китәр,
яңгыры калыр инде.

Көзге күктә болыт бар,
әүмәкләнеп агышы.
Кайгылар үтәр-китәр,
китәр микән сагышы?

1970

## Мәхәббәт

Үзең коткар бәла һәм афәттән,
Ярдәмчем бул, ниләр күрсәм дә;
Тик коткара күрмә мәхәббәттән,
Учагында көлгә дүнсәм дә.
*Н.Арсланов*

Без яратмый, җирдә кем яратсын,
чиге бармы матур хисләрнең?
Шашып сөя алсам, яшәп булыр,
мәхәббәтем сүнсә, нишләрмен?!

Йөрәгемә салкын су сипсәләр,
бер көнгә дә, бәлки, чыдамам.
Ярым өчен иң зур океан кичеп,
тере чәчәк алып чыгалам.

Күңел тулса тулсын,
мөлдерәп торсын.
Тамчысына кадәр кадерле.
Без — табигать таҗы,
бөре чыга,
чәчәк чыга
тишеп бәгырьне!

Җаным янып сөйсә, күтәрермен —
бер бәхетем торсын мең газап.
Хисләремне мин коллыкка бирәм,

мәхәббәтем бөек һәм азат.

Әкиятләрдә ул без,
без — поэма.
Мин ул очам шашкын атымда.
...Поэмалар әле язарбыз без
бөек яратулар хакында.

Таһирлар да, Зөһрәләр дә исән,
Мәҗнүннәр дә йөри табынып.
Мәхәббәткә җирем батар иде,
бу йөрәгем китсә ярылып!

1971

## Тамчылар

Керфегең очында
тамчылар
мөлдерәп торалар.
Өзелә тамчылар...
Керфекләр яңадан тулалар.

Тамчылар тама да,
тама да
йөрәккә кадала.
Акылым юата:
карама,
тамчыга карама.

Күзләре,
яшьләре тамуы
истә бит,
күңелдә.
Авыр ла күтәреп баруы
тамчыны гомергә!

1968

## Син кирәк

Хыяллар гел сиңа урала,
бердәнбер булуың хак, димәк.
Көннәрем үткәндә кабатлыйм:
ул кирәк, ул кирәк, ул кирәк!

Ялкыным чәчелә, сибелә,
нур итеп җыярга, кил, өйрәт.
Кышын да, көзен дә — һәрвакыт
җылы яз, җылы наз — син кирәк.

Бер-берен эзләгән кешеләр
очраша, табыша бик сирәк.
Кулыма бик кирәк кулларың,
иңемә иңнәрең бик кирәк.

Ерак юл, зур эшләр алдымда,
көчләрем кимесә, бул терәк.
Дөньямны, җанымны аңларга
син кирәк, син кирәк, син кирәк!

## Әйтегез, кешеләр!

Турсайган, йомшаган чак була,
күңелгә наз кирәк чак кына.
Сез дә бит нәкъ минем ишеләр,
җылы сүз әйтегез, кешеләр.

Кайнаган, ярсыган чак була,
гаделлек җитми күк чак кына.
Мең кояш актырта юлымны,
эчкерсез кыссагыз кулымны.

Тоймастан абынган чак була,
таяныч эзлисең чак кына.
Иңемә канатлар үсәләр,
кешеләр кул биреп үтсәләр.

Куәтем ташыган чак була,
ярдәмем тимәсме чак кына?
Сез дә бит нәкъ минем ишеләр.
Ни кирәк,
әйтегез,
кешеләр?

1968

## ***

И чабабыз, йөгерәбез,
этенәбез, төртәбез.
Олы эшләр ята бирә,
абынышып үтәбез.

Ирлеккә тиң, Кешегә тиң
уйлар уяу торганда,
күп йөрәкне җилкетерлек
кодрәтләр бар бит җанда.

Олы мәшәкатьне ташлап,
ыгы-зыгы эченә
кереп китсәм иләсләнеп,
туктат мине!
Кичермә!

1971

## Заман көтә

Җиңел түгел тормышы да, заманы да.
Безнең өстә шатлыгы да, газабы да.
Кешеләрнең кайсы җырлап сөендерә,
кайсы елап, кайсы чыдап сүгендерә.

Берәү дәшми дәшәр чакта, түзеп тора, —

бер җансызы күгәрченгә мылтык кора.
Көләр чакта ачу белән каш төрелә, —
кешеләргә бик кирәкле нур өзелә.

Очрап куя арабызда җан телүче,
иман алып, иман сатып көн күрүче.
Бик тәртипле, бик тыңлаучан егетләр бар:
нәфес иркен, йөрәк нәни, күңелләр тар.

Көннәр килә көлтә-көлтә шатлык төяп,
зәңгәр күзле яшьлек йөри шигырь сөйләп.
Иманлылар, инанганнар — безнең халык,
Җиргә карый, Күккә карый таңга калып.

Кеше булып йөрү җирдә җиңел түгел,
бик күп нәрсә безнең сүзне көтә бүген.
Тоегыз, ди, ишетегез, күрегез, ди, —
туар моңнар, туар җырлар урын эзли.

Мәшәкатен түкми-чәчми иңгә салган,
бер керфекнең чыклануын күрә алган,
мең шатлыкны бергә төйнәп күтәрерлек,
ил кайгысын йөрәк аша үткәрерлек,

туры сүзгә, туры йөзгә карый торган,
намусларны стаканга салмый торган,
чиста куллы, чиста уйлы ирләр генә
безнең сүзне, дөрес сүзне әйтә белә!

Аналардан малай туа, ирләр тумый,
малайларның туган бере гел ир булмый.
Сабыр итеп һәр мизгелдә заман көтә:
кыл өстеннән кемнәр үтә,
ничәү үтә!

1970

## Үземә

Елларның көннәре,
төннәре үтелгән.
Берсендә сөенеп,
берсендә үкенгән.

Яшибез икән бит
күптәннән, күптәннән...
Яшьлегең аркылы
дәверләр үткәннәр.

Сана да, сайла да,
мин яшь дип юанма.
Киләчәк барын бар,
бу көннәр юк анда!

1971

## Кар яуганда

Инде җиргә күпме карлар яуган...
Барысы да шушы бер кышта.
Кара!
Җиргә күпме карлар яуган...
Барысы да ап-ак, чип-чиста.
Карлар ява,
безнең иңгә ява,
күтәрүе карны җиңел лә...
Кар яратсаң,
яңгырын да күтәр,
бозларын да күтәр,
иренмә.

1969

## Усаклар

Җырның матурларын малай чакта
урманнарда тынып тыңладык.
Олылардан качып үзебез дә
урманнарга китеп җырладык.
Аңлап түгел,
болай ярattык без
табигатьнең һәр тын алышын.
Бер җырга да алыштыра алмыйм
усак шавын,
урман тавышын.
Җилсез шаулый алар...
Мин аларның
тынмас җанын һаман аңламыйм.
Усак төпләреннән китә алмыйм,
һаман малай,
һаман бала мин.
Җанымның да шундый көйләре бар,
рәхәт тоеп йөрим мин аннан.
Малай вакыттан ук ияреп килгән
матур көйләр миңа урманнан.
Инде юллар урман юлы түгел,
күптән үтте инде ул чаклар.
Барам көйләп, —
миннән бераз алда
лебердәшеп бара усаклар...

1971

## Энеләр

Таулар биек.
Җилләр җитез исә.
Йөрәклеләр төшә ук булып.
— Сак-ла-ны-гыз!
Алда сикәлтәләр-р-р!
...Өерелеп кала ак болыт.

Безнең энеләр ул.
Энекәшләр.
Безнең кебек чая,
тереләр.

Таулар текә.
Кузгалыгыз бергә.
Бәрелмәгез генә,
энеләр!

## Замана

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.

*Р.Фәйзуллин*

Бу ныклык, бу сафлык,
нәфрәтләр, сөюләр,
җаннарның балкышы,
янулар, көюләр
күкләрдән иңгәнме,
кайлардан килгән ул?
Җиңелмәс рухлы җан
кайлардан, кемнән ул?
Яшәгән бу халык,
заманнар кичергән.
Өмете кырык кат
ялганган, киселгән.
Ансатмы, кыенмы —
тормышын юллаган.
Хәсрәте булса да,
мескенлек булмаган.
Күтәреп заманны
заманга ялгаган.
Син минем бәхет дип,
михнәтен алдаган.
Кемнәрдер егылган,
кемнәрдер үткәннәр.
Аякка чалынып
йөргәннәр бүтәннәр.
Борыннар каный ул
аларга абынып.
Кем яши табынып,
кем яши тагылып.
Вакытлар аера
барыбер аларны.
Мескеннең зары бар,
халыкның — заманы!
Өметкә инанып,
күтәрелеп, ишелеп
егылган һәм торган
бүгенге кешелек.
Нык җелек, нык буын,
өрекмәс, тынмас җан,
киң офык — киң караш,
суынмас кайнар кан
сыгылып, сыналып
яхшыда, яманда
ныгый һәм чистара
заманнан заманга!
Заманга ябышып
зарлана мескеннәр:
«Ник сытып үтәсең,
без кемнәр,
без кемнәр?!»
Замана белә ул:

бик егет чаклары;
чабуына тотынып
кем генә чапмады!
Кодрәтең зур икән,
җилкәңә салып бар.
Һич юкта таягын,
биштәрен алып бар.
Буш арба түгел лә,
ябышма, сырышма.
Без киттек, калсаң кал,
заманны орышма!
Әйбәт ул замана,
бик шәп ул замана.
Замана — без бит ул,
кем анда зарлана?!

1971

***

Кемнәрне еллар үстерә,
кемнәрне юллар үстерә,
кемнәрне җырлар үстерә
зур итеп.

Кемнәрне еллар үтерә,
кемнәрне юллар үтерә,
кемнәрне җырлар үтерә
хур итеп.

1969

## Язылгыз хатлар*

*(Җыр)*

Тормышта була якыннар, ятлар,
сагыш һәм кайгы торгалый сакта.
Якын итсәгез, языгыз хатлар,
еракта чакта, берьялгыз чакта.

Иптәш күрсәгез, чынлап сөйсәгез,
саран булмагыз җылы хисләргә.
Сөенсен әле бу да дисәгез,
янда булыгыз ялгыз кичләрдә.

Языгыз хатлар, җылы нур салып,
бер хат язуы авыр түгел лә.
Языгыз хатлар, ялкынга манып,
бер хат бәясе кыйммәт күңелгә.

1969

## Әтисезләр болар димәгез

Тапмасам да кабер ташларын,
төшләремә кереп булса да,
буыннарым бушап киткәндә,
үзе кайтып, иңгә кул сала.

Куәтләнеп китәм, олыгаеп,

шундый бул дип алга этәрә.
Хуплаганын белеп торам мин,
горурланып дөнья күтәрәм.

Әтисезләр болар димәгез,
без бәхетле, горур, аталы...
Бар эшләрен безгә ышанып,
алар өйгә кире кайтмады.

Яшь түгәргәмени зар елап,
әтиләрнең рухын кимсетеп?
Горур булып калган хәтердә,
егылса да ерак җир китеп.

Табалмадым кабер ташларын,
һәйкәлләрен үзебез салабыз.
Малай чактан егет булалдык,
инде әти булып барабыз!

1968

## Чит илдән хат

Әллә ник күңелем борчулы,
авыллар тынычмы, иминме?
Гомерем үтә бит, Габдулла,
күрергә тилмереп илемне.
Кайтам дип канат та кагындым,
борылдым вокзалга җиткәндә.
Туган ил каргышы төшкәндер,
ят итеп читләргә киткәндә.
Зур итеп күчтәнәч салгансың,
дару күк тотабыз каз итен.
Көненә өчәр кат карыймдыр
коштеле төрелгән гәзитен.
Үзең бер кунакка килеп кит,
монда да була тук яшәргә.
Тик менә ямансу, бик моңсу,
кеше юк безнеңчә дәшәргә.
Балалар телләрен онытты,
без дәшсәк, аңламый көләләр...
...Күп гомер калмады, Габдулла,
монда да каядыр күмәрләр...
Авылның зираты ни хәлдә?
Терлектән таптата күрмәгез.
Картайган көнемдә кайталсам,
мине дә кәфенләп күмәрсез.

1968

## Ирләр

***Тормыш ятим***

Китеп беткән хатынлылар, хатынсызлар...
Дөнья тоткан, семья тоткан хатын-кызлар.
Ятимлеген тормыш үзе шәп аңлаган:
илдә тәртә каерырлык ир калмаган.

Кәнсәләргә йөрү аның эшемени?
Чөелдерек каба җебе ишемени?
Ирең кебек иманнәрне иңгә салу

кыен, Банат, кыен, Биби, кыен, Бану.

Тонықланган болыннарның яңгыравы,
янап кына китсәң иде чалгыларын.
Үгез тоткан малайларның үртәлүе:
авып төшә авыш якка көлтә йөге.

Хәтәр буран. Юлсыз юллар. Текә тавы.
Кире үгез йолкып өзә камыт бавын.
Мондый чакта тешен кысып түзә, диләр,
сирәк ирләр, сирәк ирләр, сирәк ирләр.

Аңа дигән ашы тора учагында.
Эреп кенә йоклар иде кочагында.
«Ирем дигән изге сүзне кемгә әйтим?!»
Өйләр ятим, урам ятим, кырлар ятим.

Сәер генә көлеп кайтып керсә иде.
Мин әз генә салдым, карчык, дисә иде.
Өтек бер ир бүрек кигән өчен генә
кагып йөри ирсез авыл ишегенә.

Кичә дә буш, бүген дә буш өстәл башы,
әллә кайта, әллә юк дип көтә кашык.
«Утыр, улым, утыр өстәл түренә син,
нәкъ этиең кебек булып күренәсең».

Бергә төшкән рәсемнәре кулларында.
Таныш төс бар ятим калган улларында.
Күлмәкләрен күкрәгенә алып кыса:
«Ирем булса!
Ирем булса!
Ирем булса!»

### *Соңгы сулыш*

Кат-кат әйтә ата-баба, нәсел-ыру:
тигез тормыш, тигез бәхет — тигез тору.
Идел түгел, ир күтәрә авырлыкны,
иргә биргән батырлыкны, сабырлыкны.

Ир канаты — ирләр үлсә, илләр үлә,
ир исеме ил исеме белән бергә.
Яман җилләр канатларны каермасын,
илне ирдән, ирне илдән аермасын.

Аерам дип, каерам дип, көннәр туган,
ирлегеңне илгә күрсәт инде, туган.
Башкаларны үзе белән әйди-әйди,
чыгып чапкан Гатаулла, Гариф, Гайни.

Бетәм диеп утка кергән, исән чыккан.
Сабын белән ябыштырган хат карчыкка:
«Аста җылы, өстә җылы, кайгырмагыз,
туган илне дошманнарга калдырмабыз!

Сезгә генә кыен инде, нишләтәсең,
бик борчылма, хафаланма, түз, әнкәсе.
Малайга әйт: камыт-дуга исән булсын,
тимер худның күчәрләрен майлый торсын.

Хәзер менә атакага тагын китәм.
Болай булса, берәр елдан кайтып җитәм.

Хат килмәсә, борчылмагыз, тыгыз вакыт,
бер минуты, бер сәгате елдан артык».

Ирләр язган беренче хат, соңгы сәлам,
иң соңгысын ирләр язмый, яза каләм:
«Батырларча һәлак булды Ватан өчен...»
Исән ирләр даулап йөри Ватан үчен.

Агач аяк йомшак юлда чума, бата.
Күкрәгендә салкын кургаш сызып ята.
Тешен кысып авылына бер ир кайта,
Гариф та юк, Гайни дә юк, тик бер Гата.

Шатланалар: әйдә, Гата, син ир кеше,
ал кулыңа, хуҗа булу ирләр эше.
...Басу саен агач аяк эзе кала,
баскан саен салкын кургаш чәнчеп ала.

Түзеп чаба сыкрауларга, сызлануга,
ял итәргә ята басу ызанына:
«Ипи булыр, түкми-чәчми моны ургач...»
Кадап ала соңгы тапкыр салкын кургаш.

Гомер итеп беркайчан да ир туймаган,
ызаннарда җан бирәсен кем уйлаган!
Көрәшләрдән көрәшләргә ташлый-ташлый,
әнә шулай язмыш иргә һәйкәл ясый.

Ирләр көтми: кайда гына соңгы сулыш!
Ирләр белә: җилкәләрдә заман, тормыш!
Ир исемен ил йөзенә тирән уйган
ирләр булган!
Ирләр булган!
Ирләр булган!

***Ирләр исән***

Юлга чыксаң, үтә еллар, үтә еллар...
Аналарның маңгаенда күпме юл бар!
Еллар белән үлчәргәме бу юлларны,
юллар белән үлчәргәме бу елларны?!

Сөйлисе юк: фәлән илдә, төгән илдә...
Үткән еллар, үткән юллар шушы җирдә.
Маңгай сыры — шушы басу ызаннары,
битләрендә — шушы туфрак тузаннары.

...Банат юлда, Биби юлда, Бану юлда,
ашъяулыкка төреп тоткан төен кулда.
Сөялле кул башакларны сыйпап үтә:
өч тол хатын төшке ашны кемгә илтә?

«Гарифуллам күрсә иде арышларын...» —
әллә кайдан урап кайта сагышлары.
«Гайни белән бергә чәчеп йөри идек...» —
әй бу күңел, әй бу күңел һаман китек...

«Гата ятып үлгән басу ызаннары...» —
Хәтер тукый: онытмагыз узганнарны!
Оныталмый өч мәрхүмне өч тол хатын —
күңел белә, күңел саклый ирләр хакын.

Өч хатынга башын ия сары арыш,
сорый кебек: кая барыш, кая барыш?
Өч тол хатын төшке ашны кемгә илтә?
Ирләр дә юк, кемнәрең бар, кемнәр көтә?

Бер басуда бергә туктый өч комбайн,
сикереп төшә замананың өч малае.
Әтиләрдән уйнап калган чаклар узган,
битләрендә, кулларында шул ук тузан.

Малайларга әйтелмәгән мирас калган,
сүзсез генә кабул итеп алар алган.
Шул ук тормыш, шул ук кырлар,
шул ук иген
тоя бүген ирләр иңен, ирләр иңен.

Мичтә калган әтисенең төшке ашы,
бераз китек әтисеннән калган кашык.
Бу да мирас ир кешедән ир кешегә.
...Малай чактан ир күмелә ил эшенә.

...Өч тол хатын дәшми генә кире кайта.
Дәшми генә кырлар ята, иген ята.
Хатыннарга тынгы бирми яңа уйлар,
әллә каян ирләр дәшә, дәшә еллар:
«Безнең уллар инде күптән үскән икән...
Без бит исән!
Без бит исән!
Без бит исән!»

***

Калкып чыга Гатаулла... Гариф... Гайни...
Хатыннарның йөрәге күк кырлар кайный...
Бәгырьләрен телеп-телеп ала сагыш:
Улларына шәфкатьле бул инде, язмыш...

Улларына шәфкатьле бул инде, язмыш!

1970

## Кайнар җилләр

**1**

Кырлардан әйләнә күңел,
кырларга тарта күңел.
Аерылсам басуларымнан,
көннәрем тыныч түгел.

Диңгезләрендә булам да
кайтам үз кырларыма.
Тузан ерып каршы барам
туачак җырларыма.

Киң атлап үтәм басудан,
яшел йөкләр кайтканда.
Юллардан узам ашкынып,
арыш чәчәк атканда.

Җилләргә куям йөземне,
ярылсын, янсын әле...
Җилкенеп йөрим Җиремдә, —
эзләрем калсын әле.

Рәшәсе биттән йөгерә,
маңгаен сөртә ирләр.
Тормышым тормыш булалмас,
булмаса кайнар җилләр.

**2**

Йөзтүбән ауды батырлар,
алар тормышы — Җирдә.
Җиремне кочаклап тыңлыйм
алар сулышын мин дә.

Ниндидер өннәр ишетәм,
ниндидер аваз килә.
Нәрсә бу! Җирдә берьюлы
миллионлап йөрәк тибә!

Димәк, Җиремнең җылысы
шул йөрәкләрдән килә.
Ә җилнең, җилнең кайнарын
Җирнең җылысы бирә.

Гасырлар буе тапталган
кырларда эзләр калган.
Бу Җирдән ничәмә буын
яшәү җылысы алган.

Кайнар җил — алар сулышы,
буыннар теләге ул.
Исә дә безгә кабатлый:
буыннар терәге бул!

# Утлар

*(Поэма)*

***Кеше ут эзли***

Җирдә төн.
Дөнья дөм караңгы.
Җылы, якты кирәк —
таба алмыйм.
Үзем туңам,
үзем калтырыйм,
үзем Җирдә учак яга алмыйм.
Чыбык-чабык өеп куям да
ут эзләргә китәм...
адашам.
Кемнәр алган минем утымны?!
Аһ!
Утымны әгәр таба алсам...
учак ягар идем.
Кулымны
тотар идем ялкын өстендә.
Кемнәр аны миннән урлады,

кемнәр дошман миңа бу төндә?!
Аптырагач, туктыйм.
Кычкырам:
— Бармы Җирдә исән кешеләр?
Булса, кемнәр?
Утсыз, ялкынсыз
ни эшлисез, минем ишеләр?
Бер җавап юк Җирдә,
дәшмиләр.
Ә мин инде хәлсез, арыган.
Үзем туңам, үзем калтырыйм,
үзем атлыйм, үзем абынам.
Утсыз Җирдә өшим, сүнәм мин...
Аһ!
Алдымда нәрсә күрәм мин?!
Ут!
Якты!
Кемдер монда килә,
якты факел тотып каршыма.
Тирә-ягым кыя-тау икән,
тирә-ягым инде яктыра.

***Прометей белән бәхәс***

Ул туктады.
Үзе бер биек
кыя сыман алда күренә.

Билгесез зат:

— Ут эзләүче кеше синме ул?
Миндә утың,
кара,
күр менә!

Кеше:

— Таныш түгел синең тавышың,
шомга сала мине бу сүзләр.
Кем син үзең?
Бир син утымны,
мин арыдым инде аны эзләп.

Билгесез зат:

— Күрәм, кеше мине танымый,
Җирдәгеләр мине онытты.
Син утыңны менә эзлисең,
каян алган идең ул утны?
Кеше:

— Аякларың, куллар чылбырлы,
күкрәгеңә каккан кадак бар.
Кан ага бит әнә яраңнан,
нәрсә өчен мондый газаплар?

Билгесез зат:

— Мин ут бирдем Җирдә кешегә...

Кеше:

— Син? Прометей? Богау! Чынмы бу!

Билгесез зат:

— Мин — Прометей.

Үзем үлемсез,
үзем менә шулай чылбырлы.
Сезнең өчен богау кидем мин,
кешеләргә бәхет юрадым.
Утлар янсын өчен бу Җирдә,
шушы Җиргә кереп югалдым.
Кыялардан чыгып карыйм да,
мин янгыннар күреп әрләнәм.
Кыяларга куеп башымны,
сез — кешеләр өчен гарьләнәм.
Аллалардан алып ут бирдем,
кодрәтеңне күреп, ышанып.
Кире алам!
Минем утымнан
никадәрле Җирдә усаллык!

Кеше:

— Күп һөнәргә безне өйрәтте,
иҗат дәрте бирде янар ут.
Ул бик кирәк Җирдә кешегә,
аннан башка яшәр чара юк.
Прометей:

— Әгәр утта урак ясасаң,
мин сөендем, кеше, куандым.
Тереләрне утка салдыгыз,
янгыннарда көеп, Җир янды.

Кеше:

— Без төзедек, кордык ут белән,
ураклар да утта чыныкты.
Караңгыда утлар кабыздык,
салкын иде Җирдә, җылыттык.
Зур дау купты Җирдә, беләсең.
Яндырдылар безне, яктылар.
Чыныксын дип түгел, бетсен дип,
янган утка тотып аттылар.
Без бетмәдек.
Шул ук ут белән
дошманнарга каршы ташландык.
Сугышырга түгел, яшәргә
Җирдә утлы көрәш башладык.
Уттан үлем туып торганда,
Җир янганда миңа җиңелме?

Прометей:

— Бар утларны җыеп алдым да
мин коткардым менә Җиреңне.

Кеше:

— Син коткардым дисең,
тереләр
утсыз калгач Җирдә, ни файда?

Прометей:

— Җирдә калмый инде тереләр,
үлем, тынлык тиздән һәркайда...
Кеше:

— Мин бу Җирне бизим,
дошманнар
аны шулай утка тапшыра.

Прометей:

— Кешеләрне бүлә белмим мин,
миңа тигез Җирдә барсы да.

Кеше:

— Мин үлемгә каршы.
Бу Җирдә
көрәш бара һаман,
һаман дау.
Дошман сыйныф яный Җиремә,
без — Кешеләр исән һәм уяу.
Ут — тормыш ул безнең кулларда.
Ут — көчле дә бездә,
хаклы да.
Яшәү өчен бара бу көрәш,
утыңны бир яшәү хакына.

Прометей:

— Бетмәс, ахры, Җирдә янгыннар
ут булганда кеше кулында.
Һәр чаткысы — үзе бер үлем,
ничек уйлыйм яшәү турында.

Кеше:

— Ялгышасың.
Дошман сыйныфның
соңгы тартышуы ул бары.
Инде бүген синең утыңнан
Кояш ясый Җирнең уллары.
Прометей:

— Кеше, Кеше,
туган җиреңне
газапламас идең бу чаклы!
Бер мизгелгә ягам бер учак,
тыңлап кара зарын учакның.

*

Юкка чыкты факел, Прометей;
учак калды янып каршымда.
Чаткылары — кызыл күбәләк,
дөрләвендә — моң да, ярсу да.

Учак:

Башта миннән качты кешеләр,
куышларын ташлап калдырып.
Ә мин Җирдә бик еш кабындым,
файдасызга йөрдем яндырып.
Кеше килеп сузды таягын,
курыкса да кире алмады.
Шул вакытта яңа хуҗамның
таяк очын үрелеп яладым.
Алып кайтты мине куышка,
мәгарәдә учак кабынды.
Мин бәхетле идем бу чакта,
оныта алмыйм шушы чагымны...

Җылы бирдем, кеше өшесә,

пешерделәр миндә итен дә.
Дошманыннан саклап кешене,
дөрләп тордым урман читендә.
Еллар буе янды учаклар,
бер генә дә сүнеп карамый.
Кабызырлык көчең булмаса,
сүндерергә утны ярамый.
Шуңа күрә миңа кешеләр
мәңге сүнмәс гомер бирделәр.
Ярдәмче бул безгә мәңгегә
изгелегең белән, диделәр.

Сез яктыгыз мине, кешеләр,
яшәү кыен булгач яктыгыз.
Шатланышып, бергә сыенып
минем янда тормыш таптыгыз.
Мин күбәйдәм, һаман үрләдем,
кайсы йортка гына кермәдем!
Җылы бирдем, якты өләштем,
сезнең өчен яндым, сүнмәдем.
Тараттыгыз мине дөньяга,
әллә нинди эшләр куштыгыз.
Яшәү белән үлем китерде
мәңгелек дус — изге утыгыз!
Ничә чите булса дөньяның,
чите саен төрле ут яна.
Берсе астында бөре ачыла,
берсе астында көя Җир-ана!
Сез таптыгыз мине, кешеләр,
минсез кыен булгач, таптыгыз.
Ә нигә соң мине үзегез
үлем итеп Җиргә аттыгыз?!!

*

Учак сүнде.
Аның көлендә
бер кечкенә утлы шар калды.
Үзе сүнми,
үзе дөрләми,
салкын чорный тирә-ягымны.
Дөрләтмәкче булам бу шарны.
Шар селкенеп алды,
кызарды:
«Мәрхүмнәрнең кабер ташында
мүк шытарлык вакыт узмады,
кузгатырга мине уйлыйсың...
Беләсеңме,
кеше,
бу утны?
Хиросима — минем учагым,
ни арада әле оныттың?!»

Хиросима уты:

Янды миндә Хиросима,
Хиросима пыскып сүнде.
Кемнәр туган — күреп үлде,
тумаганнар тугач күрде.

Миндә барсы —
балаларның,
аналарның каргышлары.
Кемгә бирим,
кемгә тансык
януларым,
сагышларым?
Ике йөз мең* бер кабердән
ләгънәт укып карый миңа.
Һәр яшь бала бишегеннән
нәни йодрык яный миңа.
Ярларыма дулкын килә,
башын иеп, диңгез кичеп.
Ике йөз мең япон сорый:
«Хиросима!
Хәлең ничек?»
Яр буена ана килә,
яшел юрган аның кулларында.
Дулкыннарга карап елый —
гарип бала юрганында.

Кушканыңны күнеп үтим,
мин бит синең тугры колың.
Нигә мине яктың, кеше,
нигә бирдең көч һәм золым?!
Хиросима пыскып сүнде,
дөнья белә, мин сүнмәдем.
Атомнардан бомбаларга
гел үрләдем,
гел үрләдем.
Авыр йөкләр йөри әле
кара кошлар канатында.
Үлем төйи ракеталар
кыя-таулар арасында.
Трумэнның * варислары
туып үсә исән-имин.
Кнопкага басар өчен
Гризлиләр** булмас димим.

*

Хиросима —
керфекләрдә
чыклар тора,
чыклар кипми.
Хиросима —
каберләргә
куяр өчен чәчәк җитми.

Күпләр туган,
күпләр туар,
күпләр исән,
күпләр үлгән!
Кара,
кеше,
бу дөньяга
Хиросима күкләреннән!

*

Шар югалды.
Тынлык.
Караңгы.
Тагын утсыз япа-ялгызым.
Салкын үрли бөтен тәнемә.
Бу ямьсез төн нигә бик озын?!
Җылы кирәк миңа,
ут кирәк...
Прометейны эзлим тауларда.
Кычкырсам да, чыкмый тавышым.
Учак ягар утым кайларда?!
Йөгерәм дә...
абынып егылам...
аяк астым салкын туфрак.
Тагын торам,
тагын йөгерәм,
әллә кемгә дәшәм ут сорап:
Ут кирәк!
Ут кирәк!
Ут кирәк!

***Ут кабына***

Хәлсезләндем...
Беттем...
Адаштым...
Мәгарәләр...
Таулар...
Кыялар...
Упкыннарга төшәм егылып,
яңалары көтеп торалар.
Куышларга керәм...
...ике... өч...
Барысы да салкын...
өшетә.
Чү!
Нәрсә бу?!
Әллә саташам,
кайда тимер тавышын ишетәм?!
Зур бер куыш упкын төбендә.
Керәм!
Күрәм!
Әнә ут яна!
Богаулары белән Прометей!!
...Ут янында әнә ул ята.
Богаулары зыңгылдап куя —
йоклаганда ташка кагыла...
Сорыйм микән утын,
бирерме?
Барыйм микән торып янына?
Бирмәс!!
Бирмәс!!
Ә соң нишләргә?!
Мин учакка таба шуышам...
...Тик бер генә күмер...
бер күмер...
учларымда чыкты куыштан...

Кайнар күмер кайнар учымда.
Куллар әрни,
җаным сөенә.
Тау-ташларны кичәм,
кыялар,
шул күмерне тоткан көенә.
Учларымнан төшеп китә ул,
эзләп табам,
төшә яңадан...
Кайнар каным кайнар күмер күк
учларыма тама ярадан.
Бар да артта!
Туктыйм.
Учларым
гел җәрәхәт,
пешкән ит кенә.
Бөтен тәнем янсын бу утта,
тик, син, утым, дөрләп кит кенә!
Кайнар күмер!
Очкын!
Сүнмәгән!
Учларымда — хәлсез күбәләк...
Сулышымны өреп җан кертәм,
зур могҗиза көтәм чүгәләп.
Утлы күмер менә учымда.
Бар өметне шуңа тупладым.
Кабызасы иде бу Җирдә
якты утлар,
тормыш утларын!
Күбәләгем сүнми, җанлана,
канатларын суза чыбыкка.
Ут кабына!
Үрли!
Яктыра!
Минем утым мине җылыта!

Мин кабыздым Җирдә бер учак.
Менә яна, менә терелә.
Караңгылыкны куа яктылык,
җылы керә салкын тәнемә.
Ярсып-ярсып яна учагым,
чаткылары — кызыл күбәләк.
Ялкынында яшәү яктысы,
нурлар менә күккә үрмәләп.
Битләремә җылы сирпелә,
ялгыз җанны илһам иркәли.
Янар учакларның ялкыны
кешегә дә күчә микәнни?!
Чыбык өстим,
утка көч керә,
күтәрелә,
яна,
яктыра...
Әй гүзәл ут,
тугры юлдашым,
җылы да күп синдә,
якты да!
Бер кечкенә генә учагым.
Үзем таптым,
яктым,

ал, Җирем!
Кем ул анда утсыз тилмерә,
туганымдыр әле син минем?
Кил!
Кулыңны җылыт ялкында,
бер яктырып китсен йөзләрең.
Кемнәр туңа,
кемнәр адашкан —
чакырып кил монда үзләрен.
Сез кем?
Сабанчымы?
Эшчеме?
Балыкчымы?
Шигырь язучымы?
Барыгыз да монда килегез —
тормыш өчен Җирдә янучы.
Мин ут бирәм сезгә.
Яңадан
җылы, якты булсын Җиребез.
Ут өләшәм,
Җирнең уллары,
ут өләшәм,
монда килегез!

***Якты Җир***

Җирем буйлап китте яктылык,
Җирем буйлап утлар тарала.
Җирем буйлап карап барам мин:
балкыш күрәм, кая карама.
Әнә ГЭСлар тагын ут ясый.
Заводларда корыч коялар.
Яшь галимнәр чуен өстенә
лазер белән чәчәк уялар.
Академик — Казан егете —
плазмага карый шашынып;
ун мең градуслы тузаннан
кояш ясап ята ашыгып.
Кран башларында ут яна.
Тәрәзәләр якты, балкыган.
Балыкчылар уха пешерә.
Күз текәгән шагыйрь ялкынга.
Авыл миче тулы кабартма.
Казаннарга шулпа салганнар.
Печәнчеләр бүген кайтмаган,
учак ягып куна калганнар.
Җирем буйлап карап барам мин:
Җирем буйлап күпме ут яна!
Утлар белән матур бу тормыш,
утлар белән яши Җир-ана.
Без кабыздык тормыш утларын,
үлем уты поскан, без — сакта:
тик Җиребез яна күрмәсен,
дөрләп янсын утлар учакта!

«ГАМЬ» китабыннан
(1972 — 1974)
II
*Күкләргә сыймас моңнарыбыз*

*чуерташка иңгән.*
*Су төбендә ята аһ-зарыбыз,*
хисләр ярга сеңгән.

1969 — 1970

## Көрәш

Алыр-алмас торган чагың була,
кузгалуы авыр, бик кыен.
Беренче кат син көрәшкә чыккан,
тирә-якта халык, зур җыен.

Чамаң булса, кыюлык та кирәк,
үз остасы бар бит һәр эшнең.
Көчле урынын көчсез кереп алса,
дөреслеге бетә көрәшнең.

Үз көчеңә үзең ышанмасаң,
ташла да чык, үзеңә үпкәлә.
Мәйдан ташлап чыккан егетләрдән
бер көлә дә халык, үткәрә.

Бу көрәшләр синеке түгел икән,
сындырырга нигә билләрне?
Башка мәйдан, башка көрәшләр бар —
көтеп тора үзенең ирләрен.

Сагызланып билгә ябышканны
торалмаслык итеп атырлар...
Сабыр итә белә, ега белә,
егыла да белә батырлар.

1972

## Кырым сукмаклары

Горький сөйгән Ливан эрбетенең
күркәләре минем учымда.
Заманасын чирдән терелтәм дип,
Чехов йөргән икән шушында.
Дулкыннарга баксам,
Такташ күзе,
Такташ чәче килә хәтергә.
Чуерташка басып бара әнә
Руфигына нидер әйтергә.
Бер диңгезгә,
бер тауларга карый,
кая куйсын авыр уйларын...
...Болдырына чыккан Ибраһимов,
күрә мәллә кайтыр юлларын?
Монда килеп Пушкин зарын язган,
Толстойның исән имәне.
Даһиларның кайсысының гына
язмышына Кырым тимәде?!

Күпме генә дәва булды икән
җаннарына кызыл гөлләре?
...Тау юллары,
ничек тар булса да,
олы язмышларның челтәре.
Килүләре бик тә аңлашыла:
нинди өмет,
нинди сагыштан...
Язучылар түгел,
заманалар
хәл сорашкан монда,
табышкан.
Сорагандыр,
дәва эзләгәндер
кемнең тәне,
кемнең җаны да.
Күмелеп ята Кырым сукмаклары
даһиларның кыйммәт данына.

1973

## Сабан туйлары икән...

Сабан туйлары икән.
Кызыгы инде үткән.
Яңгырап тынган мәйдан,
алыш-салышлар беткән.

Басып калган ике ир,
икесе буш болында.
Ике ертык ак күлмәк
ике малай кулында.

Тәгәрәп сугышалар
ике ир — ике ата.
Ике малай — ике дус —
бер читтә үксеп ята.

Сабан туйлары икән...
Киләсе көн ни әйтер.
Ике малай — ике дус —
онытмый торган хәтер.

1973

## Атлар көтте авыл малайлары

Игелеге илгә булыр ирнең,
гаме булса уй һәм хисенең.

***Айгырлар***

Әллә уйнап, әллә безне сынап,
әллә дулап чаба бу атлар.
Зилзиләдә басып торабыз күк,
егылышып ята зуратлар.

И ыргылды атлар басуларга,

тышауларын өзеп чаптылар.
Бәкәлләре сынып-сынып кала,
күзләрендә — кайнар чаткылар.

Башак очты чәчрәп тояклардан,
тузганаклар калды сибелеп.
Елый-елый кактык тузаннарны,
түбәтәйне алдык иелеп.

Канлы иреннәрне дерелдәтеп,
сәер хисләр белән шашынып,
болгый-болгый өзек тышауларны,
артларыннан без дә атылдык.

Әллә гайрәт, әллә гарьлек инде...
Ир-аты ич без дә дөньяның...
Ничек итеп тыя алдык икән
айгырларның шашып дулавын.

Ат көтүче авыл малайларын
иргә санадылар айгырлар.
Тышауларны тешләр белән ялгап,
чыклар белән кипте кайгылар.

Иблис көлгән кебек кешни-кешни,
ат көтүе кайный тугайда.
Әкиятләрдә түгел, ә тормышта
«таз малай»лар булдык бугай ла.

Гадәт булып калды шул еллардан
егылганда сикереп торырга.
Ир булгач та сәлам биреп үтәм
үзем атлар көткән урынга...

### *Тайлар*

Кырыкмышлар артны чөеп-чөеп,
башны борып ялны торгыза.
Тезгеннәрнең тартылмаган чагы —
кем егылып кала, кем уза.

Батыр итеп тойды безне тайлар,
муеннарын кочып чапканда.
Кешни-кешни алар борылып килде,
без торалмый егылып ятканда.

Без өйрәттек микән, үзләреме? —
кешелекле иде ул тайлар.
...Чигәләрдән чәчне җилләр йолкый,
томырылып кала тугайлар.

Без тайларны (хәтта таякларны)
бер-беребезгә биреп алыштык.
Чабыш дәрте туган яшь җаннарда
узыш дәрте үскән ярышып.

Ат көтүче авыл малаеның
балаклары кибә тузанда.

Тай өйрәтеп,
без өйрәнеп калдык
чабышларда куып узарга.

...Чабышлар да башка,
«тайлар» башка,
бормаланып беткән тугайлар...
Кешни-кешни борылып килмәс инде,
без егылып калсак, бу «тайлар».

***Болын***

Баш астымда яшел түшәк икән,
юрганым да яшел икән... дим.
Кочагында ятып,
бу болынны
төштә күреп ятам икән мин.

Утлап йөри атлар керт-керт итеп,
дулкынлана учак... чайкала.
Без болай да иләс малайлар бит,
томаннарны, җилкәй, айкама.

Өндәгесе төшкә керми булмас,
тугайларда аунап туймасаң.
Малайлар да даһи булыр кебек,
бу болында ятып уйланса.

Таң алдыннан яшьти әкият сөйли:
бик бәхетсез булган шаһзадә...
Шушы таңнар терелтерләр иде,
шаһлар мине дарга асса да.

Утлап йөри атлар керт-керт итеп,
чалкан ята чандыр малайлар.
Ат көткәндә барлык йолдызлар да
көтүчегә карап яналар.

Бу минеке, бу синеке, диеп,
йолдызларны бүлешеп ятмадык.
Бөтен күкне кызык китап итеп,
серле шигырь итеп ятладык.

Үтеп барган малай вакыт түгел,
безнең туу иде ул чаклар.
Йолдызларны әле һаман саныйм,
йөрәгемдә яна учаклар.

Күге-ние белән сеңгән болын,
коеп куйган кеше түгел мин.
Җырга салып җырлап бетерә алмам
ат көтүче малай күңелен.

Сәерсенеп безгә карамагыз,
сорамагыз бәхетем турында.
Безнең җаннар сихерләнеп бетте
атлар көтеп ятып болында.

1972

## Юлда үскән арыш

Серкәләнеп уйный кырда арыш...
Туган йортка әле кайтып барыш,
бераз сагынып, бераз сагындырып,
үрәчәдән аяк салындырып.

Гаярь атлар каты басып бара,
тимер арба тирән эзләр сала...
Көпчәк үткәч, арыш торып кала,
торып кала, ләкин башы кара.

Юлда үскән башак шуңа дучар:
дегет белән буяп уза күчәр.
Әллә буш син, әллә тулы җелек —
арба күчәрендә җитә дегет.

Бергә-бергә бер келәттән чыккан,
кайсы кырда, кайсы юлда шыткан;
бусы юлга төшсен дип сайламый
чәчкәндер лә кеше абайламый.

Орлык булып йөктә барасың да,
ялгыш кына төшеп каласың да,
интегәсең чиста башың белән
дегет сөртеп көпчәк арасында.

Каныга бит мәрхәмәтсез язмыш,
бер башакта ничә арба сагыш!
Серкәләнеп уйный шул ук арыш,
дегет сөртеп тора шул ук арыш.

...Бераз сагынып, бераз сагындырып,
үрәчәдән аяк салындырып,
кайтып барыш төрле уйлар уйлап,
арыш башын дегет белән буяп.

1973

## Күзгә карагыз

Туры итеп, нурлы итеп карый, —
бусы карый чынлап.
Күзен кысып, мәрхәмәтле карый, —
бусы карый сынап.

Күзебезгә карый юмакайлар,
карый алдакчылар.
Усал итеп караучылар була:
өнне алмакчылар.

Усалына без дә усал итеп
карап үткәрәбез.
Бик тырышсак, авыр карашны да
җиңел күтәрәбез.

Йөрәкләргә текәп карау була, —
буйсындыра хәтта.
Бер карашы өчен кылган эшең
сыймас шәригатькә.

Куркам, шүрлим,
нишләргә дә белмим,
аңламыйм да:

бик ваемсыз сыер күзе булса
кеше маңгаенда.

1974

## Без синеке инде

Авыр димим сине,
җиңел димим,
үлчәп булмый сине, Замана.
Еллар белән яшьләр картаялар,
яшьләр белән еллар яңара.

Мәңгелеккә үтеп бара торган
кешелекнең без бер буыны.
Алып кара,
өзеп ташлап кара
чылбырдагы безнең урынны!

Тамыры юк,
ябыштырган җире,
ялгавы юк,
җөе юк аның;
кешеләрне бүлеп була әле,
бүлеп кара халыкның җанын!

Төзәп атты дошман:
дөмегәсең!
Илең ирсез кала...
Әтиләр
«Улларыбыз!» дигән соңгы сүзне
Илне — безне уйлап әйттеләр.

Бөтен илне урап,
бура бурап,
йорт-сарайлар салып кайтасы.
...Бүрәнәгә чапкан килеш калды
яңа кайрап куйган балтасы.

Хан-хакимнең зиннәт-нигъмәте дә
аера алмас иде басудан.
...Камыт агачлары шартлап сынды,
атлар пеште юлда... ачудан.

...Төзүчеләр китте — балта калды,
игенчеләр китте — буразна.
Шагыйрь китте —
каралары кипте;
төер торып калды бугазда.

Ниятләп тә
эшләнмәгән эшләр,
васыятьләр, теләк, хыяллар —
сабыйларга.
...Безнең белән бергә
бишекләргә ничек сыйганнар!

Иркәләргә үрелеп алыр өчен
алар инде кире кайтмады.
Бишекләрдән үзебез төшеп җиктек

туарылып калган атларны.

Мәңгелеккә үтеп бара торган
кешелекнең шушы буыны
алып тора
халык тарихында
бер чылбырда ике урынны.

Берәр йорт ким,
бер буразна,
берәр
шигырь кимдер безнең исәптә...
Бик беләбез аны,
тик иң элек
ни эшләсәк,
нәрсә дисәк тә,

этиләрнең сүзен әйттек башта;
алар кылмый калган гамәлне
кылгач кына,
үзебез кара ясап
мандык үзебезнең каләмне.

Без синеке инде,
син — безнеке;
тоеп тора сине җилкәләр...
Артыбызда калды суык җилләр,
каршыбызда нинди җилкәйләр?!

Авыр димим сине,
җиңел димим,
үлчәп булмый сине, Замана.
Утыз яшькә җиткән егетләрнең
икенче кат чәче агара.

1973

## Граф паркы

Агачларның шаулауларын
мин тыңлыйм.
Колакларым нигә болай
бик чыңлый.
Бу бакчаның сөйләшүе
ник шомлы?
Чинарларның чайкалуы
ник моңлы?
Күзләремне йомып ятам
аптырап.
Күз алдымда кемнәр йөри
калтырап?

Кая үтә, кая бара
бу кәрван?
Һәрбер адәм әлсерәгән
һәм арган.
Барысы да яланаяк,
яланбаш.
Ертык ыштан. Калган төшләр
ялангач.
Бар да кара, бар да шушы

җир кебек,
бар да пычрак, адәм түгел,
җен кебек.
Биттән-баштан ага кара
тирләре.
Хатын-кызлар елап арган,
ирләре
тешен кысып сукмагына
караган,
авып кала кайсылары
арадан.
Кара туфрак тулы кәрзин
җилкәдә,
көндез ташый, кич тә ташый,
иртә дә...
Ай-Петридән чыга кәрван
тезелеп.
Килә-китә, бер дә тормый
өзелеп.
Туктап булмый, тиз төшәләр
артыңа.
Туфрак кирәк, туфрак граф
паркына!
Таш чыгара, ташлар вата
кәйләләр.
Кәрван һаман әйләнә дә
әйләнә.
Җирдә ятып тыңлыйм бакча
шаулавын.
Ясаганнар ташып Кырым
тауларын* .
Юкка гына чинар моңлы
түгел лә:
күп кешенең моң-зары бар
төбендә.

1973

## Араукария*

Сокланыпмы, әллә мактаныпмы —
кайтарганнар ерак җирләрдән.
Ләкин алар Кырым туфрагында
әсир булып тамыр җибәргән.

Ылыслары корып-корып төшкән,
үзәкләре кипкән авырып.
Күпме генә кадер итсәләр дә,
китә алмаганнар савыгып.

Араукарияләр арасыннан
берсе генә җанын саклаган.
Йөз ел яшәп хәтта анысы да
бер тапкыр да чәчәк атмаган.

Ышанасы килми:
йөз ел яшәп...
бер бәләкәй куак кадәр ул.
...Безгә түгел,
димәк, агачка да

туган җирсез яшәү хәтәр ул.

1973

## Игенче

Һәр чәчәкнең була үз даласы,
чүп-чарның да була үз кыры.
Кошларның да әнә җырлары бар,
һәр адәмнең була үз җыры.

Берәүләрнең җыры шәһәрдәдер,
берәүләрнең күктә — югары.
Берәүләрне йорты бәхетле итә,
берәүләрнең бәхете — юллары.

Һәркем җырлый:
маңгай тирен сөртеп;
йодрык болгап;
көн-төн утырып...
берәү җырлый эчтән генә сызып,
берәү җырлый авыз тутырып.

Көлеп җырлый
яки елап җырлый...
Мыек астыннан да мырлыйлар.
Адәм күпме, —
шуның кадәр көйгә,
шуның кадәр җайга җырлыйлар.

Минем җырым — кырда башак шавы,
елы-елы белән үзгә ул.
Ишетелмәсә,
югалган җыр булып
үзәкләрне кайчак өзә ул.

Үзегезнең җырны җырлагыз сез,
моңнарга бай безнең замана.
...Уҗымнарга карап яшәрәм дә
көтә-көтә чәчем агара.

Күңелләрем ташый дәрья сыман,
килгәнмен күк мәңге яшәргә.
Мәңгелек җыр кебек
башакларым
басуларга мине дәшәләр.

1972

***

Чәчәкләрдән күп нәрсә юк монда:
алы, агы, кызыл, сарысы...
Җанга ләззәт бирер өчен икән,
безнең өчен икән барысы.

Үзем нидер өнәмичә йөрим,
бутый мәллә чәчәк хисләрне?
Розаларны исним, розаларга
каян килгән шомырт исләре?!

1973

***

Башак шавы — тәүге бишек җырым,
камыл — түшәк,
болыт — юрганым.
Туган көннән алып бу кырларга
мин битараф һәм чит булмадым.

Әни өйгә кайтып җитә алмый
кырда тапкан мине, камылда.
Ана сөте белән туган туфрак
туган көннән алып канымда.

...Ул тапкан да мине, аңын җуйган:
газаплары бераз бүленгән.
Иген үсә торган туфрак кына
саклап калган, ахры, үлемнән.

Һушын җыеп, бер имезгән мине
буразнадан алып кулына.
Кодрәтләре чиксез булсын дипме,
Кадыйр* исемен кушкан улына.

Үләргә дә риза, дигән әни,
күрә алсам тик бер көлгәнен.
...Көлеп яткан урыннарым исән,
мендәр итеп арыш көлтәсен.

Ул борчыла һаман,
нинди уйлар
бимазалый күңелен ананың?
Бәхетләре тулы булмыймы соң
буразнада туган баланың!

...Ак мендәрдә түгел,
әни мине
тапкан камылларда тәгәрәп.
Шуңа күрә җир үзенә тарта,
буйларыма кадәр тәбәнәк.

1972

## Кара диңгез

Ярларыңа килеп төшү белән,
хәтерләттең туган ягымны.
Зәңгәрлегең безнең яклардагы
кызлар күзе кебек ягымлы.

Көннәремнең ямьле чагы иде,

тагын матуррак иттең син.
Анам күңеледәй чиксез бугай,
анам күңеледәй иркен син.

Төпләреңә төшеп җитә алмыйм
катлам-катлам суың аркылы.
Синең белән ярыша алыр бары
тирәнлеккә атам акылы.

Сине танып, сине аңлар өчен
үз холкыңны башта бел икән.
Карап тордым давыл вакытында,
син бит минем белән бер икән.

1973

## Яулык болгаулары

Безнең авыл тау астында ята,
мендәредер тауның итәге.
Үргә менгәч, борылып карый-карый
яулык болгый чыгып киткәне.

Болай гына болгый, берәр айдан,
берәр елдан кайтыр, әйләнер...
Яулык болгау хәзер ныграк итеп
сагыныр өчен матур хәйләдер.

...Ә ул көнне без туарга калган,
кызыл яулык болгап киткәннәр.
Киткәннәр дә...
кайтып булмый торган
урыннарга барып җиткәннәр.
Газиз җанны туфрак иткәннәр.

Мираслары — тормыш — серле сарай,
кулыбызда алтын ачкычлар.
Авылыбызның биек үре кебек
һәйкәлләргә илткән баскычлар.

Сау бул, дисәң, — безнең үрләр биек,
кайтам дисәң, — безнең юл такыр.
Алардан соң яулык болгап китеп
кайттылар бит инде күп тапкыр.

Онытырлык юкса вакыт үткән,
киткәннәрен без бит күрмәгән.
Йөрәкләргә тия яулык очы,
болгасалар шушы үрләрдән.

1973

## Кибәнче карт

*(Баллада)*

**1**

Гайрәтләнеп һәм яшәреп кырга килде,
бер нечкәрәк эскерт кенә салыйм, диде.
Аптырашып карап торгач, агай-эне

кибәнчегә кыска саплы сәнәк бирде.

Ыспай булып үсә эскерт, тигез, шома.
Карт кибәнче егет сыман басып тора.
Җыелышкан бу кырдагы барча халык,
тынган басу, карый басу хәйран калып.

Очланды эскерт. Карт кибәнче дәште өстән:
«Соңгы көлтә! Бер көлтә дә сыймый бүтән!»
...Сәнәк төште әкрен генә шуып күптән,
астагылар эзләделәр картны күктән.

Азга гына, ял итәргә генә ятты:
«Бу һавалар, бу күк йөзе бигрәк якты...»
Уйга салды картны гомер агышлары,
моңсуланып көзге кояш баешлары.

*

«Унсигез яшь... егерме яшь... кырык... илле...
без бик озак яшәгәнбез икән инде.
Бабагызга алтмыш тулды... җитмеш... сиксән...
Дөнья матур, матур итеп гомер итсәң.

Соңгы көннәр инде орчык төбен сүтә.
Узган гомер хәтеремнән кабат үтә.
Ул язларым яңаралар уҗым сыман,
унсигездә егет булып басып торам.

Яшь гомердәй җирдән яшел чишмә ургый,
кырда безнең хисләр кебек серкә уйный.
Юллар сыман ерак китә пакусларым,
бергә туктап чалгы яный бар дусларым.

Атлар сыный, ятлар сыный — түземнәрме? —
Чорнап-чорнап тоткан чаклар тезгеннәрне.
Атка менсәк — үзебездәй ябь-яшь тайлар,
ябыбызда ябь-яшь кызлар — сөйгән ярлар.

Җәйләр әнә килә-китә уйнап-көлеп...
Безнең яшьлек иксез-чиксез басу кебек.

*

Менә көзләр килде тагын сабырланып,
нурлар тулды башакларга сарыланып.
Без береккән бу кырларга тамырланып,
күңел тулды ир чагымны танып алып.

...Учларымда моңлы кыллар — сары камыл.
Чыңлап тора: урак белән генә кагыл.
Каерып-каерып урак урам чын ир булып,
көлтәләрем тәгәрәшкән басу тулып.

Кайнар һава, кайнар сулыш, кайнар урак...
Ирләр алган басуларны урап-урап.
Башак уйный, учма уйный, көлтә уйный,
билләр ара, куллар ара, җаннар тынмый.

Уйный урак камылларны өзеп-өзеп,
сала куллар учмаларны тезеп-тезеп.
Моңлы көйләр,
моңлы җырлар сузып-сузып,
бара ирләр берсен-берсе узып-узып.

Чыңлап торган камылларым,
уракларым —
минем чыңлап узып киткән ир чакларым.

*

Кибән салган агай-энем, нәсел-нәсәп,
бәхет тапкан көлтәләрдән таулар ясап.
Сиксән яшьтә эти соңгы тавын өйде,
очлады да: «Менә күккә аштым», — диде.

Шуннан бирле миңа җитте инде чират,
«Атаң кебек күкләргә аш»,— диде ир-зат.
Кешеләргә бәхет юрап салдым кибән,
беркайчан да, гомер зая үтте, димәм.

Башы башта, иңе иңдә, биле билдә,
сыенышып, кочаклашып ята көлтә.
Көлтә өям — өмет өям, бәхет өям,
почмагы нык, нигезе нык — куям кибән.

Күтәреләм хозурлыктан хозурлыкка,
көлтәләргә басып менәм бу зурлыкка.
Әйтерсең лә бу кырларга
бер мин башлык,
кибәнемнең эче тулы дәүләт, ашлык.

Офыкларым киңәяләр, күкләр якын,
иркенәя, ачылып китә тирә-ягым.
Минем өчен таңнары да иртә ата,
минем өчен кояшы да соңрак бата.

Соңгы көлтә.
Бер көлтә дә сыймый бүтән...
Ничә мендем, һич төшәсе килми күктән.
Кибәннәргә басканым юк иде күптән,
кибән куяр заманалар үтеп киткән...

Күңел уйный әллә нәрсә көтә-көтә...
Бу гомерләр әнә шулай көлтә-көлтә».

**2**

Эскертендә карап ята күккә туры,
йөзләрендә — баеп барган кояш нуры.
Күккә карап чалкан ята, йөзе көләч,
сөенечләре кимемәгән, хәтта үлгәч...

Аптырашып, көрсенешеп торды ир-ат:
күккә ашты кибәнче карт — илаһи карт.

1973

## Кар сулары

Үзәннәргә ага кар сулары,
безнең гомер ага үрләргә.
Бер гомердер үзе бер сулавы
адәмнәргә язгы көннәрдә.

Серле дәрвиш кебек йөри кеше,
башы горур, чиста күңеле.
Язгы көннәр җиткәч,
хастаның да
китеп тора ди бит үлеме.

Кар сулары ага безнең аша,
арынадыр кеше мәкердән.
Кимсенүләр, үчләр онытыла,
явызлыклар чыга хәтердән.

Бетә шикләр.
Якыная читләр.
Суда эреп ага ачулар.
Без тапмаган олы мәхәббәтне
алып килер сыман ташулар.

Офыкларның күрче киңлекләрен,
ачылып киткән кебек галәмнәр.
Кулда — куәт,
җанда гайрәт арта,
уйда туа олы гамәлләр.

Барысы да хәлдән килер кебек,
кытыклана йөрәк,
азына...
(Каләмеңне дәрьяларга ман да,
көн дә бер поэма яз гына.)

Язлар килә бөтен ямьсезлектән,
гамьсезлектән безне биздереп.
Әле гомер яңа башлана күк,
бөтен дөнья тулы изгелек.

1973

## Озату

Пристаньнар ярга ятып кала,
елый-елый китә пароход.
Бара-бара үксеп-үксеп ала,
кайтмаска ук китеп бара күк.

Безгә кирәкләрне алып китә,
кирәкмәсләр кала сөялеп.
Үзе белән бергә бар сагышы
нигә китми икән төялеп?!

Күпме озаттык инде, күпме киттек,

ник күнегеп булмый бу хәлгә?!
Гомер буе сыкрар яра булып
 яралганбыз микән без әллә?

Кемгә китү, кемгә калу кирәк —
без беләбез моны икебез.
...Бәгыремнең исән җире булса,
тагын телеп алып китегез!

1972

## Давыл

Ярсуларым җаннан ашкан вакыт,
карыйм дулкыннарга.
Кем өйрәтте икән сине, Кама,
болай сулкылдарга?

Дулкыннарың ярга сыя алмый
тузган, үрә торган.
Салларыңны, гашыйк хыялы күк,
җилләр ярга орган.

Төптән, эчтән суың актарыла,
күктә — яшен, болыт.
Сызаларың ярда ярылып ята
тоташ яра булып.

Ургый-ургый суда күбек кайный:
төште яшен ташы.
Күк дулкынга чумды,
дулкыннарың
тәмам күккә ашты.

Сары, кызыл, кара маякларың
сүнә-сүнә бата.
Ярыңдагы гашыйк җаны кебек
җаның дулап ята.

1972

## Давылдан соң

Көрәштән соң кеше шулай була,
ашкынулар кинәт тынмыйлар.
Сабантуйда чабып килгән атны
йөрүенә карап таныйлар.
Кибән өеп кайткан ирләр кебек
чалкан ята Кама ухылдап.
Чабышкы күк тынычлана алмый
ак күбеккә баткан дулкыннар.
Җилләр китте,
давыллары үтте,
ник дулыйсың, елгам, тынычлан.
Кемнәр аңлар сине?
Яшәү өчен
тыныч акыл кирәк, тыныч кан.

1973

## Саллар

Салмак саллар ага, дулкыннарның
чәчен тарый-тарый.
Бәхетлеләр салда учак яга
күккә карый-карый.
Басып торам ярда бу дөньяның
гамен уйлап-уйлап.
...Әй эзлибез яшәү рәхәтләрен,
җирне иңләп-буйлап.
Салдагылар, и-и, бәрәңге ашый —
тозга мана-мана.
Бу җиһанның бар ләззәтен җыеп
салмак саллар ага.

1972

## Бозлар

Китә бит, әй,
сулар ургып кала...
Кама киңлекләре — ирек бит.
Гранит сыман тоташ бозга карап
сәерсенеп торган идек бит.

Быел бозлар шундый калын иде,
кем уйлаган кинәт китәсен...
Аккан бозга карап тора-тора
офыкларга барып җитәсең.

Боз белән дә кыен саубуллашу,
томанланып тора күз алды.
Җанымда да, ахры, бозлар булган,
барысы да эреп кузгалды...

1972

## ***

Үрсәләнеп, үпкәләшеп,
үртәлешеп арыдык:
син дә мине, мин дә сине —
үзебезне таныдык.

Төчеләнеп, көнчелләнеп, —
көчсезләнеп ни файда!
Икебез дә исән-имин,
мин Кояшта, син Айда.

...Өченчебез юкка чыкты —
мәхәббәтебез кайда?

1973

## Тантаналы сагыш

Каршыларга килә монда кеше,
килә озатырга.
Сагышлары ярга ятып кала,
кичләр уза тора.

Уйга калып килә монда кеше,
килә күңеле тулып.
Берәү килә өметләрен өзеп,
берәү гашыйк булып.

Якыннары барлар сирәк килә,
килә ялгыз калган.
Ярга басып су төбенә карый
хисләреннән арган.

Ярдан ерак йөри көләч кеше,
җырлап, уйнап, көлеп...
Чуерташка башын салып ята
бер фәкыйрең бөлеп.

Инде монда азмы моң түгелгән,
азмы кеше зары...
Без ташыган сагышларга түзми
ишелеп тора яры.

Болар безнең кара сагыш түгел,
татлы, назлы моңнар.
...Чуерташлар тезеп җырлар язам,
безнең күкләр тыңлар.

Аерылышу, сагыну газаплары —
дулкын кочагында.
Гашыйк җанның хыял канатлары —
тирәк очларында.

Күкләргә сыймас моңнарыбыз
чуерташка иңгән.
Су төбендә ята аһ-зарыбыз,
хисләр ярга сеңгән.

Шуңа күрә моңлы да ул Кама,
безнең моңнар бер үк.
Аны тыңлап һәм үземне тыңлап,
ярда ятам ереп.

Дулкыннарга карап бер җырласам,
бер моңайсам инде...
Беләм: яры, суы, салы белән
туктап тыңлар мине.

Без — моңлылар.
Тик мин аңа түгел,
ул охшаган миңа.
Яры, суы, салы, моңы — бергә
йөрәгемә сыя.

Горур башны артка чөеп торам...
Моңлы безнең язмыш.
Йөрәгемә кага җылы дулкын —
тантаналы сагыш.
Тантаналы сагыш.

1972

***

Кабатлама, кат-кат төшендермә,
хәлләреңне аңлыйм.
Минем өчен янып көлләр булдың,
ә мин дөрләп янмыйм.

Үзәгемә, йөрәгемә үтә
мәҗнүн карашларың.
Адәм генә үзең, дөнья белән
барыбер санашмадың.

Тормышыңны тотып утка аттың
белә, күрә торып...
Елавын да елый беләсең син
аягүрә торып.

Әй бу ирлек! Ташлап бөтенесен,
мин бер юләр булсам,
юк, син түгел, ә мин синең өчен
янып үләр булсам...

Без бәхетле булыр идек, шаять,
бик тә озакка...
Мин башымны иям, ә йөрәгем
биктә, йозакта.

1974

## Язмыш

*Еллар буе дәшми тилмерттең дә,*
*менә хатың ята өстәлемдә:*
*газапларны бераз киметтең дә,*
*газапларга газап өстәдең дә.*

Кошларның да тала канатлары
берсен-берсе эзләп табышканчы.
Кешеләрнең сөеп-яратканы
аерыла икән кавышканчы.

Бара-бара озын гомер буйлап
һаман ерак, һаман ерак китә.
Яшьлегендә калган ярын уйлап
гомер итә һаман —
гомер үтә.

Тыйнак кына кайчак күрешәләр —
чит кешеләр диеп уйлап була.
Бер елга бер ялгыш үбешәләр
бер-береннән оялып,
урлап кына.

Үзләре дә кайчак аңламыйлар,
әллә нинди чиргә сабыштыра.
Ике елга бер хат алгалыйлар,
күзләрендә тере сагыш тора.

Ялгышалар куркып ялгышлыктан
ялгышмаска вакыт бар чакларда.

Интегәләр авыр ялгызлыктан
загс язып биргән кочакларда.

1973

## Чамалап үт

Без танышлар түгел,
юллар кара-каршы.
Үзең кара кашлы,
туп-туры карашлы —
тишә торган ташны.

Син туры карашлы, —
мин туры карашлы —
танышуның башы.

Син карап үтәсең, —
мин дә карап үтәм;
син шуны көтәсең,
мин дә шуны көтәм.
Күзләрнең сүзе бар,
сөйләшәләр күптән.

Алар нидер күрә,
алар нидер белә.
Без дәшмибез генә
менә шуңа күрә.

Без танышлар инде,
без танышлар инде:
зинһар, чамалап үт.
Тик бер елмайсаң да,
ялгыш елмайсаң да,
әллә нишләрмен күк.

Инде хәзердән үк
әллә нишләдем күк.

1973

## Йөрәгең яна торсын

Кузгалды инде күңел,
басыла торган түгел
ашкынуы җанымның.

Син минем хыялымдыр,
тапсам да җуярымдыр,
каян күзгә чалындың?

Көткәнен таба бәндә...
Сөйгәндә-сөймәгәндә
эзләмиләр ялгышын.

Башыңны түбән имә,
үтәр дә китәр димә,
бу — аяусыз язмышың.

Янган утка салырмын,

үземнекен алырмын,
мин сине таптым инде.

Барыбер яратырсың,
йөрәгең яна торсын, —
утларын яктым инде.

1973

## Миләшле йорт*

*(Җыр)*
Купшы төннәр,
җәй башлары —
җәй җиләс.
Чәчәк ата
өй каршында
яшь миләш.

Тәрәзәгә
яткан чук-чук
тәлгәше.
Тәрәзәдән
карый кемнең
кәләше?

Ике өлге
ике якка
ачылды.
Кыз егетне,
миләш кызны
качырды.

Өлгергәнне
кемнәр алмас,
кем алмас...
Буламы туй,
булмыймы туй —
кыз калмас.

Җәй калса да,
көз калмас.

Ничек китәр —
уйнап микән,
уйлапмы?
Туйлап микән,
әллә читән
буйлапмы?

Китәрсең шул,
калалмассың
һуш килгәч.
...Миләшкәең
белән тагын
бер киңәш.

Тәрәзәдә
чәчәкләре —
тәлгәшләр.

Бик күп булыр,
әче булыр
миләшләр...
1973

## Югалткан,
## тапкан чагым

**1**

Әле һаман яфрак яшел икән,
миңа сары кебек тоела.
Бу арада әллә нишләп торам,
йөрәгемнән яфрак коела.

Әле һаман кошлар сайрый икән,
ник китсеннәр алар җәй булгач...
Канатларын салып, дәшми-тынмый
йөрәгемдә ята сандугач.

Әле һаман таңнар якты икән,
миңа бетте җәйнең ямьнәре.
Йөрәгемә эреп тама-тама,
шәмдәлләрнең сүнә шәмнәре.

Читлегендә талпына җаным:
мәхәббәтне югалткан чагым.

**2**

Кай арада үтеп китте җәйләр,
агач яфрак коеп өлгергән.
Бу йөрәгем әллә нишләп тора,
яфрак ярып ята бөредән.

Сандугачлар талдан күптән киткән,
ни арада килгән бу кышлар?
Йөрәгемдә канат җилпи-җилпи
китә алмый калган пар кошлар.

Бөтен җирдә боз һәм кар салкыны,
җылы нурлар ничек сүнмәсен?
Йөрәгемә якын килә күрмә,
орынсаң да янып үләрсең.

Лачын кебек биектә җаным:
мәхәббәтнең исән-сау чагы.

1972

## Үзәннәрдә калды
## томаннар

Юлсыз җирдә кая барырсың,
алларыңа төшсә томаннар?
Адашырга тиеш идек без,
без — томанлы елда туганнар.

Ераклардан кемнәр дәштеләр:
туктамагыз гына, оланнар...
Дулкынланып алды томаннар,
сыегаеп китте томаннар.

Берәм-берәм чыктык без юлга,
бергә-бергә бара торганнар.
Күтәрелеп киттек үрләргә,
үзәннәрдә калды томаннар...
Артыбызда калды томаннар...

1973

***

Бу юллардан инде азмы узганнар.
Калган әле без ерасы тузаннар.
Юлларының, сукмагының җае бар, —
һәр адәмнең Кояшы бар, Ае бар.

Без сөрәсе, без чәчәсе басулар,
без эчәсе, без йөзәсе бар сулар.
Үтелмәгән-сүтелмәгән Күк әле,
сулыйм дисәң, анда һава күп әле.

Ал таңнары аткан чакта чыкланып,
ал чәчәкләр аткан чакта чукланып,
кыяк саен, бөре саен тукталып,
йөрисе бар онытылып, сокланып.

Озын гомер, аек акыл, таза тән...
Мәхрүм түгел шатлыгыннан, газаптан.
Күздә төсләр, җанда хисләр, телдә тәм.
Тормышта ямь, җиһанда ямь, Җирдә ямь.

Җырлап тора, уйнап тора күңелләр,
үткән саен кыйммәтрәк бу көннәр.
Әйләнә Җир һаман саен шәбрәк.
(Чабуыннан тартасы иде әзрәк.)

Моны ташлап башкасына узмак юк,
төгәл беләм: Җирдән гайре оҗмах юк.
Барысы да безгә карап баккан ла,
и җаныем, ташлар чәчәк аткан ла.

Анасының бу кодрәтле баласы
туып, яшәп, мәңге шунда каласы.
Гали җанга тәме дә бар, яме дә,
исән генә була күрсен гаме дә.

«АВАЗЛАР» китабыннан
(1970 — 1979)
III

*Баш киемен талап исә җилләр,*
*пәри тузан ташый туена.*
*Яшьнәп торган агачлардан өзелеп*
яшел килеш яфрак коела.

1973 — 1974

## Шигырь

Уйларымны нидер сихерләгән,
бөтенләем белән сихерле.
Үземне-үзем сихерләдем мәллә
сихерсез дип йөреп шигырьне?

Һәр тарафтан җырлар, моңнар килә.
Барысы да якын, илһамлы.
Әллә дөнья,
әллә үзем сәер,
аңлап бетерә алмыйм бу хәлне.

Гадиерәк берәр нәрсә бармы?
Барысы да миңа илаһи.
Дөньяның бар ишекләрен ачып
алып керә шигырь,
и даһи!

Уйларымны нидер сихерләгән,
үләмени кеше сихердән?
Авырырга да мөмкин,
терелергә дә,
үләргә дә мөмкин...
шигырьдән!

1970

## Һәйкәлләр

Үзенә үзе динен тапкан кеше.
Халыкларның гомер-гомердән
йә суларга карап,
йә күкләргә,
йә ташларга башы иелгән.
Исәннәргә имин гомер юрап
юкка чыга торган корбаннар.
Дөреслекне әйтеп бирә алмый
ташлар аптырашып торганнар.
Кодрәт кирәк.
Илаһи рух кирәк,
илһам кирәк һәрбер эшеңдә.
Аллаларга кеше кирәк түгел,
Алла кирәк икән кешегә.
Без сыннарга корбан китермибез,
корбаннарны изге сын иттек.
Көрәшләрдә Аллабызны табып,
табынуларны инде чын иттек.
Алар безнең идеал корбаннары,
язмышыңны туры әйтәләр.
«Ианауың нықмы?» дигән сыман
күзебезгә карый һәйкәлләр.
Илен саклап җанын биргәннәрнең
һәйкәлендә — Кояш,
нур үрчи.
Табынам ташка!
Безнең динебез шул.
Бөтен илебез белән мәҗүси!

1977

## Картлар

Җиңел чагы туры килмәгәнгә,
онытылмаган әле авыр чаклар.
Зарланмыйча гына дәшми йөри,
хәтер бетте, диеп,
тыйнак картлар.

Үз гомере белән үлчәп карый,
сынап карый:
болар нинди затлар?
Нәрсә бөркәнсәк тә безне таный,
заманны таный
сизгер картлар.

Төскә түгел,
алар төпкә карый.
Нигә сүзләр,
нигә ялган антлар!
Эшебезне,
үзебезне аңлый,
заманны аңлый
зирәк картлар.

Үзләренә әле без түлисе
онытылмый торган олы хак бар.
Үзләреннән туган изгелеккә
рәхмәт укып йөри
сабый картлар.

Кер булганга түгел,
сер булганга
гүргә кадәр, бәлки, әйтми саклар.
Оланнарга зыян килмәсен дип,
кирәк булса әгәр,
сабыр картлар.

Карап кына,
санап,
барлап кына
заманны һаман әйдәп атлар.
Әйтерсең лә бер дә яшәмәгән,
бер дә картаймаган
даһи картлар!

1976

***

Кешеләрнең барын танып йөрим,
таянганым бары — ышаныч.
Вакытым белән мин алар күк горур,
вакытым белән мин дә кызганыч.

Бер эшкә дә кайчак кулым җитми,
бар эштә дә ләкин хакым бар.
Башкалар күк мин дә йә гаепле,
башкалар күк мин дә хөкемдар.

Күрми диеп кайчак уйлыйлардыр,

кызганычка каршы, күрәм мин.
Һәрбер туган белән туа торам,
һәрбер үлгән белән үләм мин.

Шуңа күрә мин бер бәхетледер,
үтмәгәнгә гомер әрнелеп.
Шуңа күрә, бөтен кеше кебек,
бу тормышта мин дә мәңгелек.

1978

## Авылдашым

Иң беренче дәрес.
Әлифбаның иң беренче
бите ачылган.
Буйдан-буйга олы, тере итеп
Ленин портреты басылган.
Укытучы безгә карап сөйли.
«Сез, балалар, ипләп карагыз,
авылыбызда аны белмәгән юк,
юлбашчыбыз, Ленин бабагыз».
Язарга да әле өйрәнмәгән,
тел тибрәтеп сөйли белмибез.
Борынын тартып кинәт телгә килде
(Мыштым Хәмит бугай) беребез:
«Ленин бабай безнең авылданмы,
Ленин бабай татар булганмы?
Аның өе кайсы икән, абый,
кайсы урам аның урамы?»
Укытучы озак җавап бирде,
соңгы сүзе истә бүген дә:
«Татарларга шатлык килгәч, Ильич
бәхетле итеп тойган үзен дә.
Гомерендә бер кат күрмәсә дә,
ул сезне дә белгән, таныган.
Ленин бит ул бөтен дөньяныкы,
Ленин бит ул һәрбер авылдан!»

1978

## Әкиятче

Бишмәт кыза апрель кояшында,
нигез кыза,
җылы пар чыга.

...Баш очында яшел тәрәзәсе
ике якка җырлап ачыла.

Тәрәз төбен кысып-кысып тота
табагач күк арык куллары.
Тәрәзәгә башы менгән чакта
шуып төшеп кала юрганы.

Сәкесенә ипләп утыра да,
тәрәзәдә кала ап-ак баш:
ап-ак йөзе белән ап-ак теше,
ап-ак чәче белән ап-ак каш.

Гомере буе хаста,

торса да шул
ни хакына, белмим, тора ала?
Елмая да
безне барлап чыга:
— Килдегез дәмени, оланнар?

Көн дә әкият.
Инде яз башыннан...
Әкиятләр дә озын,
дәвамлы.
Каюм бабай көн дә без килергә
уйлап яткан микән әллә аны?

Һәр көн шулай.
Тоташ язы белән.
Дәрес кала инде димәдек.
Әкиятче дә
безнең белән бергә
тыңлый иде үзен кинәнеп.

Яз беткәндә яшел тәрәзәсе
ачылмады бүтән,
дәшмәде...
Яз җилләре сөртеп алды безнең
керфекләргә кунган яшьләрне.

Миңа һаман яшел тәрәзәләр
яшел әкият кебек тоела.
...Каюм бабай кабере каеныннан
әкият булып яфрак коела.

1977

## Диңгездә таң

Диңгез белән һава бер сызыкта.
Офык яна.
Суда — ал томан.
Шул офыкта миңа ал сарайлы,
ал җәннәтле дөнья бар сыман.
Йоклаганмы диңгез дулкынында,
юынганмы төшеп күгеннән?
Дулкынланып алды ал офыклар —
Кояш чыкты диңгез төбеннән.

...Тамчы тамып калды битеннән.

1975

## Кар шыгырдый...

**1**

Көмеш тоякларын
тугайларга
сузып салган ап-ак тай кебек,
бишегендә —
күктә кырын ята
кичә генә туган Ай, көлеп.

Күктә үзе,
тәрәзәдә күзе:
өйләрендә нишли кешеләр?
...Өйдә җылы.
Тышта һава чатный,
каеннардан карлар ишелә.

Өйдә яхшы,
якты,
тыныч,
җылы.
Һавасында бала тыны бар.
Ике бармак тарта каба йонын —
безнең өйдә лира моңы бар.

Кабасыннан кулын алмый гына,
бер күз ташлап ала бишеккә.
Орчыклары туктап торган чакта,
тәрәзәгә карый,
ишеккә.

Тәрәзәгә нигә карый әни?
Тәрәз артларында кемнәр бар?
Ник ишеккә карый икән әни?
Ник шыгырдый икән тышта кар?

**2**

Берәм-берәм
елдан елга керәм,
узганнарны үтәм сүткәләп.

...И елаган идек үксеп-үксеп,
ник кайтмыйсың, диеп
үпкәләп.

Язмышларның мәрхәмәтсез чагы.
Уйларымнан китми ул һич тә.
Бик караңгы иде
һәм бик салкын,
без бик мескен идек ул кичтә.

Иске табак кебек изелгән Ай —
бозлы тәрәзәдә шәүләсе.
Уйлап арган башын түбән игән,
сәке почмагында гәүдәсе.

Салкын өйдә ике ач бәндә без,
икебез дә елап арыган.
Караңгыда иске шәлен капшап,
иңнәренә барып сарылам.

Кайсы йортлар инде көтеп арды,
үлем белән тормыш килеште.
Яки кайтып,
яки гүргә ятып
өзде ирләр алыш-бирешне.

«Вафат» дигән хәбәр җиңел түгел,
күнәсеңдер күнгән кадәре.

Өметеңне өзми ялгап тора
«хәбәрсез юк» дигән хәбәре.

Әллә кайда сузып-сузып елый —
әллә бүре, әллә эт улый.
Ватык капкаларны кага-кага,
әллә язмыш, әллә җил дулый.

Тышта дөнья тынып торган чакта,
әллә нәрсә әни ишетә.
Сискәндереп сикереп кузгала да
йөгерә-йөгерә бара ишеккә.

Тәрәзәгә килә.
Тыңлап тора.
Тагын ишек биген күтәрә.
Яңа кертеп япкан тоткын сыман,
үз өендә үзе үртәлә.
Язмыш шулай алдамакчы була.
Ышаныр да, барыбер чыгар, ди.

Өй артында, ахры, этләр йөри,
кар шыгырдый,
һаман шыгырдый...

**3**

Мылтык тавышы дисәң,
кемнәр атсын?
Агач шартлый торган суык чак.
Күмерен әни мичтән яңа тартты,
җылы бөркеп җемелди учак.

Орчыклары тынып торган чакта,
оныгына карый — бишеккә.
Моңлы,
серле,
шомлы шыгырдый кар.
Ике күзе күчә ишеккә.
Ике күзе һаман ишектә.

Әллә йөрәк,
әллә кар шыгырдый.
Әллә тышта аяк тавышы.
Бишекләрдә — кече оныклары.
Гомерләрнең үтеп барышы...

«Вафат» дигән хәбәр җиңел түгел,
күнәсеңдер күнгән кадәре.
Өметләрне өзми ялгап тора
«хәбәрсез юк» дигән хәбәре.

Кичә генә туган Ай елмая.
Бишек уйный,
уйный җаныбыз.
Тышта салкын,
булса юрганыгыз,
яңа туган Айга ябыгыз...

1975

## Апрель

Әверелгән дөнья тоташ туйга,
җан иясе тәмам гайрәтләнгән.
Кырык тәүбәң кылдай өзелеп китәр, —
кызлар халкы шундый һәйбәтләнгән.

Кемгә ләззәт, кемгә газап икән,
сагышларга сала шушы язлар, —
баганага муйнын ышкып йөри
капка төпләрендә ата казлар:

өй ишеге һәрчак сак астында,
ана казлар бар да сәке астында.

1978

## Инвалидлар

Өчәү иде алар.
Атна саен
бер үк көнне,
бер үк сәгатьтә
очрашалар мунча ләүкәсендә...
Бу хаҗәт тә иде,
гадәт тә.
Күрешкәндә кырыс битләрендә
балкып ала җыерчыклары.
Алар кергән сәгать —
мунчаның иң
күңелле һәм җылы чаклары.
Шаян сүзләр,
мәзәк,
уен-көлке
бер атна бит инде җыелган.
Шаулап тора ләүкә.
Һич ким түгел
сабан туендагы җыеннан.

Икесенең берәр кулы җитми...
Өченченең аяк бер генә...

Карап торсаң,
бөтен рәхәтләре
әйтерсең шул мунча керүдә.
Икесенә сыңар тазны тотып,
ике кулсыз башта су ташый.
...Салсаң иде берәр чүмеч эссе,
кара мунча түгел,
юк ташы.
Өченчесе тирләп парлап чаба,
күбрәк ача парны,
түз генә!
Ике куллап ышкый аркаларын,
таянган да сыңар тезенә.
Ике куллап ышкый,
үзе көлә:
— Ятыйм мәллә үзем, арсагыз?
Бурычымны түләп бетералмам
булса да, — ди, — туксан аркагыз.

Бу сүз башта сәеррәк иде,
тик соңыннан төштем серенә.
Язмыш шулай бәйләп куйган икән
бу өчәүне берен-беренә.

...Дошман белән бәрелештә булсын,
окоптамы,
ялан кырдамы;
семьяларга язган хатта булсын,
сохарида,
таныш җырдамы.
Бергә-бергә барын уртак итеп,
тыгыз куеп иңне иңнәргә,
көрәшкәннәр алар өчәү бергә,
бергә кайтыйк диеп илләргә.
Дошман белән соңгы якалашу
алар өчен көтелмәгәндә
сәеррәк була,
олы юлның
яртысы да үтелмәгәндә.
Чолганышны өзеп килгән чакта,
ут эчендә,
дөнья купканда,
сул беләген пуля тишеп чыккач,
беренчесе юлда туктала.
Икесенә әле бер ялы...
Салынып төшә кинәт уң кулы, —
өч солдатның инде икенчесе
хәл җыялмый ята бу юлы.
Икесенә ике иңен куеп,
чәйни-чәйни ирен итләрен
сөйрәлгәндә,
тезе яраланып,
хәтерләми һуштан киткәнен...

Ничә минут,
ничә сәгать үткән?
Ике иптәше — ике ялы
аңнарына килә-китә генә
үлем тотып торган араны
аны сөйрәп көчкә үткәннәр дә
үләргә дип хәлсез ятканнар.

Инвалидлар булып кына түгел,
туганнар да булып кайтканнар.
Бүлеп кара, кемгә кем бурычлы?
Язмыш җепләренең очлары...

...Атнага бер мунча ләүкәсендә
гөрли инвалидлар почмагы.

Бер атнадан әллә нәрсә булды,
күренмәде сыңар аяксыз.
Кеше дә күп,
мунча тынып калды,
кая көлү,
кая шаян сүз!

Атна саен сыңар куллы икәү

шул ук көнне,
шул ук сәгатьтә
икәү генә килеп юыналар,
дәшми-тынмый гына, гадәттә.
Үзалдына кайсы нәрсә уйлый?
Әрни микән китек пар күңел?
Атна саен каен себеркегә
су да тими кала,
пар түгел.

Тегесеннән бергә чыксалар да,
аера соңгы чолганышлары.
...Кеше дә күп, мунча тынып калды,
ләүкә хәзер — матәм почмагы.

1979

## Урман

Кышкы урман.
Көннәр, айлар буе
ак кар тулы
чиләк-көянтәсен асып иңнәренә,
басып тора карда чыршылары —
бу сәхнәнең
ак чәчәкле яшел күлмәк кигән
кышкы җырчылары.

Кышкы урман.
Җилләрендә туңган
чукларына
алкаларын тагып ап-ак кардан,
чыгып баскан карга ак каеннар.
...Һава дәшми.
Җилләр дәшми.
Ак кар дәшми.
Бу урманда нинди гамь,
ваем бар?

Кышкы урман.
Җылы язда туган
агачларның
яфрак өзелеп төшкән урыннары
сөйләшәләр өмет белән:
тиздән...
яшел кошчык булып чыгар яфрак...
Кайры белән кәүсә пышылдаша:
тиздән...
бөреләргә кадәр йөгерер каным...
Бармакларын ташка төрткән тамыр:
тиздән...
хәрәкәткә килер агач җаны...

Соңгы көздә
өзелеп төпкә төшкән
кар астында калган сары яфрак
горурланып урманына дәшә:
«Яшә!

Тиздән...
мин булырмын сиңа нигез, туфрак...
Яшә!
Җиргә,
миңа берегеп яшә!»

...Ап-ак карда басып тора урман тездән.

1978

## Соңгы чабатачы

Бетсә дә бит давы, сугышлары,
килеп керде халык көрәшенә.
Булса икән шахтер галушлары
ике йортка бер пар өләшергә!
Өч сугышта йөреп исән калган,
бер тәнендә өч кат ярасы бар.
Авылның да әле яраларын
юкә-курыс белән ямасы бар.
Күнегергә кирәкмени аңа?
Шөшлесе дә кайткан капчыгында.
Юкә белән чабатачы белә
ачлыгын да, ялангачлыгын да.
Партизаннар өчен ничә йөз пар
ясаганын санап тормагандыр.
Кайткан айны ук авыл аягына
киндерәне йөз кат чорнагандыр.
Тузган саен алыштыра тордык,
әниләр дә киде, без дә кидек.
Атлар белән,
чабаталар белән,
күтәртмәләр белән исән идек.
Шөшлесенә бер текәлгән килеш
карамады өскә күтәрелеп.
Булган икән көче
замананы
күтәртмәгә куеп күтәрерлек.
Ул яшәде әле.
Чабатаның
гомере бетте диеп офтанмады.
Инде аяз һаваларга карап
каршы ала иде бу таңнарны.
Ышандымы кирәк түгеленә,
өнәмәде мәллә мондый эшне —
еллар буе кысылып торган җирдән,
матчасыннан егылып төште шөшле.
Озата халык картны соңгы юлга,
агыла авыл зират капкасына,
ышана авыл,
чабата да кире,
чабатачы карт та кайтмасына.
Китте нужа.
Китте чабаталар.
Башын иеп китте эшче атлар.
Аты белән чабатачы картын
йөрәгендә авыл мәңге саклар!

1979

## «Шота Руставели»

Кара диңгездәге аккош булып
калган идең минем хәтердә.
Мәһабәт һәм мәгърур килешеңне
бер күрәсе иде хәзер дә.
Кул болгасам,
син бер сәлам бирсәң,
минем өчен шул да җитә ич...
Ерактан ук күреп танырмын дип
яр буенда йөрим иртә-кич.
Теплоходлар килә-китә тора,
корабларның чуты юк монда.
Бик ерактан хәбәр көткән кебек,
күңел никтер сине юксына.
Хыялланам:
Килсәң шул дәвердән
алып Руставели сәламен,
дулкыныңа манып калыр идем
бөтен шагыйрьләрнең каләмен.

## Яшел килеш яфрак коела

Баш киемен талап исә җилләр,
пәри тузан ташый туена.
Яшьнәп торган агачлардан өзелеп
яшел килеш яфрак коела.

И дөньяның нурсыз мизгелләре,
и кайгыра торган сәгатьләр...
Кеше күбрәк үлә торган саен,
туа тора мәллә сәбәпләр?!

Күрәчәкне инде күрмәгәнме,
түзмәгәнме инде кешелек?!
Җир күтәргән афәтләрне салсаң,
күкләр төшәр иде ишелеп!

Ай!
Хәвефле исә әле җилләр...
Җил исәр дә туктар дисеңме?
Искән саен искә төшерә бит
истән чыкмый торган исемне.

Йә бер илдән,
йә бер илдән әле
сугыш сүзен алып исә җил.
Безгә исем,
безгә атамалар,
кемнәргәдер газиз
Туган ил.

Радиолар йөзләп,
меңләп саный...
Бер булса да,
кеше саны бит!
Кайгырмыйча эт җирләмәс заман...
Кем булса да,
кеше җаны бит!

Аһ-зарлары безгә килеп тора,
әйтерсең бу
безнең кайтаваз.
Йә берсенә,
йә берсенә ел да
канлы яшьләр булып кайта яз.

Баш киемен талап исә җилләр.
Сал башыңнан, ди күк тоела.
Тагын кайда яшьләр үлә икән?..
Яшел килеш яфрак коела.

1976

***

Зар ишетсәм якташларның язган
сәлам хатларында,
бер сызланып куям:
әле ярый
туган якларымда.
Сөйләсәләр сагынып туган җире,
иле хакларында,
бер кызганып куям:
әле ярый
туган якларымда.
Бик мескен һәм бик бәхетсез булып
йөргән чакларымда
бер куанып куям:
әле ярый
туган якларымда.

1976

## Арта бара

Безнең яклы гына түгел тормыш,
төрле һава төрле илләрдә.
Ирек сүзе йөри мәйдан даулап,
эш җитәрлек әле ирләргә.

Без утырткан кораб мачталарын
сыйпап кына тормый җилкәйләр.
Давылларда шартлап ярыла әле
брезентлардан теккән җилкәннәр.

Берсен-берсе таба ирләр, илләр,
дучар түгел кеше түземгә.
Милек кенә,
ирек кенә түгел,
илен яулый кеше үзенә.

Авыр йөкләр кеше җилкәсендә,
бөгелеп төшә кайчак шәп ирләр.
Арта бара җирдә шәп кешеләр,
арта бара җирдә шәп илләр.

Безнең яклы гына түгел заман,
сизгер карый кылган эшеңә.

Дөнья баккан ничә күзе белән,
бөтен өмет бүген Кешедә!
Кешедә!

1971

## Корылык

Басуларга аяк басып булмый —
гүя чүлләр.
Җәйләр буе ярлар чатнап ята —
кибә күлләр.

Яшел килеш ката буыннары —
корый иген.
Койма астында ята усал этләр —
көя ирен.

Ботаклардан сары яфрак коя —
үлә таллар.
Сандугачның томшыклары кипкән —
үлә таңнар.

Табигать тын. Көйгән башын игән —
өстә камчы.
Ирененә җирнең тамызырга
юк бер тамчы.

Диңгез кибәр. Исән калыр өчен
тамчы җитмәс.
Кешеләрнең күңелендә
өмет мәңге кипмәс.

1977

## Бер эздән

Бер эз салып үтте кыр казлары,
тыным бетте алар үткәндә:
бердәм булсаң,
бер эз буйлап кына
йөреп буладыр бит күктә дә?!
Таралсалар юлда,
мин гаепле,
ник санадым икән,
ник баздым!
Егерме каз үтте,
камылларда
күләгәсе калды бер казның.

Чаңгычылар ерак юлга чыкты.
Күз күреме — офык.
Ак дала.
Чаңгылардан кала бары бер эз,
сулышлардан җылы пар кала.
Сызгыра кар офык сызыгында,
китә офыклардан авышып.
Зур походта чаңгычылар байтак,
тик бер генә чаңгы тавышы.
Чыгып бергә,

офыгыңа бергә
барып җитү кирәк,
бик кирәк.
Чаңгы юлы буйлап ишетелә:
ак далада тибә бер йөрәк.

Аякларын аерып баскан ирләр.
Чалгычының эзе бер генә.
Язылмаган,
ләкин тиеш түгел
бер сөям дә читкә керергә.
Селтәнәсең бергә,
кистер бергә,
аерым-аерым арма, талма да.
Учка төкер бергә, җана бергә,
узарга да базма,
калма да.
Чалгычылар ничә дистә булыр,
болыннарның бигрәк киң чагы.
Күзне йомып тыңлыйм:
бер болынны
яңгырата бары бер чалгы.

Чаңгычылар,
чалгычылар кебек,
бер була ала Җирдә мең кеше.

Шуны көтеп
буыннарга күчә
дөньяларның мең дә бер эше.

Кыр казлары кеше көнләшерлек,
чылбыр-чылбыр итеп кем тезгән?!
...Төшләремә керә кайчакларда —
бара, имеш, дөнья бер эздән.

1978

## Сыерчык бураны

Бик озак китмәде кышлары.
Еракта әле яз кошлары.
Өлкәннәр офыкка карый да
бөтерә чал мыек очларын:
бу язлар соңарды, соңарды,
белмәссең заманны, елларны...
Шулай да, җәмәгать, бул түзем,
әйтер ул, боерса, үз сүзен.

Әй кинәт кузгалды ташулар,
гөрләште, җырлашты бар сулар.
Басулар битләрен ачтылар,
җиһанда уянды ярсулар.

Сизгәндәй халыкның уйларын,
томалап кырларын, юлларын,
бөтерелеп-бөтерелеп уйнады,
уйнады сыерчык бураны.

...Ә халык уңышка юрады.

Ашыгып китте кыш, ашыгып.
Ачынып китте кыш, ачынып.
Иң соңгы гөрләвек артыннан
өлкәннәр башларын кашыды:
ни ара килде соң, ни ара?
Майга да бер ай бар, майга да...
Калырмы туфракта дымнары?
Белмәссең заманны, елларны...
Шулай да, җәмәгать, бул түзем,
әйтер ул, боерса, үз сүзен.

Кырларның тузаны тузмады.
Яз тагын пошынмый узмады.
Томаны төште дә басуга,
офыкта болыты кузгалды.

Сизгәндәй халыкның уйларын,
томалап кырларын, юлларын,
бөтерелеп-бөтерелеп уйнады,
уйнады сыерчык бураны.

...Ә халык уңышка юрады.

Яз саен, яз саен урый ул.
Үзенең көнендә уйный ул.
Уйный ул сыерчык бураны,
хак була халыкның юравы.

1978

## Эскәмиядәге карт

Йоклый алмый чыкты микән?
Чал сакалын бер сыпырды.
Түбәтәен кырынайтып,
моңсу гына уйлап торды.

Иреннәре көлеп куя.
Тере очкын карашында.
Бүлдермәгез!
Карт утырды
яшьлегенең канатына.

Сәер генә карап алды
утыргычның уң ягына.
...Гаҗәпләнде, табалмагач,
сөйгән кызын үз янында.

1977

## Юкәләр

Урамнарга инде ничәдер,
уналтыда гына чатлары.
Урамнарның карап кояшка
иркәләнеп яткан чаклары.

Язгы ямьнәр иңгән дөньяга,
язгы нурлар кабат кабына.
Купшыланып калсын юкәләр

яшь чагында, үсмер чагында.

Ботак саен яшел бөреләр.
Тезелешеп баскан юкәләр.
Бүген никтер бөтен кешеләр
юкәләргә карап үтәләр.

Урамнарга, бәлки, йөз яшьтер,
уналтыда гына чатлары.
Чатларында яшел бөреләр,
юкәләрнең үсмер чаклары.

Уянганнар үсмер юкәләр,
гел кояшка таба үсәләр.

1972

## Борчак ашы

Кичләр алсу бүген,
таңнар алсу.
Көннәр ярсу бүген,
кырлар ярсу.
Туфрак, Кояш, Кеше
ни сөйләшә?
Үз-үзенә бүген
авыл дәшә:
сөенә-сөенә ашык,
бар да яхшы,
чәчү башы бүген,
чәчү башы!

Басуларга безне
дәшкән өйдән.
Буразнадан алып
күккә чөйгән.
Бәрәкәт һәм илдә
муллык башы —
басуларда пешкән
борчак ашы.
Кибеттә дә бүген,
келәттә дә...
Әле һаман безнең
йөрәктә дә.

Тук вакыт та булган,
ач булсак та.
Рәхмәт аңа — йомры
ак борчакка.
Өзелеп көткән көннәр —
кызу урак.
Без хуҗа да анда
һәм без кунак.
Басу арган инде
эшли-эшли.
Безнең алда табак —
кайнар эшти.
Ипи булмаса да,
безнең җор чак.
Кырда — яшәү, тормыш,
кырда — борчак.

Ни хикмәттер, хәтта
авыз пешми —
уттан гына алган
кайнар эшти.
Еллар ачы вакыт,
кайры ачы...
Рәхмәт, эшти, рәхмәт,
борчак ашы!

Олауларда орлык
көлә-көлә
кырдан кайтмый бүген,
кырга килә.
Үләсе дип түгел,
үсәсе дип,
җирдә шытып өскә
күчәсе дип
ята кереп туфрак —
бишегенә.
...Бөтен кырда борчак
исе генә.
Балкый басу түре —
кыр станы.
Кырда авылымның
аш өстәле.
Җилләр җылы бүген,
көннәр яхшы.
Казаннарда итле
борчак ашы.
Туфрак! Кояш! Кеше!
Яшә! Яшә!
Безнең авыл бүген
борчак чәчә!

Чәчү башы бүген,
чәчү башы.
Казаннарда итле
борчак ашы!

1978

## Карурман

Сөйләшәсе килә синең белән,
бу күңелгә әллә ни булган.
Яфрак саен бер җыр ишетелә,
кайсыбызга безнең моң тулган?
Серләрең бик тирән, карурман.

Болытларга барып башын сала
яшел дулкын, яфрак ярудан.
Имәнеңә иңне куйган идем,
арындырды ару-талудан.
Кодрәтеңнән көнлим, карурман.

Җир астыннан тамырың тоташ киткән,
ботакларың өстән сарылган.
Балтаданмы, яшен ташыннанмы,

яшь имәнең нишләп ярылган?
Яраларың бар шул, карурман.

1977

## Авыл урыны

Урамнары әле беленеп тора,
нигез саен — чокыр, багана.
Шау чәчәкле алмагачын күреп
килеп кердем үтеп барганда.
Арба эзен күмгән яшел чирәм,
бака тавышлары сазлыкта.
Киртәләрен баскан алабута,
авып ята черек казыклар.
Инде быел буылмаган инеш,
чишмәләре кипкән, саеккан.
Буш нигезнең каены ботагында
йорт җиткереп кергән саескан.
Сүтсәң, бәлки, тузан гына калыр,
исән килеш әле йорт әрәм.
Тәрәзен дә каплап маташмаган,
ташлап киткән икән бу адәм.

Соңгы йортның инде хуҗасы юк,
кошлар торыр,
алар талымсыз.
Бу авылда туып үскән кеше
калмас микән туган авылсыз?
Бабалары ята шушы җирдә,
кайтыр әле,
карар,
кадерләр...
Китә алмый ияреп кеше артыннан
туган нигез белән каберләр.
Туган илдә урын иркен безнең,
кая барсаң — шунда хуҗа син.
Бәхетенә таба китә кеше,
ияреп бармый арттан нужасы.
Бик кирәккә күрә китәләрдер,
ялгыз язмышлардан котылып.
Киткәннәрнең үткәннәре генә
югалмасын иде онытылып.
Ни әйтсәң дә,
бераз ямансурак
нигезеңдә хуҗа калмагач.
Ак чәчәген коя-коя елый
авыл урынында алмагач...

1976

## ***

Шөкер дөньяларга,
безне юатырга
әле ярый сез бар.
Сезне юатырга,
табып югалтырга
әле ярый без бар,

кызлар.

Безнең дә бит әле
бар бит янасыбыз,
бар бит барасыбыз...
Үзебезне үзебез
яратмаган чакта
безне яратыгыз.

Гомер итә-итә
яра-җәрәхәтле
йөрәккәйләр сызлар.
Үзәкләргә үтеп,
кабат гашыйк итеп
яратыгыз, кызлар!

1978

## Атыла йолдыз

Баш түбәмдә генә,
бер үземә
янып тора күпме йолдызлар!
Ялгыз чакта
уйлы-моңлыларга
әле ярый күктә йолдыз бар.
Бу төнем дә әнә шундый чагым.
Барыбер миңа —
җирдә, күктәме,
сердәш кирәк миңа
сөйләшергә,
киңәшергә азга, күпкәме.
Саубуллаштым
йөрәгемнән йолкып.
Хисләр аерылышу чатында.
Мәңгелеккә,
гомерлеккә микән?
...Җавап булып йолдыз атыла.
Атылсын дим.
Бетмәс,
бетмәс әле.
Берсе сүнсә, берсе кабыныр.
...Кабынганы янда яна торыр,
ә сүнгәнен күңел сагыныр.
Атыла йолдыз.
Миллионнардан бердер.
Сизелми дә бит ул күкләргә.
Минем менә бердәнбер йолдызым
атылды әле бүген...
үткәнгә.

1977

## Таңнарым

Ялгыз башым хозурланып йөрим,
урамнарда әле иртә таң.
Бу таңнарның җылы нурларыннан
яралгандыр, ахры, минем җан.
Кая барсам —
шунда Мәккә миңа,
тыкрык саен йөрим хаҗ кылып.

Дөньяларның барлык оҗмахлары
мине көтеп тора ачылып.
Сүз алышам Җирләр,
Күкләр белән.
Үз язмышым белән сөйләшәм.
Таңда торып йөрүчеләр булса,
этләрдән дә хәтта көнләшәм.
Һәркайсыбыз адәми зат булып,
бала булып туган анадан.
Һәр илаһи таңда камилрәк
кеше булып туам яңадан.
Шул иртәнге хозурлыгым белән
көннәр буе инде хаким мин.
Таңнарымнан әгәр аерсалар,
бер ташландык бала,
ятим мин!

1974

## **Көзләр җитте***

*(Җыр)*

Киек кошлар китә безне ташлап,
кызлар китә табып ишләрен.
Җырлар китә, инеш буйларында
казлар гына кала кичләрен.
Моңнар гына кала кичләрен.

Сау булыгыз, диеп куллар изәп,
шушы көзнең берәр көнендә
кызларына, җырларына ияреп
бер китәсем килә минем дә.
Көзге моңнар салып күңелемә.

Талгын гына болытлар агыла,
түбәләргә төшеп җитәләр...
Көзләр җитте инде, китәр вакыт,
болытлар да әнә китәләр.
Болытлар да әнә китәләр...

Китәләр.
Юк, мин калам әле —
язлар килер, кайтыр киткәннәр.
Каршы алыр өзелеп көткәннәр.

1976

## ***

Пыскып утырасың,
йөзең — кара болыт.
Хәсрәтләрең күпме?
Түкер, ташла, оныт!

Күтәр башкаеңны,
сөйләп бир кайгыңны.
Ягыңнан аерыммы,
ярыңнан аерыммы?

Ышанычларыңны
кемнәр акламады?
Дусларгамы үпкәң,
әллә ятларгамы?

Кая китте әле
шатлык-хәсрәтләрең,
үпкә-сагышларың,
сөю-нәфрәтләрең?

Күтәр башкаеңны,
утырмачы җебеп!
Без бит михнәтләрне
җиңә торган егет!

1976

## Тормыш чире

Бер елмайсам, шул да җитә миңа,
тик елмаеп булмый кайвакыт.
Көтмәгәндә үзәгеңә үтә
тормыш чире сару кайнатып.

Карамадай кешеләргә керә,
йөз яшәрлек имәндәйләргә.
Җаныңда бер тамыр җәеп алса,
инде үзе имәнгә әйләнә.

Йә сүз булып керә,
йә бер сүзсез.
Астыртын эш булып керә ул.
Гайбәт булып,
әйбәт булып керә,
кырык төрле юлын белә ул.

Берничек тә инде алалмаса,
җиңә алмаса сине каһәрләп,
тормышыңны эт тормышы итә,
хатыныңның телен зәһәрләп.

Яхшылыкта яман булып ята,
яманлыкта яхшы күренә.
Бу дөньяда эше бетми икән,
үтеп керә кеше гүренә.

Йөзебезне кара-кучкыл итә,
сүзебезгә тага кургашлар.
Аяктан да түбән урын булса,
төшеп китәр кебек бу башлар.

Кешеләрдән кешеләргә күчә,
йөздән йөзгә төшә карасы.
Дәвасы да бар бит,
тик бер генә,
бер елмаеп кына аласы.

Бер елмайсам, шул җитә дә миңа,
тик елмаеп булмый кайвакыт.

Елмаерга ирек бирми каһәр,
йөзне боза сару кайнатып.

1971

***

Нинди генә булсын,
мәхәббәтне
тиңли алмам әрнер ярага.
Бер генә көн чынлап яратсам да,
әллә нигә җитә янарга.
Сагышлары арттан килсә килер,
илаһидыр әле бу чагым.
Әле һаман дөрли йөрәгемдә
унсигездә яккан учагым.
Һәр минутта,
һәр сәгатьтә,
һәр көн
мәхәббәтем тота имтихан.
Еллар белән юллар сынап тора.
Арта гына бара ул илһам.
Яратуның күгенә менгәндә дә
әле тагын калыр хыялым.
Чөнки минем мәхәббәтем икәү:
берсе — чыны,
берсе — идеалым.

1977

***

Җиңә алмый ирне
танк та, туп та.
Бүлә алмый юлын
сулар да, ут та.

Адәм түзмәслек
хәлләргә түзем.
Ир карашына
чыдамый үлем.

Яуларда тигез
каһарманына
кайчак гап-гади
тормыш каныга.

Монда ул туплар
янамый икән.
Монда ул корал
ярамый икән.

Сәләт-кодрәтен
кеше оныта.
Укый, танымый:
тормыш — күп нокта...

1970

## Күңел

Кемдер җиңде, кемдер узып китте,—
ачуы кабарды.
Әле генә алсу кебек иде, —
йөзе агарды.
Тиделәр күңеленә.

Бәхәсе дә булды, фикере дә, —
булалмады хак.
Кемдер аңа бер туры сүз әйтте, —
диде ул: нахак!
Тиделәр күңеленә.

Бер каурые белән кагылып үтте
яла вә әләк.
Олы афәт килгән кебек йөрде,
илгә үпкәләп.
Тиделәр күңеленә.

— Лаек! — диде халык, кулын чабып,
аңа бермәлне.
Яшен сөртте бармак бите белән, —
күңеле нечкәрде.
Тиделәр күңеленә.

1978

## Әйтер иде кеше

Әйтер...
Шаулы мәктәп коридорларында,
курчак театры залларында,
урамдагы яки күршедәге
чуар битле малай алларында,
чирәмнәргә әйтер
иртә язда:
балачагым,
кайт беразга!

Әйтер...
Төсе киткән иске хатларына,
альбомдагы сары фотоларга,
китеп барган поезд артларыннан,
яшьлектәге самим хаталарга
карап әйтер,
әйтер күккә карап:
куяр идем сиңа шундый канат,
кайтсаң,
яшьлек,
кабат!

Әйтер...
Яфрак ярган утын бүкәненә,
киез ката кигән аягына,
кәкре таягына,
бая гына
юнып куйган утын тукмагына
текәлер дә:

бик җитәрлек миндә, дөнья, малың,
эшләремә күрә бардыр даным,
һәркемгә дә булмый һәйкәл, шөһрәт.
Булса иде җегәр...
Бераз кодрәт!

Әйтер иде...
Бишегеннән каберенә кадәр
барып җиткәч әйтер иде карап,
исән булса,
исән булса әгәр:
дөнья бирәүгә дә түгел хәрәм!
Нинди бәхетле син тере адәм!
Карап торсаң иде сиңа бераз
капка төбендәге эскәмиядән...

1979

## Әбием

Үзе инде җәннәт түрендәдер,
калмагандыр ишек катында.
Төннәрен дә оныта алмый иде
көнгә биш намазы хакында.
Без йокыдан торсак —
ул бөгелгән.
Өйлә җитте исә —
тезләнгән.
Бүгенгесен түгел,
киләчәген
намазлыкка ятып эзләгән.
Йөзләрендә чагылып,
намазлыкка
төшеп сүнде күпме таңнары!
Кызганмады.
Үз догасы белән
намазлыкта чыкты җаннары.
Хак булган ул димим.
Ялгышына,
язмышына тимим мин аның.
Бу тормышның ваемсызлыгына
бирешмәде аның иманы.
Безнең дә бит көнгә биш кат намаз.
Алдыбызда кәгазь-намазлык.
Кыйбла гына безнең башка якта.
Эшләү — савап,
эшләмәү — язык.
Була әле бик ваемсыз чаклар,
була әле күңел гарьлеге.
Кайвакытта җитеп бетми әле
әбиемнең фидакарьлеге.
Җаннар фида,
үзең фанилыкка
онытылып китсәң беразга,
баш калкытып әби дәшәр кебек:
«Әй! Намазга, улым, намазга!»

1979

«ХЫЯЛ» китабыннан

(1969 — 1984)

IV

*Өч юл булыр һәм өч төрле язмыш*
*көтәр дигән... сайла чатка басып.*
*Әкиятләр дә юлдан башланалар,*

хыялларга юллар һәрчак ачык.

## Офыкларга карап

Исе китеп текәлгән бу, димә,
күрмәгәндәй алсу таңнарга.
Җирдә гомер озынайган саен,
кадерлерәк таңнар җаннарга.
Кояш чыгып, Кояш баюлары
гамьсез вакытларда шәйләнми.
Җир әйләнә планетарийларда,
ә тормышта Җир ул әйләнми.
Әйләнмәсен шул ул,
миңа бары
Кояш кына чыксын көн дә бер.
Кояш чыгу белән Кояш баю
арасында минем — бер дәвер.

Кояш баеп барган вакыт инде,
дөнья бераз моңда, сагышта.
Меңенче кат менә карап торам,
меңенче кат Кояш баешка.
Уйландыра безне янар офык,
уйландыргандыр ул элек тә.
Офыкларга карыйм,
яңа таңнар
атачагын алдан белеп тә.

Исе китеп текәлгән бу, димә,
һәр көн саен шулай карыйм мин.
Күктә Кояш — минем җаным бит ул.
Ә Кояшның Җирдә җаны — мин.
Шуңа күрә бераз тыныч түгел,
озатып калам бераз шик белән:
мин Кояшның кайдан чыкканын да,
кайда батканын да бик беләм...

1980

## Яңа елга

Яшәүнең дәвамы булып кил,
көннәрең көн булып тусыннар.
Бүген кич кайгырып ятканнар
иртәгә сөенеп торсыннар.

Бәхетне юлларда туктатма,
хыяллар хыялда калмасын.

Утларың яп-якты булсыннар,
тик утта өметләр янмасын.

Җир дә бер,
без дә бер,
син дә бер —
һәммәсе бик кыйммәт, зарури!
Чир керсә кешелек канына,
еллар да ел буе авырый.

Һәр елдан һәр елга таләп бер:
күрсәтмә зур бәла, зур каза.
Көннәрең булсыннар сәламәт,
кешеләр булсыннар сау-таза.

Ел гына түгел син,
син безнең
җиребез,
суыбыз,
күгебез...
сәгатьләп,
минутлап,
секундлап
без сине җыябыз үзебез.

Тарихка исән-сау тапшырып,
бусыннан хушлашып китәбез.
Җыйдык без,
җыярбыз елларны,
сине дә матур ел итәрбез!

1976

## ***

Су буйлары безнең тугай-тугай,
дәртле җырлар-моңнар тургайда.
Үзебез дә җырлы-моңлы идек,
һаваларда тургай булганга.

Сулар саектылар, ярлар сөзәк,
үләннәрдән көйгән ис килә.
Без тәгәрәп үскән тугайлар дип
ышанасы килми һич кенә.

Туган ярлар һаман тугай-тугай,
тугайларда һаман шул тургай.
Тик тургайның җырларында инде
ятимнәрнең моңы бар бугай.

1983

## Быел яз...

Кайгыңны да бүген иртәгәнең
шатлыгына юра.

Бәхетеңне үзең шәйләмәсәң,
син язлардан сора.
Без бик комсыз булыр идек, әгәр
пошсак гомер азга.
Мәңгелектер әле, бер уйласаң,
яшәү шушы язда.
Язлар алар безгә карап тормый,
килә, китә
димә.
Дөньяларда без булганга гына
мондый язлар килә.
Бу мизгелләр, утлы караш сыман,
җанны айкап чыга.
Син бары тик җиңелмичә генә
сихеренә чыда.
Моңа кадәр булса югалтулар,
барысы да кайтыр.
Ышанмаска мөмкинме соң шуңа —
көннәр шундый матур!
Күреп алдык инде язлар ямен,
мондый көннәр бетмәс.
Дөньяларда әле без булганда,
язлар бездән китмәс.
Бәхетеңне әгәр шәйләмәсәң,
син язлардан сора.
Мин ышандым быел: безнең гомер
гел язлардан тора!

1983

## Яза халык

Заманасы шундый микән? дим мин.
Кешеләре шундый микән? дим.
Кемнәр белән кайда танышсам да,
шагыйрьләргә очрыйм икән мин.
Укучылар яза дәфтәр-дәфтәр,
дәфтәрләрдә шигырь-моң гына.
Болар миңа башка дәфтәрләрдән
мөһимрәк булып тоела.
Ялгыш та юк анда,
билге дә юк.
(Билге куйсаң — бишле аласы.)
Күңелендә аның тик ярату:
Иле,
җире,
авылы,
анасы.
Укытучы яза...
Укучысын
һәм үз эшен ничек сөя ул?!
Классында гына өлгерә алмый,
шигырендә янып-көя ул.
Яза врач...
Ул да авырый икән
шигырь дигән изге чир белән.
Агроном да яза,
ул сөйләшә
шигырь аша туфрак-җир белән.
Яшьләр яза:
кызлар — егетләргә,

егетләре яза кызларга.
Сүзләр яна сөю ялкынында,
алсуланып кәгазь кызара...
Инвалидлар яза...
Пенсионерлар...
Нәрсә кирәк инде ул картка?!
Ул ярата Җирне,
тынычлыкны —
шигырь яза янып шул хакта.
Кешеләрнең йөзләреннән хәтта
шигырь укып йөрим таң калып.
Яратуның теле шигырь икән,
яратмаса, язмый ул халык!

Заманасы шундый микән? дим мин.
Әллә халык шундый микән? дим.
Бәхетләрем нидә икән, дисәм,
шагыйрь халык улы икән мин.
Халык бәхетедер мондый хикмәт,
әллә каян килә, тирәннән.
Яратырга да ул,
яратуын
яза белергә дә өйрәнгән.
Гаҗәпләнә идем.
Гаҗәпләнмим.
Тормышы да, дөрес, булышкан.
Әмма ләкин мондый шагыйрь була —
шагыйрь халык кына... тумыштан!

1983

## Мәчет мәйданы

Үткән заман төсе,
карт һәм иске,
түбәсендә кыйшык манара.
Хәтеренә сеңгән
бу авылда
булып үткән барлык манзара.
Тутык айлы башын кырын салып
түбән карый
гүя үткәнгә.
Үткәннәрдә бар язмышы,
хәзер
кирәк түгел Җиргә, Күкләргә...

Бер карасаң — изге җир бу мәйдан,
бер карасаң — олы гөнаһлы.
Заманалар узган гауга салып,
мәчет манарасы — гуаһы.

Кичке шәфәкъ яна,
яна офык,
яна бер йорт мәчет каршында.
Ялкын белән тарткалашып яна
кызыл байрак түбә башында.
Әллә янгын,
әллә байрак балкый,
әллә шәфәкъ,
әллә ил каны...
Совет йорты яна,

ялкынына
чумып ята мәчет мәйданы.
Китерәләр сөйрәп мәйдан аша...
Уттан чыгып исән калганнар.
Икенче кат үләр өчен баса
Заһид, Салих, Нури, Солтаннар...
Кан төсендә һава...
Сөрем...
Төтен...
Кояш яңа байган чак була.
Стенага терәп ата аклар,
михраб ягы, кыйбла як була.
Өч большевик кала чират көтеп:
Ширияздан, Касыйм, Габдулла.
Соңгы залп яңгырар мизгелендә
килеп җитә йөгереп карт мулла:
«Әфәнделәр!
Мәчет...
Кыйбла ягы...
Туктатыгыз Тәңре хакына!»

Мәчетен яклап басып торган мулла
өч большевик белән атыла...

Күкрәкләрне тишкән шул ук ядрә
тишеп үткән мәчет тактасын.
Большевиклар дошман,
ә мулланы,
ә мәчетне нигә аткан соң?!
Кыйбласына аткан,
мулласына...
Шушы мәйдан яхшы белә аны.
Алласын да атар,
анасын да —
вәхшиләрнең шундый иманы!

Мәчет мәйданында — мәрмәр һәйкәл,
башын ияр һәрбер замана.
...Айлы башын кырын салып тора
уйлы,
моңлы,
иске манара...

1969

## Пошилар

Бик кадерле бер көнебез үтте,
гади көн дә кебек,
түгел дә.
Әллә нигә генә шушы көнем
бик уелып калды күңелдә.
Чабыш аттай үтте бүген вакыт,
ашыкмаган чагы юк аның.

Һәр көн саен дөресләргә кирәк
сәгатьләрен хәзер дөньяның.
Үзе уйлый, үзе кыла кеше,
үз хәлен соң кемнән сорасын?
Һәр көн саен иртән:
«Дөньяларга
ни булды икән?» — диеп торасың.

Баш бетәрлек хәлләр булгалагач,
борчылырга сәбәп табыла.
Әллә җире,
әллә чире шундый —
кешелек тә бик еш абына.

Бик кадерле бер көнебез үтте:
гомерләргә аны тиңләрлек.
Без бу көнне җылы учак эзләп
өйдән өйгә кереп йөрмәдек.
Бүген Кояш безгә көлеп чыкты.
Сандугачлар белән атты таң.
Йөзләребез көләч,
еласак та,
елаганбыз күбрәк шатлыктан.
Олыларга олы итеп дәштек.
Җылы учны тойды сабыйлар.
Онытылып,
эреп,
җанга кереп,
кочакларда янды җаныйлар.
Уйларыбыз безнең эшкә ашты,
юлларыбыз булды уңышлы.
Ким дигәндә
тагын бер көнгә без
буып тордык әле сугышны.
Шатлыкларны җырлап каршы алдык,
кайгыларын күрсәк, дәшмәдек.
Без бүген дә,
тагын бер мәртәбә,
бер гомерлек итеп яшәдек.
Чәчләребез бераз агаргандыр.
Без картайсак, дөнья яшәрә.
Агармасын, имеш,
бүгенебез
һәм киләчәк өчен яшә дә!

Бик кадерле бер көнебез үтте.
Һәркайда да аны тойдылар.
Шагыйрьләрдә түгел,
компьютерда
сизгеррәк бүген тойгылар.

Күрдек бүген күпне.
Тойдык күпне.
Кемдер яңа корал сынады.
Сукбайлыкка дучар булган гарәп
тагын бер көн ачка чыдады.
Янгын исе,
шартлау тавышлары
ишетелә икән еракта.
Бу заманда бөегрәк эшләр
көтелә иде юкса ир-аттан.
Шаулады Җир бүген зур тавыштан
(чүкеч тавышларын әйтмим мин).
Үкседеләр яңа каберләрдә,
без аңлыйбыз хәлен ятимнең.
Җир шарыннан төтен исе чыкты,
авыру йөрәк кебек тибеше.

Кешенең бит әле, бер уйласаң,
яңа гына туып килеше.
Кемнәргәдер артык рәхәт Җирдә.
Кулда затлы уен-кораллар.
Ир исемен әләм итеп Җирнең
инде күпме җанын кыйганнар?!
Көне буе бүген Җиребезнең
зыңлап торды нерв җепләре.
Кемнәргәдер, шартлап үләр өчен,
берәр бомба әле җитмәде.
Җитмәгәнен ясап, салдык заряд,
ипи бүлгән кебек,
тигезләп...
Һәркемгә дә җитә инде бүген,
барыбыз да Җиргә игезәк.

Бик кадерле бер көнебез үтте.
Елъязмада урыны зур аның.
Әрнеде җан.
Әйтерсең лә мине
ташлап китте газиз туганым.
Гайрәтләнеп,
гөрләп,
дөнья шулай
ыгы-зыгы килеп торганда,
Кояш баеп барган вакыт иде,
ике поши чыкты урманнан.
Чибәрләнеп,
көязләнеп түгел,
бераз моңсурак пар иде.
Күзләрендә кешеләрнекеннән
тирәнрәк сагыш бар иде.
Күккә карап озак иснәнделәр,
су эчтеләр төшеп инештән.
...Әллә инде поши урманына
берәр шомлы хәбәр ирешкән.
Пошиларга никтер тыныч түгел,
урманда да дөнья тар сыман.
Китеп барды бүген ике поши
баеп барган Кояш артыннан.

Сүнеп бара тагын бер көнебез.
Шундый матур,
шундый кадерле...
Офыклардан бәрә кайнарлыгы,
табигатьнең яна бәгыре.
Күп сораулар туды бүген Җирдә,
күп сорауга җавап табылды.
Минем менә тик бер генә сорау
җәрәхәтләп тора җанымны:
Бик борчылып һәм дә бик үпкәләп
китеп баручыга охшыйлар;
көз бит инде,
кая бара икән,
кая бара икән пошилар?

1983

## Сагыш

*Советлар Союзы Герое*
*очучы М.Девятаевка*

— Очалмыйсың,— диде аңа врач,—
җирдә генә урының бүгеннән...
Төшерделәр аны бик биектән,
бик биектән —
зәңгәр күгеннән.
Бер күкләргә,
бер суларга карап,
йөрәген ул баса алмады.
«Кая куйыйм бу җанымны», — диеп
дуламыйча чара калмады.
Утырттылар аны «Метеор»га,
самолеттан бер дә ким түгел.

— Охшаган шул,— диде,—
бераз гына,—
һәм җилкенеп куйды...
И күңел!
Кыяфәте очкычныкы кебек,
канатлары суда судасын...
Югарыда һава иркен булгач,
суларына, бәлки, чыдарсың.
Әйләнде ул Идел киңлекләрен,
суда йөзде — күккә карады.
Бер сәгатьтә үтеп китәр иде
өчәр сәгать үтәр араны.

Кайчакларда аңа бу матур кош
дулкыннарны кисеп үтәр дә,
канатларын җәеп ике якка,
ыргылыр күк иде күкләргә.
Басалмады ләкин ярсуларын:
— Очмый икән,— диде,— кораблар.

...Җирдә инде табып булмыйдыр шул,
күктә калса әгәр канатлар.

1983

## ***

Ни сәбәптән җир йөзендә
тәнгә — мунча, җанга юк?!

*Г.Тукай*

Яшь белән дә, тән һәм җан белән дә
без дә олгаябыз.
Нишләтәсең, дөнья белән бергә
без дә болганабыз.

Аладыр шул, ала яңгыр, җилләр —
җете төс тә уңа.
Ничек кенә төренсә дә кеше,
җанга тузан куна.

Кешенеке кебек бар минем дә
чорым, җирем, анам.
Тик барыбер, керсезме дип җаным,
мин Тукайга барам.

## Күгәрчен үлеме

Иләсләнеп очты бер күгәрчен,
бик атлыгып очты, ашкынып.
Кунар җирен таба алмадымы —
кабат кайтты уктай атылып.

Әллә күрми, әллә күреп инде —
тәрәзәгә килеп бәрелде.
Үле күгәрченнең канат очы
тырнап китте минем бәгырьне.

Нәрсәгә дип ашкынды икән бу кош,
иркен һаваларда җан атып?
...Озак тибрәнде бер ялгыз каурый,
һаваларда эзләп канатын.

1983

## Язмышка

Мин сорамыйм синнән бәхет-мазар,
ул кадәрен генә табам үзем.
Миннән башка хәл итәрлек булсаң,
колагыңа гына бар бер сүзем:

Дуслар белән мине дошман итмә,
дошман белән берүк дуслар итмә.
Гел дошманнар арасында калдыр,
ялгызлыкка гына дучар итмә.

## Авырганда

Шундый көннәр әле,
шундый көннәр...
Авыр вакыт бераз, моңсу вакыт.
Төрле уйлар килә, төрле сагыш,
гел түшәмгә карап чалкан ятып.

Төсләрнең дә уңа җетелеге,
карашлар да бераз тоныклана.
Алып китә уйлар бабайларга,
алып китә туар оныкларга.

Әллә инде кирәк чагын белә:
сагышыңны, уйларыңны ватып,
бер бәләкәй генә матур шатлык
килеп керә сиңа кайсы вакыт.

Сизәм, нидер булган кебек бүген,
әллә нигә минем шатлык арткан.
Күзем төште, уйнап алды күңел:
бүлмәбездә бер гөл чәчәк аткан.

1982

## Хәбәр

Октябрьнең унбишләре,
көннәр дә инде кырыс.
Күрәктәй ике кулында
бәләкәй генә тырыс.

Тырыста кызыл җиләкләр,
әллә кызыл күмерме?
Октябрьнең унбишләре...
Кара инде гомерне!

Анасының хаты да бар,
биш-алты сүз аңарда:
«Бу инде соңгы җиләкләр,
азлыгына карама».

«Миңа микән?» —
дигән кебек
исләре китеп карый
анасының төпчек улы —
илле яшендә сабый.

1983

## Сиреньнәр

Сөенергә бүген сәбәп бар:
бер генә уз сирень яныннан.
Бер генә уз сирень яныннан,
бөтен дөнья чәчәк ябынган.

Тәлгәш-тәлгәш
купшы сиреньнәр,
яшь сиреньдә бары бер чәчәк.
Яшь сиреньдә бары бер чәчәк.
Яшь сиреньдә әле — киләчәк.

Яшь сиреньдә әнә бер чәчәк
яңа гына килә ачылып.
Яңа гына килә ачылып,
йөрмик әле без дә ачынып.

Бөтен дөнья чәчәк ябынган,
табигатьтә гүзәл гадәт бар.
Табигатьтә гүзәл гадәт бар,
сөенергә һәрчак сәбәп бар.

## ***

— Саклан, — дидең, —
сүздән һәм кешедән,
чыгар яманатың...
Яманат та чыкты,
яхшы ат та,
чөнки сакланмадым.

— Тапта, — дидең, —
шайтан белә уе
кай тарафта аның...
Дошманым да,
дусларым да артты,
чөнки таптамадым.

Акланырга кирәк чаклар булды,
никтер акланмадым.
Мин шуңа шат бүген:
бу тормышны
ваклап сатмаганмын.

1983

## Ялгызлар

Фатирына бик соң гына ялгыз
талчыгып һәм шактый арып кайтты.
Куенына тыгып,
адашкан бер
калтыранган мәче алып кайтты.

Иртүк торды:
— Чәйләп алыйк, — диде,
песи белән бөтен эштән алдан.
Тик мәчесен эзләп табалмады:
өйдә салкын,
ишек ачык калган.

— И ялгызлык!
Кемгә сыенырга;
шул мәче дә ташлап киткән, — диде.
...Ә мәчесе, куып чыгарыр дип,
бер почмакта посып ята иде.

1983

## Трамвайда хат укучы кыз

Ыгы-зыгы:
билет...
тиен...
урын...
Гамьсез кеше сирәк.
Тукталышны узып китмәс өчен
онытылмаска кирәк.
Аңа гына барыбер.
Ул битараф
мондый буталышка.
Кирәк түгел аңа трамвай да,
һичбер тукталыш та.
Сипкелле кыз балкып хатка баккан,
сипкел саен нурлар.
Күрмәсәм дә, миңа таныштыр күк
бу хаттагы юллар.
Шушы кызга карап тукталышны
мин дә узып киткән...

Егерме ел элек мин язган хат —
шушы түгел микән?

1983

***

Син кош булып кердең
минем төшкә,
очып киткән кошлар күк түгел.
Сайрый-сайрый очып килдең...
Ләкин
сыңар канат идең син бүген.

Очып килеп кундың иңнәремә,
бераз туңып,
бераз калтырап.
Бу кош мине нигә үз итте дип,
карап тордым бераз аптырап.

Сылу идең,
бик тә иркә идең,
сайравыңны өзелеп тыңладым.
Бик таныш та иде, бик яңа да,
бик зарур да иде моңнарың.

Иңнәреңдә кошлар тою рәхәт,
кошларның да мондый сылуын.
Кулым белән мин орынган идем —
күрдем сиңа канат чыгуын.

Белмәдем мин ничек юрарга да,
юрауларга күңелем яраксыз.
Аңладым мин бары шуны гына:
миннән башка син дә канатсыз.

1984

## Хыял

*(Поэма)*

Рухы таза булса,
беркайчан да
ашкынуын кеше тыялмаган.
Китәме ул кая,
йә кайтамы —
башланалар юллар хыяллардан.
Күңеле саф икән,
кешедән дә,
Алладан да кеше оялмаган.
Күккә ашарлык олы мәхәббәтләр
башланалар җирдә хыяллардан.
Кодрәте киң.
Шуңа гомере буе
Җиргә генә кеше сыялмаган.
Бер-бер артлы
күпме йолдыз-җиһан
кабына тора кайнар хыяллардан.
Ул чаклар да булган:

башны башка,
ташны ташка куеп,
җыялмаган.
Үсә торсын дигән,
яңа йортка
нигез салган башта хыяллардан.

**1**

*Өч юл булыр һәм өч төрле язмыш*
*көтәр дигән... сайла чатка басып.*
*Әкиятләр дә юлдан башланалар,*
*хыялларга юллар һәрчак ачык.*

Тик ятмыйлар юллар.
Алар һәрчак
замананың даим тарту көче.
Юлы булгач, йөкләре дә була,
төяүчесе була,
тартучысы.
Ике туктап ике ял иткәннәр
Чаллы үрен менеп җитәр-җитмәс.
Аты булса, кеше кая бармас,
юлы булса, кеше кая китмәс.
Атлар тарткан,
үгез,
сыер тарткан,
алар арса, кеше үзе тарткан.
Өметләре алдан чакырып торса,
заманасы әйдәп торган арттан.
Без бүген дә йөкче һәм тартучы.
Йөкләр авыр,
әмма атлар әйбәт.
Без һәрвакыт төяп бушатучы,
замана ул һәрчак тора әйдәп.
Йөк тә арта,
тартучы да кирәк.
Бушый алмый бүген йөкче кулы.
Йөкче Казан кебек
Чаллы йөкче,
тарту көче — яңа Чаллы юлы.

Озатабыз.
Яңа машиналар...
һәм башкалар китә, һәм башкалар...
Йөкче «КамАЗ»ларның тормышлары
Чаллы юлы белән башланалар.
Без озаткан яңа йөк «ат»ларын
кайсы якта каршы алсагыз да,
сез, егетләр,
тизрәк бушатыгыз,
бүген инде гаҗәп арсагыз да.
Буш димәгез.
Йөктә — кырлар шавы.
(Дулкынлана әнә карабодай.)
Соңгы кабат бездә сайрый-сайрый
кошларыбыз китеп бара бугай.
Сак булыгыз.
Зинһар, сак булыгыз
бушатканда безнең «КамАЗ»ларны.
Күлләрен дә алып үзләренә,

утырып китә безнең кыр казлары.
Озатабыз.
Менә бер болынның
чык тамчысы,
соңгы бер чәчәге...
Борчылмагыз!
Барыбер бездә кала
яңа бакчаларда киләчәге.
Югалтулар белән табабыз без.
Шәһәр кадәр шәһәр сал да, имеш,
югалмасын икән бер буразна,
үзгәрмәсен икән берәр инеш.
Елга-сулар исән,
кыр-басулар,
җәйләре дә исән, кышлары да...
Елгаларны диңгез италабыз.
Күкләр биек очар кошларына.
Күгебезнең тирәнлекләрен дә
төягәннәр безнең машиналар.
Халкыбызның зирәклекләрен дә
җиткерергә сезгә ашыгалар.
Буш димәгез.
Яңа «КамАЗ»ларның
әрҗәләре шыплап-шыплап тулган.
Җиребезнең җан җылысын төяп
озатабыз сезгә яңа юлдан.
Буш димәгез.
Яңа «КамАЗ»ларның
әрҗәләре тулы асыл маллар.
Бушатыгыз!
Анда безнең гомер:
безнең көннәр,
төннәр,
кичләр,
таңнар!

Тик ятмыйлар юллар.
Еллар һаман
каршы ала
яки озата тора.
Олы юллар һәрчак ике яклы —
нидер китә,
нидер кайта тора.
Нәрсә тарта аны?
Нәрсә көтә?
Суык яктан килә,
җылы яктан...
Татарстан туфрагына баскач,
кардәш булып китә җиде яттан.
Кайсы җирнең балалары гына
әйләнмәде хәзер юлдашларга?
Үзбәктән дә,
рустан,
чуваштан да...
Чаллыга дип туры юл башлана,
алып килә безгә хис-тойгысын
үз халкының,
ихлас кардәшлекнең.
Чикләре юк бүген халыкларның,
чикләре юк бүген бу яшьлекнең.

Чаллы юлы
бүген илебезнең
кан тамыры.
Шулай исәпләнә.
Кая гына барып ялганса да,
без бүлмибез аны кисәкләргә.
Бер.
Тоташ ул.
Сукмак-сукмак булып,
еракtan ук илне иңләп ята.
Бер.
Тоташ ул.
Чаллы юлы буйлап
йөри вакыт бары ике якка:
машиналар китә,
кеше кайта.
Кошлар кебек кайта җан-туган да.
Сигнал бүген «КамАЗ» гудоклары
сусаганга газиз җир-суларга.
Җаны-тәне тарта.
Килә.
Кайта.
Монда, димәк, аңа сулар һава.
Чаллы юлы — илнең тарту көче,
машиналар китә,
юллар кала.
Машиналар китә.
Килә кеше.
Кемнәр,
кайдан,
кайчан юлга чыга?
Чаллы юлы иркен,
киңрәк ягы
килүчегә безгә,
кайтучыга!

**2**

*Гаҗәпләнә яңа килгән халык:*
*кайда шәһәр монда, кайда авыл?*
*Гаҗәп түгел. Бик күп кешеләргә*
*аеруы аны шактый авыр.*

Исте җилләр —
дымлы,
йомшак,
назлы...
Исте кайчак кисеп-кисеп битне.
Яуды яңгыр —
җылы,
чиста,
рәхәт...
Яуды кайчак — яра ясап китте.
Җәе-кышы,
язы-көзе килде —
бер елда да бер дә онытылмады.
Сөрде,
чәчте,
урып-җыйды кеше,
үзе үлсә, улы,
оныгы калды.

Гел шул якта байды кояшы да,
таңы туды туар нәүбәтендә.
Бозылмады канун
йөз ел,
мең ел...
табигатьнең камил дәүләтендә.
Тик бер генә җырны белде басу,
шул бер көйне ел да җырлап ятты.
Башак шавы белән таңнар атты,
башак шавы белән кояш батты.
Мөмкинмени җирдә башка җырлар?
Үз көенә тугры ул электән.
Бодайларның шушы ялгыз җыры
барыр кебек иде мәңгелеккә.

Җир картая микән,
яшәрәме?
Арта тора барыбер еллар саны.
Һаман саен берәр хикмәт белән
шаккаттырып куя кеше аны.
Шулай килгән.
Гомер шулай булган:
еллар җирдән һаман нидер ала.
Тик барыбер җирдә нидер арта,
өсти тора нидер кеше аңа.

Ник уянды әле басу иртә?
Җил куптымы әллә таңга кадәр?
Тиккә түгел.
Кай тарафтан килә
аңлашылмый торган нинди хәбәр?
Басу белән янәшәдә генә
субай сугып кеше нигез салды.
Ул арада йортлар үсеп чыкты,
тамашага басу хәйран калды.
Бер уянды:
яңа гына җәйгән
җылы асфальт исе килә кырга.
Бер уянды:
таныш моңнар түгел
краннардан килә торган җырда.
Уяттылар:
каян килгән диген
трамвайлар бодай арасына.
Уяттылар:
яңа җырлар килде
төялешеп «КамАЗ» арбасына.
Тынды басу.
Тынды мескенләнеп.
Канатларын күктә какмый тургай.
Тынды басу.
Бу ят, яңа җырлар
башак шавын күмеп китте бугай...
Тик моңайды басу юкка гына.
Шытты иген,
үсте башак тулып.
Күктә — тургай,
кырда — башак шавы,
җыр яңгырый тик көчлерәк булып.
Тиз күнекте басу асфальт юлга.

Ияләнде шәһәр тавышына.
Язган икән Чаллы кырларында
бу җырларга бергә кавышырга.
Яңа Чаллы көн дә яңа җырын
көйләп тора,
уйнап,
җырлап тора.
Басу аны башак шавы белән
заводларга илтеп тоташтыра.
Шаулый басу.
Бүген аның шавы
куәтлерәк инде күп тапкырлар.
Яңа җырлар килеп,
аның белән өр-яңа көй,
уртак көй таптылар.
Яңа җырлар килә, кушыла тора,
куәтләнә,
ныгый Чаллы җыры.
Бозылмый көй,
чөнки гигант хорның
гигант кеше өлкән дирижеры.
Һәрбер җырның хорда үз тавышы.
Аерып булмый аны,
шунда хикмәт.
Тавышлар күп,
ләкин башлап җырлый
яңа көйне
тимер,
бетон,
икмәк!

**3**

*Икмәкме ул, таштан стенамы —*
*нигезләр нык безнең эштә.*
*Тамырыбыз —*
*җирнең үзәгендә,*
*хыялыбыз өстә —*
*гел үсештә.*

Ни салса да,
сүтәргә дип салмый.
Нигезләрнең гомерен юрамыйлар.
Таш — мәңгелек.
Аннан нигез салган
киләчәккә карап болгарыйлар.
Кемнәр сала,
кемнәр җимереп китә —
ил язмышы шулай ташта уйный.
Әйтерсең лә заманалар өчен
кеше түгел,
җансыз ташлар уйлый.
Төзегәнне җимерүче җитә.
Андый чакта хәтта таш та яна.
Яшәргә дип атап сала белсәң,
халык өчен барыбер нигез кала.
Җимермибез бүген,
сүтәбез без.
Кагылмыйбыз изге нигезләргә.
Шул нигездә шәһәр салу өчен
кирәк җирне бераз тигезләргә.

Үсә диләр ташны.
Иске Чаллы
авыллары инде йөздән үткән.
Алай гына үссә...
таш йортлары
зур сарайлар булыр иде күптән.
Кымшанмый да күпме гомер иткәч
шушы йортлар, бүген сүтеләләр.
Кызыл Чаллы,
иске Чаллысында
йөз елдан соң ташлар үкенәләр:
ник үсмәгән алар,
ник булмаган
бер һәйкәлме шунда,
бер кыямы!
Сүтелә өйләр.
Иске нигезләрне
урап йөри кебек таш хыялы.
Үсә диләр ташны...
Үсә.
Дөрес.
Таш хыялы чөнки бездә шыткан.
Иске Чаллы нигезендә әнә
нинди йортлар таштан үсеп чыккан!
Юк!
Үсми таш!
Әгәр үссен дисәң,
җан җылысын кирәк кызганмаска.
Үсми ташлар
безнең хыяллардан,
безнең нурдан,
безнең җырдан башка.
Кеше әле яңа тапкан ташлар
үсә әнә,
үсә катлап-катлап.
Ташка басып бергә кеше үсә,
күтәрелә каттан катка атлап.
Кояш уйный якты таш йөзендә,
ташларда да бүген ачык чырай.
Балкый-балкый үсә безнең ташлар,
һәйкәл,
ядкарь булып,
гимн,
җырдай.
Иске Чаллы бетми,
ул үзгәрә,
искесеннән үсә Яңа Чаллы.
Елмая таш, безнең куллар тигәч,
таш та аңлый безнең уйны, җанны.
Җимерүче итеп белми дөнья,
таный безне тик төзүче итеп.
Игенчеләр идек,
терлекчеләр,
ташчылар да булып үсеп җиттек.

Тик сүтәбез бераз,
җимермибез.
Шәһәр өчен җирне тигезлибез.
Үсә ташлар,
үсә катлап-катлап,

асыл таштан — салган нигезебез!

**4**

*Җимерүе ансат.*
*Аң кирәкми.*
*Замананың җитә залимнәре.*
*Хыялларның ышанычы таза,*
*без —*
*тынычлык фәне галимнәре.*

Хәбәрләр күп.
Хәбәрләр тиз килә.
Соңга калмый хәзер соңгы хәбәр.
Җимерелгән диеп килә,
килми әле
төзелгән дип бирәр яңа шәһәр.
Кемнең генә йорты тетрәнсә дә,
үзәкләрне ала өзеп-өзеп.
Шәһәрләрнең төне тыныч түгел,
җир сулышы һаман өзек-өзек.
Шәһәрләр күп.
Кемгә нинди зыян,
кайбереннән калса зират кына?
Бетончыга эш бар
утрауларда...
Бетончыга эш бар
җир астында...
Бетончыга эш бар...
Төзүчегә
якты дөнья кирәк,
тирән һава.
...Күп шәһәрләр карый шуңа күрә
Көнчыгышка,
Көнчыгышка таба!

Җир астына түгел,
җир өстенә,
көмеш сулар аккан ярлар буйлап;
үткәннәрне белә-күрә торып,
бүгенгене,
киләчәкне уйлап;
биек ярлар буйлап,
калку җиргә
салабыз без
аның һәрбер йортын.
Безгә дә бар дөнья күренеп торсын,
безне дә бар дөнья күреп торсын!
Су буена,
ярга,
калку җиргә!
Кояш,
һава
кирәк тәрәзәгә!
Күрсен дөнья
киләчәккә безнең
ышанычыбыз
нинди
дәрәҗәдә!

Табылмаслык булып югалганын...

Үләр хәлдә терелә алганнарын...
Беләбез без кайбер шәһәрләрнең
сызымнарда гына калганнарын.
Бик беләбез,
кешенеке кебек,
шәһәр язмышы да каһәрләнгән.
Шуңа, дибез,
безнең кешелеклелек
күренеп торсын безнең шәһәрләрдән!

Яңа Чаллы үзәгеннән үтә.
Юк.
Башлана Чаллы шул урамнан.
Без Тынычлык проспекты дибез,
зур ул аннан,
проспектлардан.
Кайда аның иң беренче йорты?
Шәһәребез саен бар ул урам.
Шул бер урам —
барыннан да зуррак —
дәүләтебез буйлапуза урап.
Дөнья буйлап,
ил-дәүләтләр буйлап,
ничә урам-проспект үткән?!
Шул тынычлык урамнарын җыйсаң,
үзе дәүләт булыр иде күптән!

Һава тирән.
Ярлар җиләс тора.
Иркен сулый монда Җирнең җаны.
Үзәк урамына —
дәвамына
ташлар тезә бүген Яңа Чаллы.
Без Тынычлык проспекты дибез,
аңа тоташ һәр урамның башы.
Һәр шәһәрдә,
тыныч ятсын диеп,
иплэп сала кеше һәрбер ташын.
Планетаның чиксез бу урамын
күптән төзи инде безнең халык:
һәрбер ташын йөрәгеннән алып,
һәрбер ташын йөрәгенә салып!
Яңа Чаллы үзәгеннән үтә,
ераккарак,
һаман ераккарак...
Төзүченең йөрәк тибешендә:
«Өзелмәсен! —
дөнья тора карап!»
Ышанабыз:
ялгышалар күпләр.
Ышанмыйбыз дөнья ялгышына.
Ышанабыз:
кешеләрнең,
җирнең,
шәһәрләрнең
якты
язмышына!
Төзүче без!
Димәк, көрәшчеләр,

күкрәк сугып алай димәсәк тә.
Төзелә монда җирнең баш урамы,
дәвам итә
моннан
киләчәккә!

**5**

*Киләчәккә бара,*
*үз иленең*
*уртак итеп язмышларын, юлын.*
*Кешеләрне заманалар бүлә,*
*шәһәрләр дә шулай —*
*буын-буын.*

Дөнья бүген сиксәненче елда,
ун яшендә, димәк, Яңа Чаллы.
Яше белән әле сабый гына,
эше белән — инде егет чагы.
Чирек гасыр салына сарайлар да:
кыела ташлар,
кыела кеше җаны...
Ни бәядер истәлеге-даны,
нигезендә ятса халык зары.
Шатлык булып,
көлеп туды Чаллы.
Чулман яры буйлап гөрли алкыш.
Күләгәсез,
якты аның таңы,
безнең күктә тагын яңа балкыш.
Тарихмыни ун ел шәһәр өчен?
Ул бары тик безнең елъязмада.
Ә тарихы шәһәр дигән түгел,
Чаллы дигән аерым кулъязмада.

Бүген туган Чаллы бик күпләрнең
тарихына барып тоташа ул.
Заман белән заман охшашмаса,
халык белән халык охшаша ул.
Тарихмыни ун ел?
Ун меңләгән
тарихларны инде Чаллы күрә.
Халыкларның уй-хисләрен, җырын,
язмышларын Чаллы уртак бүлә.
Күпме язмыш —
шуның чаклы тарих.
Чаллы белән ил язмышы бергә.
Урамнарга кеше
Тукай,
Пушкин,
Сәйдәш,
Шишкин,
Җәлил белән керә!
Урам исеме генә түгел алар,
исемнәр күп безнең урамнарга.
Һәр халыкның Тукайлары килә
булышырга бура бураганда.

Үлчәмибез еллар белән генә,
ул тарихның үлчәүләре бүтән.
Менә шушы бүген салган йортлар

хыяллардан ничә кабат үткән!
Яңа Чаллы нигә балкымасын?
Балкышлары шул ук, бер үк күктән.
Күпме генә еллар аермасын,
Казан,
Мәскәү,
Чаллы
тоташ күптән!

Дөнья бүген сиксәненче елда.
Ун яшендә бүген яңа Чаллы.
Яше белән — сабый,
җаны белән —
егет чагы,
яшәр,
үсәр чагы.
Тик хыялда иде ун ел элек.
Тизрәк үтә гомер әкияттән дә.
Ел үсәсен — айда,
көндә үсә.
Яңа Чаллы — яңа әкиятнамә.
Елъязмасы кыска.
Тарихы зур.
Хыялларның таза канатлары.
Яши Чаллы,
заманананы аңа
алып керә Тукай пар атлары!

***

Кешеләрнең таныклыкларына
мин бер махсус билге уяр идем:
әгәр булса,
«ЗУР ХЫЯЛЫ БАР» дип,
баш хәрефтән язып куяр идем.
Бүлә торган булса аны кеше
йөзенчегә берне,
меңенчегә...
мин бирдерер идем
(кемгә-кемгә!)
шагыйрь белән
башта төзүчегә.
Кагылмасын иде бер казык та,
яңа йортка нигез салынмасын. —
Шәһәр түгел, мунча салырга да
хыялсызлар
берүк
алынмасын!

Алынганнар!
Шәһәр булыр, дигән,
утырткан да бер таш,
замандашым.
...Ялан кырда искән җилләр генә
тузгытканнар аның яланбашын.
Алынганнар!
Тездән сазга батып,
шушы кырга кергән минем чордаш.
Күз алдында ап-ак шәһәр торган,

ә янында торган
бары бер таш.
Бары бер таш.
Ләкин хыялый таш.
Ышанмас та кайбер акыллылар.
Шунда да шул хикмәт:
без кичергән
хыялларның тирән акылы бар.
Алынганнар!
Бары ун ел гына...
Бу — хыялның юкса сабый чагы.
Зирәк бала кебек
үзебезне
һәм хыялны узып бара Чаллы.
Алындылар!
Ун ел элек монда
алып килде бер таш
минем чордаш.
Бөтендөнья картасында тора
шәһәр булып хәзер
шул горур таш!

Иң яраткан төпчек балабыз күк
аңа карап-күреп туялмыйбыз.
И көләч тә үзе,
И матур да —
шушы иде безнең хыялыбыз!
Шушы иде безнең хыялыбыз.
Нинди булыр, үсеп җиткәч, бала?
Карыйбыз да алга...
карыйбыз да...
хыялларны тагын борчу ала.
Күпме кеше,
ничә кибете бар —
гаме инде анда гына түгел.
Җаны нинди,
рухы нинди булыр,
нинди булыр моның
йөрәк,
күңел?!
Баракларда күбрәк,
шәһәрләрдә
сирәк яши шәһәр салучылар.
Алар китәр.
Тагын йөз елдан соң
нәрсә әйтер монда калучылар?
Чакырамы хыял йөз ел алга?
Маяклары шуннан дәшә микән?
Син салырсың бер йорт,
йөз ел алда
ун йорт булып ул йорт яшәр микән?
Йөз елларга таба безнең уйлар
чәчәк ата-ата барырлармы?
Хыялларны безнең
бу шәһәрдән
йөз елдан соң күреп танырлармы?
Шул турыда бүген безнең хыял.
Шәһәр бала әле,
хыял бала.
Оныкларга сөенечкә дигән

нигезендә асыл хыял кала.

Яши кеше.
Бөек хыялларның
белеп булмый кайда башланасын.
Үсә Чаллы.
Кемнәр өчендер ул
хыялының бүген башкаласы.
Белә кеше
кайгыртуны еллар
йөзе-меңе белән кайтарасын.
Безнең алда яшьлек
һәм яшәеш,
тик хыяллар гына,
тик хыяллар гына картаймасын!

1980 — 1981

## Уел

*(Поэма)*

Ишеттем мин кичә, берәү җырлый...
...Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

*Г.Тукай*

**1**

Бер моң яши миндә.
Минем белән
бергә туган, дисәм, ялгыш булмас.
Шушы моңны югалтмасам гына,
җирдә минем җаным ялгыз булмас.
Бишегемнән килгән шушы моңга
ияләнеп булмый,
гадәтләнеп.
Гомер буе тыңлыйм,
гомер буе
үз халкыма үзем гаҗәпләнеп.
Көлә димә аны,
елый димә:
куанычы һәм сагышы бергә.
Җырлый халык.
Халык җырлаганда
көлә күрмә берүк,
елый күрмә!

Язган халык.
Чыгышын да язган.
Тумышын да язган,
еллар чиккән.
Үзен-үзе таныр вакыт җиткәч,
гасыр тузаннарын сөрткән биттән.
Язган халык:
туган елын,
урынын,
шөгылен язган,
язган кәсепләрен.
Дошманнарны җиңүләрен язган,
үзен аның кемнәр рәнҗеткәнен.
Кабер ташы,

баш сөяге,
кылыч...
Курганнарда туктап халык уза.
Киләчәккә килеп җитәр-җитмәс
тузлар туза,
ташта язу туза.
Гадәтләре,
халәтләре — бары
килә безгә килә алган кадәр.
Тарих тугры:
һәрбер таш кисәге
саклап торган безгә бирәр хәбәр.
Кайда?
Кайчан?
Ничек?
Җавапларын
бүгененә кадәр укыйм аның.
Бу аз миңа!
Бир син аның миңа,
ачып бир син аның газиз җанын!

Үзе туып басып торган төштә
ни уйлаган,
ничек уйлаган ул?
Данын җуйган чакларында ничек,
ничек итеп аңын җуймаган ул?
Кадере ни аның,
җәбере ни?
Нинди аның саны,
горурлыгы?
Каян килә,
каян килә аның
бу дөньяда төз, нык торырлыгы?
Мескен булыр иде, иркә үссә.
Моңлы батыр булган сызланудан.
Нишләп үзен кызгандырмый торган
халык була үзе кызганучан?
Бик җитәрлек атсыз-йортсыз чагы.
Булды микән аның моңсыз зары?
Йөрәгеңне кысса...
ул зармыни?!
Моң гына бит ул зар,
тик моң бары.
Моң гына бит,
моңлы моң гына бит.
Бар гомере сыйган шушы моңга!
Йөрәгеңне кысса...
син халыкны,
син халыкны әнә туктап тыңла!
Бик кадерләп төргән тузда түгел.
Ташларга да чокып уелмаган.
Иң кыйммәтле асыл гәүһәрләре
биктә түгел,
әмма җуелмаган.
Сак кына тот.
Чиста кулың белән.
Тапланмасын берүк.
Буялмасын.
Бер нөсхәдән,
бары бер нөсхәдән

халык күңелендә кулъязмасы.
Һәр бөртеге аның кеше рухы,
кеше җаны океанында тапкан.
Халыкныкы хәзер.
Авторларын
эзләп табып булмый инде ВААПтан.
Үзенеке аша халыкныкын
тоя белгән кемнәр,
күрә белгән?
Мәңгелеккә барып җитсен өчен
яза алган халык йөрәгенә.
Кемнәр алар?
Тарих телсез монда.
Җырларның да туза таныклыгы.
Инде халык җырны үзенә алган,
җыр язучы чөнки халыкныкы.
Кемнәр алар
бөтен бер милләтнең
рухын илгә ачып бирә алган?
Киләчәккә җырын озатканда,
кайсы чатта кемнәр басып калган?
Кемнәр алар
моңны моңга ялгап,
тоташтыра алган чорны чорга?
Кемнәр алар?
Халык кадәр халык
кулын куйган кемнәр язган җырга?

Тыңлап торам уй-хисләрем белән.
Халкым минем җырлы, моңлы илдән.
Башымны иям моңга җиргә кадәр.
Имзасы бар:
халык җыры дигән!

Актарма син ертык тарих битен.
Көндәлеге үзенең бар бит аның.
Тыңлыйк әле,
тыңлыйк халык җырын,
халык җырын тыңлыйк —
халык җанын!

**2**

Диктор:

— Тапшырабыз сезнең игътибарга
иске җырлар.
Быел ерак Алан
авылында булган чакта безнең
студентлар ишетеп язып алган.
Кайсы елда?
Кайда?
Кем чыгарган?
Ирешкән ул безгә ничек әле?
Бу турыда нәрсә әйтер икән
шушы авылда үскән Җамал әби?

Җамал әби:

— Инде миңа сиксән тулып артты.
Әйтә алмыйм: күпме җырлар яше.
Мин үземне белгән көннән алып

безнең якта алар һаман яши.
Чыгаручы минем Уел бабай.
Үзе җырлап үзе уйнаган ул.
Икесен дә бик яраткан, диләр:
дөнья белән җырдан туймаган ул.
Мин күрмәдем үзен.
Яшьтән үлгән.
Бик зур кайгы итеп сөйли халык.
Җыры өчен,
теле өчен, диләр,
янып үлгән бабай,
утта янып...
Сукыр Уел бабай фаҗигасе
әбиемнең сеңгән бәгыренә.
Әйтеп үлде,
мәрхәмәтле бул, дип,
сазы-җыры белән каберенә.

*

Җырлый Алан.
Моңга күмелеп ята.
Уел үзе килеп керде көйгә.
Чигенде дә вакыт йөз ел артка,
йөз яшьлек җыр керде безнең өйгә:

*Кара урманнарның аръягында*
*Кара болыт килә күкерәп.*
*Заманалар авыр, дошманнар күп,*
*Күтәрәдер калын күкерәк.*

Ерак кунак сыман,
ят та түгел,
бик таныш та,
таныш түгел дә ул.
Беренче кат ишетү әле җырны,
ә нигә соң күптән күңелдә ул?!

*Утырдым ла көймәнең түренә,*
*Ишеп киттем суның үренә;*
*Сөйләсә дошманнар сөйләсен,*
*Кеше керми кеше гүренә.*

*Сахраларда үскән сары чәчәк,*
*Бакчаларда үскән гөл кебек;*
*Яшь гомеребез үтеп бара*
*Кыйблалардан искән җил кебек.*

Һәр заманның үзенең җыры була.
Җырга сеңеп калган ул еллар да.
Чор сулышы җырда,
җырчыларда,
халык җырчы иткән Уелларда.

*Елтыр ла гына,*
*елтыр утлар яна,*
*Юлаучылар,*
*Юлаучылар яткан җир микән?*

*Үзе лә җырлый, үзе лә көйли,*
*Күп нужа лай,*
*Күп нужа лай күргән ир микән?*

Килеп җитә алган безнең көнгә
кабатланып мең кат моңы-сүзе.
Җырларына халык кулын куйган
кем ул Уел,
кем ул Уел үзе?

**3**

Зират түгел.
Басу ызанында —
ялгыз кабер
саклый каеннары.
Бер зират та күтәрә алмас кебек
каеннарда калган кайгыларны.
Иңнәрендә шәлләр җилфердәшә,
кайчак җилләр озак туктамыйлар.
Китә алмый калган кайгылары
мөлдерәп тора авыр чукларында.
Килдем әле Уел каберенә,
тыңлап торам Уел тавышларын.
Каеннарда җилләр генә түгел,
каеннарда —
еллар сагышлары.
Ялгыз кабер.
Халык,
еллар өчен
ялгызлыктадыр күк кадере дә.
Зираты да була бер кабердә,
зират була ялгыз кабере дә.

Кәүсәсенә кулым тиде микән?
Орындымы чуклар битләремә?
Басып торган шушы җир язмышы
ачылып китте кабер итәгендә:
Әнә үткән гасыр,
әнә авыл.
Салам башлы әнә өйләр тора.
Сәкесендә,
чыра яктысында
Алан авылы әнә кич утыра.

*

Кышкы кичләр үтмәс кебек,
йон булмаса кабада.
Кайгы-хәсрәт бетмәс кебек,
җыр кермәсә арага.
Күрше хатыннар җыелган
озын кич үткәрергә.
Айныйсың бераз уеңнан,
булганда бергә-бергә.
Җырлыйлар моңлы хатыннар:
заманы, чоры җырда.
Хатыннар түгел, акыннар
утыра кебек монда.

Зырылдап орчык әйләнә,
чырада тибри ялкын.
Җырларга җырлар бәйләнә,
моңы күңелгә якын.
Җырларга җырлар өстәлә,
кайгыга — кайгылары,
итәк очына сөртәләр
күзләрен кайсылары.
Хәсрәтләре хәттин ашкан...
Ә җырдан булмый туеп.
Уйный Уел яңабаштан,
башын сазына куеп.
Дулкынлана сазы хистән,
хатыннар тынып кала.
Заманны белим дисәң,
Уелны тыңлап кара.

*

Мин таяндым каен кәүсәсенә
җырчы Уел моңын ишетергә.
Ә ул җырда үзе генә түгел,
җырлый авыл,
җырлый иле белән.
Халык уе,
халык моңы анда.
Бар илнекен күңел җыя икән.
Җырчы күңеле шундый:
сөюе дә,
нәфрәте дә бергә сыя икән.

Уел җыры:
*Ат аунаса басуымның*
*ызанында,*
*җитмәс иде җирем аяк сузарына.*

*Анысын да карун Закир*
*тартып алды.*
*Бу гаделлек җирдә бармы,*
*илдә бармы?*

*Хәерче дип атамагыз,*
*туганнарым.*
*Бирер идем хәзинәмдә*
*бөтен барын.*

*Барчагызны иң бай кеше*
*итәр идем,*
*сазым белән җырым гына*
*калды минем.*

*Фани дөнья бигрәк кырыс,*
*бик җәберле.*
*Ә яшәүләр, ә гомерләр*
*бик кадерле.*

*Кая барсаң, Закир кебек*
*этләр бардыр,*
*бу дөньялар киң булса да —*
*безгә тардыр.*

*Моңлы бала түгел идем,*
*моңнар иңде.*
*Йөрәк маем сызып-сызып*
*тама инде.*

*Өйдән өйгә хәер эстәп*
*йөрим хәзер.*
*Бертуктамый моңаерга*
*сазым әзер.*

*Сөйлим үзем, уйныйм үзем,*
*җырлыйм үзем.*
*Сезне күреп җуанадыр*
*ике күзем.*

*Бу дөньяда газаплылар*
*күптер-күптер.*
*Бүтәннәр дә моңаядыр*
*минем күктер.*

*Гомер итү безгә кыен,*
*байга — уен.*
*Бу җырларны чыгаручы —*
*җырчы Уел.*

*

Уел җыры Уел зарымы соң?
Ялгыз зарлар кемне уйландыра.
Җырга күчсә зарлар,
мескенлектән
ун баскычка биек,
өстә тора.
Сукырның да күрер өмете бар.
Өмет тулы халык сагышында.
Моң, җыр булып ага гомер, еллар.
Нәфрәт кайный гомер агышында.
Уртак аның елмаюы, яше.
Уел монда бары башлап бара.
Уелмыни? —
Халык үз язмышын
кич утырып шулай җырга сала.

**4**

Ияреп барам Уел язмышына,
урала җыр хәсрәт-кайгыларга.
Көчлеләргә каршы җыр яз, имеш.
Җанны саклау кыен андыйларга.
Кемне көтә пычак,
кемне баулар.
Кемнәрнедер куып тота уклар.
Сулар йота,
йота билгесезлек,
күккә аша-аша йота утлар.
Җырлый-җырлый, килә-килә, Уел,
нигә әле синең тукталуың?
Бу — таң түгел,

бу — шәфәкъ та түгел,
бу — ялкыны янгын утларының.
Моннан ары инде җырлар да юк,
сазың да юк,
өең,
авылың,
халкың...
Күз алдыңда синең ал нур түгел,
күз алдыңда янгын,
зәһәр ялкын!

*

Җыела булган кадәре —
карт-карчык, бала-чага.
Алып кайгылы хәбәрне,
малайлар кырга чаба.
Бөтен йорт ялкын эчендә,
җитез дә икән бу ут.
Комсыз да икән, көчле дә,
усал да икән бу ут.
Гөрселдәп түбә ишелә,
болганып ала учак.
Ярсыган атлы кешеләр
басудан кайта шулчак.
Туктала атлар, тыпырдап.
Закир бай тиргә баткан.
Ияреп Закирга кырдан
туган-тумача кайткан.
Шашынган Закир, ярсыган,
дөрләгән утка карый:
— Ник янгын минем йортымда,
ник башка өйләр янмый?!
Кычкыра һаваны ярып:
— Уел! Уел эше бу!
Уелны табыгыз эзләп,
ут төртүче кеше — ул!
Уелны, өенә барып,
алалар якасыннан:
«Авылда берүзең калып
ут төртеп ятасыңмы?»
Китерә Уелны сөйрәп
Закирның якыннары.
Ут яна талпынып, дөрләп,
күкләрдә ялкыннары.
Карт-коры дерелдәп көтә:
нишли бу Закир явыз?!
Йөрәкләрне ярып үтә
өшеткеч салкын аваз:
— Салырга! Утка салырга!
Кара күмергә калсын!
Үзе яккан бу тәмугта
кинәнеп үзе янсын!
Очрашты Уел, Закир, Ут.
Тукталды язмыш янда.
Кешедә аның эше юк,
янгын ашкынып яна.
Уелның бер уй башында:
«Нигә мин җирдә артык?!

Нинди гөнаһым хакына
үләргә утта янып?»
Закир уйлый: «Көнең бетте,
оҗмах юлы такырмы?
Закир этме? Уел этме? —
Менә җырның ахыры!»
Ут: «Кабынгач янам инде,
йотам — ни туры килә.
Беләм, зәһәр дисез мине,
кем белә бит, кем белә...
Юк мәллә миннән зәһәрләр,
ник утларга саласыз?
Шаһитлар сезне каһәрләр,
мин сүнәм, сез — каласыз».
Закир, Ут — хөкем һәм палач.
Уелга якын үлем.
Арада минутлар калгач,
үксимсең, үксер күңел?..
Сөйриләр җырның хуҗасын
салырга янган утка.
Илерә картлар: «Узасың,
тузасың, Закир, юкка!»
Ялвара Уел: «Үтермә!
Нахак бит! Ялган! Ялган!»
Гомерне атлап үтәргә
соңгы мизгелләр калган.
— Туктагыз! — Закир тавышы. —
Мин кансыз дошман түгел.
Дөрестерме бу, ялгышмы —
кичерә алам бүген.
Тик менә халык каршында
җырла җырның яңасын.
Ул сиңа да, ул барысына,
ул миңа да ярасын...
Бермәлгә яктырып китә
Уелның йөзе кинәт:
исән калуга ни җитә,
яшәргә була, димәк.
Закирга кирәк нинди моң?
Карый ул янган утка...
Ничек җырларга икән соң
җанда андый җыр юкта?
Сазына кагылды кулы,
сыйпады җайлап кына.
Кылларын чирткәләп куйды
сак кына, сайлап кына.
Яңа моң килгәнен көтте,
салды ул бөтен назын.
Эченнән генә ул әйтте:
«Йә, коткар инде, сазым!»
Дәшмәде аның сазы һич,
килмәде көткән моңы.
Андый җыр булмый икән ич,
аңлады Уел моны.
Аңлады Закир көткәннең
туачак түгеллеген.
Моңнары башка икәнен
Уеллар күңеленең.
— Тимәгез! — диде.— Яшәсен,
хәер эстәргә калсын!

Тик сазы гына дәшмәсен,
җырлары утта янсын!
Алдылар тартып... Аттылар
утларга сазын аның.
Әйтерсең утка салдылар
бәгырен, җанын аның.
Чорнады йөрәген ялкын
бер мизгелдә, бер мәлдә.
Күкләргә ашкан бу янгын
җанына күчте мәллә?
Ыргылды Уел, атылды
утларга, ялкыннарга.
Уелны тоталмый калды
ятлар да, якыннар да.
«Ах!» итеп алды бер мәйдан.
«Ах!» итеп алды ялкын.
...Бу кызуда килә каян
йөрәк өшерлек салкын?

Утлы кисәүләр эченнән,
ертып ялкын пәрдәсен,
таянып соңгы көченә,
Уел сөйри гәүдәсен.
Үрмәләп чыга. Өс-башын
ут чорнаган, ут алган.
Булмаса да инде ашы,
соңгы минуты калган.
Яраткан сазы кулында.
Үрмәләп, яна-яна
килә Уел. Ә юлында
һушыннан китеп аңа
карый халык. Ул аңында.
Алдында мәйдан, халык.
Яраткан сазы янында...
Егылды тынсыз калып.
Соңгы минутында аның
калгандыр әйтер сүзе.
Ачып салыр иде җанын,
өлгерсә болай үзе:
«Утларга сала, суына —
язмыш ул шундый гаҗәп.
Сазым булмаса кулымда,
мин илдә кемгә хаҗәт?
Юк минем бүтән хәзинәм,
сагышым бар, назым бар.
Мирасым да бик әз генә:
җырым белән сазым бар.
Гомер буе җырга салдым
сагышымны, назымны.
Мин утлардан йолып алдым
сезгә шушы сазымны».

Көн буе пыскый кисәүләр.
Заманалар алама...
Сызланып җилләр исәләр,
җилләр елый Аланда.

**5**

Тынмый җилләр Уел каберендә.

Башын игән өлкән каеннары.
Чукларында һаман эләгеп тора
замананың кара кайгылары.
Җиңалмаган халык ялваруы,
кертмәгәннәр зират капкасыннан.
Мәеттән дә залим үчен алган,
аерым җирләп ата-бабасыннан.
Начар үлем белән үлде, дигән.
Уел үзенә үлем сайлый алса...
Ул сайламас иде...
Нәрсә була
җирдә, әгәр берәү үлми калса?
Үлми калса...
Җырга да җан кирәк!
Юк!
Халыкта җырның
юк үксезе.
Тик шулай да кануны бар аның —
үлем аша килә үлемсезе.
Уеллары кала утта янып,
халык җыры утлар аша килә.
Канун шундый:
чордан чорга күчеп,
бер-беренә җырлар дәшә килә.
Без белмәгән уллары күпме!
Уртак моңнар белән тоташ алар.
Җырлар ялгыз түгел,
барысы да
Уелларга барып тоташалар.
Зиратта да ул югалмас иде.
Аерым булгач халык үзгә иткән:
каберендә әнә башак шаулый,
туфрагына халык икмәк сипкән.
Авылының арыш диңгезендә
офыкларга чума басу юлы.
Кыр башлана кабер итәгеннән,
уйный рәшә — Уел күзе нуры.
Башакларын чайкый җилдә арыш,
башаклары авыр, таза, тулы...
Җир тирбәлә кебек,
дулкын-дулкын,
башак шаулый кырда —
Уел моңы.
Җырлый әнә Уел каеннары,
Уел башаклары,
Уел кыры...
Туфрагына сеңгән,
һавасына,
ярасына сеңгән аның җыры.
Яши халкы,
яши халык җыры,
кырларында яши,
күкләрендә...
үткәннәре бара киләчәккә,
киләчәге яши үткәнендә.
Йөзәр елдан,
меңәр елдан кайтып
әйтер сүзе һәрчак бар бит аның!
Тыңлыйк әле,
тыңлыйк халык җырын,

халык җырын тыңлыйк —
халык җанын!

1980 — 1983

«ИНАНУ» китабыннан

(1968 — 1985)

V
*Омтыла җан гөлләр янына.*
*Чәчәк төсен күңел сагына.*
*Гөлләр тулы болын авазы*

сагыш булып җанга сарыла.

## Авыл, чишмә, инеш...

М.Юнысның «Юлда уйланулар»
дигән әсәрен укыгач.

**1**

Хыялыбыз йөзә иде күптән
зур океаннар буйлап.
Инешләрдә батып яттык башта
диңгезләрне уйлап.

Чишмәсенең суын эчә-эчә
шактый зураелган.
Көнләшерлек чаклар җитте безнең
сабан тургаеннан.

Монда инде безгә бар да таныш —
китәселәр килә.
Адәм җитмәс җирләр бардыр сыман —
җитәселәр килә.

Чыгып киттек басу капкасыннан,
башлар күктә иде.
Безне көтә ачылмаган серләр,
могҗизалар иле.

Без ачасы җирләр илаһидыр,
зур-р булырга тиеш.
...Бик бәләкәй булып калды бездән
авыл,
чишмә,
инеш.

**2**

Шуннан бирле гомер сәяхәттә,
күпме серләр таптык!
Ничә илнең-җирнең капкаларын
инде ачып яптык.

Матур-матур таулар, елга-сулар
күрдек сәфәрләрдә.
Хозурланып йөрдек искитәрлек

гүзәл шәһәрләрдә.

Өлгердек без җиде җиргә җитеп,
җиде диңгез кичеп.
Төрле-төрле чишмәләрнең
йөрдек суын эчеп.

Ерактагы дөнья зур, илаһи,
тылсымлы һәм серле.
Сәяхәттә йөреп мин үземә
ачтым иң зур серне.

Киткән чакта мин бит бер нәрсәне
аңлый алмый киткән,
еракларда үзәк өзелмәсә,
аңлау кыен икән:
көтә икән безне гомер буе
ачылмаган килеш
иң тылсымлы могҗизалар иле —
авыл,
чишмә,
инеш!

1983

## Шимбә өмәсе

Йөрдек бүген көрәк-сәнәк тотып,
хуҗа булып йөрдек һәрберебез.
Күңелләргә бигрәк якын икән
авылыбыз безнең, шәһәребез.

Төшке аш та бүген онытылды,
күп эшләдек, ләкин ачыкмадык.
Эш бетәргә биш-ун минут кала
кайтырга да өйгә ашыкмадык.

И көләсе килә, шаярасы,
и яшисе килә матур булып.
Кая баксаң — безнең дуслар икән,
бөтен кеше йөри тату булып.

Тартып ала ирләр авыр эшне —
хатын-кызны сөеп, саклап кына.
Ә хатын-кыз йөри (йа Илаһи!)
ярдәм итеп, җөпләп, мактап кына.

Безгә нәрсә булды икән бүген?
Нәрсә булды икән тирә-якка?
Безгә карап кояш көлеп тора,
күгәрченнәр гөрли безнең хакта.

Күңелебез дә узды бәйрәм кебек,
көч-куәт тә артык түгелмәде.
Урамнарны чистартабыз диеп,
чистартканбыз бугай күңелләрне.

1983

## Шәһәргә

Син мине кыерсытмадың,
мин дә кыерсытмадым.
Икәү бергә сызып куйдык
маңгай җыерчыкларын.

Мин бичараң түгел синең,
үткәне бергә үткән.
Киләчәкне бергә-бергә
уйлыйбыз инде күптән.

Әшулай да сагынам мин,
ямансулыйм кичләрен:
Калгандыр качып авылда
иң мөкатдәс хисләрем.

Калмаса, юксынмас идем,
мин аларны юксынам.
Бөтен нәрсәм дә бар минем,
әллә нәрсә юк сыман.

Синдә туып, синдә үскән —
утларга карый икән.
Йолдызлар булмаган чакта,
утлар да ярый икән.

Үпкәләмә... Син гаепсез...
Мин бит сине төзегән.
Син дә минем кебек инде,
шул авылдан өзелгән.

1984

## Шул бер ишек

Кайткаларга туры килә кайчак
авылларга —
туган бишегеңә.
Яшәсәк тә күптән шәһәрләрдә,
без өйрәнгән авыл ишегенә.
Шыгырдаса бераз шыгырдасын.
Дерматин да аңа кагылмасын.
Тупасрак булса булсын бераз,
җеге җеккә килеп ябылмасын.
Ачып керү шуны күңеллерәк,
күңеллерәк шуны ябып керү.
Күңеллерәк үзең белән бергә
берәр кочак суык алып керү.
Бусагадан аяк атлаганчы,
минем күңел инде кереп китә.
Бераз гына туңган булса, йөрәк
каз мае күк кинәт эреп китә.
Алып керә килен сөт исләрен,
энекәш кайта арыш исе белән.
Бер ачылып,
бер ябылып тора
шул бер ишек авыл хисе белән.
Кичләр җитсә,
урамнардан җанны
тирбәтерлек моңнар, көйләр керә.
Шәһәремә кайтсам, өч көн тоташ
төшләремә шушы өйләр керә.

Ачык калган авыл ишегеннән
шаулый урман,
шаулый чишмә,
инеш...
Бер кечкенә генә шушы ишек аша
киенмәгән,
төренмәгән килеш
тормыш үзе,
яшәү үзе көн дә
кереп-чыгып тора,
йөреп тора.
Мөлдерәгән моңлы күзе белән
минем күңел шуны күреп тора.
Без өйрәнгән:
авыл ишекләрен
ачып-ябып үскән малайлар шул.
Инде хәзер дерматинлы ишек
ачып керә торган агайлар шул.
Суыгы да керми...
җылысы да...
Бөтенесе тышта кала хәзер.
Агайлар без, дим дә...
без, мөгаен,
балалыгын җуйган бала хәзер.
Күңелләр бай әле.
Әле ярый
шул ишекләр ачык безгә һаман.
Мин авылга барып кайткан саен
күңелемә нидер алып салам.
Бар хәзинәм шунда ята минем,
мин кисәкләп аны алып кайтам.
Ничә кабат ярлы килеш китеп,
ничә кабат шуннан баеп кайтам!
Күп нәрсәләр җитми безгә бүген,
авылда да җитми — үзем беләм.
Гомер буе җитми шул бер ишек,
алып кайтып булмый үзең белән!

1985

## Якташларга хат

*Социалистик Хезмәт Герое*
*якташым С.Шәйдуллинга*

Бер тынгысыз уйлар өермәсе
аның күңелен борчып тора.
Бик җентекләп язып,
хаты белән
теләде ул шуны аңлатырга.
Күп уйлады:
кемгә,
ничек итеп
язарга һәм нидән сүз башларга?
Нык бер уйга килеп алды каләм,
язып куйды:
«Чаллы, якташларга!»
Туктап калды.
Шул уйларын ничек
аңлатырга белми башы катты.
Күз алдыннан үтте бөтен гомер...

Язганы юк иде мондый хатны.

Чаллыдан ул.
Инде бер гомердер
авылыннан чыгып киткәненә.
Орынып тора иде Кама суы
алар бакчасының читәненә.
Кем гаепле?
Сугыш бетәр елда
йортка кергән үги атасымы?
Кайтмыйм! диеп чыгып китүләре
хак булганмы?
Әллә хатасымы?
Ансатмыни татар баласына
ияләшү читтә телгә-сүзгә?
Ул белмәгән, ул күрмәгән дөнья —
җирләре дә үзгә,
җыр да үзгә.
Шул үзгәләр аны үз иттеләр.
Югалтты да нидер, нидер тапты.
Тормыш үзе ятим булган чакта
атасызлар аңа җиде ятмы?
Калдырмады заманасы читтә,
читләтмәде аны яшәү тәме.
Тар забойга сыя икән кайчак
кеше белән яшәвенең гаме.
Алтын түгел аның шахтасында.
Бер уйласаң, бары күмер генә.
Җылы учак булып янып керде
кара күмер аның гомеренә.
Бәйрәмнәре булды...
Сабантуйлар...
Тик булмады атлар чабышлары.
Башкалар күк моңлы-җырлы булды,
бүтән иде ләкин сагышлары.
Бәхетле ул.
Аның үз бәхете.
Эзләми ул тормышыннан хата.
Бәхетемне читтә таптым, диеп,
буламыни язып мондый хатта.
Чаллыдан ул.
Ата-баба җире.
Монда да бит тирән тамырлары.
Туган якта аның ни даны бар?
«Кайттыңмы?» — дип танып алырлармы?
Кешенең бер дөрләр чагы була.
Бәлки инде, йөрәк алай янмас.
Социалистик Хезмәт Герое дип
исем кушты аңа шушы Донбасс.
Туган җире монда улларының.
Шахтер нәселеннән Булат, Алмаз.
Ник аердың миннән аларны, дип
әйтмәс микән шушы Донбасс?
Монда кала хатыны һәм дусы...
Монда тапты аны сөю һәм наз.
Йөрәгендә һаман,
ә каберен
алып кала аның шушы Донбасс.
Үзе белән бар гомерен алыр,
ташлап киткән җире булып калмас.

Җылы булып,
моңлы җыры булып
йөрәгендә калыр аның Донбасс.
Буйсындырды ул һәрчак акылына.
Йөрәген дә кайчак тыя алмады.
Үткәннәре дәшә аны бүген.
Киләчәге дәшә,
хыяллары...
Ике як та якын,
ике яр да...
Уйлап торды озак шушы хакта.
Йөрәгемне ярып калдырам, дип
буламыни язып мондый хатта?!

Чаллыдан ул.
Татарстан...
КамАЗ...
Килеп тора хәбәр арты хәбәр.
Тынгы бирми аңа һаман бер уй:
«Мин дә булсам туган якта әгәр...»
Үз кадерен эзләп хыялланмый.
Кулдан килә әле бөтен эше.
Мондый чакта аның Чаллысында
кирәк булмасмыни шахтер кеше?
Тарта аны нидер.
Чакыра аны.
Карышсаң да барыбер шул көч җиңә.
Бик кайтасы килә аның бүген
үзебезнең якка — туган җиргә.
Авылы бит шәһәр булып үсә,
ансыз үсә,
шуңа әрни күңел.
Шул авылның бер кешесе булып
әрни күңел.
Герой булып түгел.
Кем белә бит,
аның кебек, бәлки,
туган як та аны сагынгандыр.
Үзе генә әле монда сыман,
язмышлары инде Чаллыдадыр.
Язмышларның юлы, ай, әйләнгеч,
язмышларның юлы чалу-чалу.
Ансат түгел аңа кайту хәзер,
мөмкин түгел әмма кайтмый калу.
Тыя алмый инде ул йөрәген.
Тыеп торсын нигә мондый чакта?
«Кайтам булгач кайтам,
якташлар!» — дип,
бер генә юл язып куйды хатта.

1985

## Үз йортын сала кеше

Ир булып илгә туганның
иң мөкатдәс эшедер:
Тиеш йорт салып керергә
гомерендә кеше бер.
Ырудан килгән, токымнан,
әйткәннәр, тапшырганнар.

Безнең бабайлар бу сүзне
тормышка ашырганнар.
Бурычлы булып калмаган,
ыштансыз калса калган.
Ыштансыз калса калгандыр,
кеше үз йортын салган.
Никадәр өлгер булса да,
нужа да калышмаган.
Үз йортын салырга кеше
гомерен багышлаган.
Тормышында төп эш итеп
шушыны күргәндер ул.
«Салдым! Кала миннән йорт!» — дип
шатланып үлгәндер ул.
Ырудан килә, халыктан,
мәгънәсе инде тирән:
тугансың икән, гомернең
кадерен белергә өйрән.
Эшләрең калсын йорт сыман,
югалмаслык, карарлык...
Бөтен булып, төзек булып,
кешеләргә ярарлык.
Йорт җиткерү ансат түгел,
булмый салып түземсез.
Җанын ярып салса кеше,
илдә йортлар үлемсез.
Батырлык түгел, бурыч бу,
гомерең белән түлә.
Үз йортын салмаган кеше
тумый-яшәми үлә.
Гомеренә тиң эшен көтә
һәр замана ирләрдән.
Бер кеше дә бу дөньяга
мәңгелеккә килмәгән.
Мәңгелек тик эшләр генә,
йортыбыз һәм илебез.
Үз йортларын сала торган
замананың ире без.

1984

***

Инде кич.
Күкләр дә караңгы.
Якыннар сыенышып йоклаган.
Иртәгә кичләрем булырсың,
ә бүген яратып йоклатам.
Йолдызлар, әй, ерак...
Ай ерак...
Ярату кыен ул ерактан.
Иртәгә йолдызым булырсың,
ә бүген яратып йоклатам.
Йолдызлар сүнәләр,
Ай тона.
Бәхетле җаннарга туа таң.
Иртәгә таңнарым булырсың,
ә бүген яратып уятам.
Бүгенгә Ай да бар, таң да бар,

Аен да, таңын да югалтмам,
ә бүген яратып уятам.
Мин сине яратып уятам.

1982

## Дустыма, яшьтәшемә

**1**

Мин дә, син дә ул чак
бик яшь идек әле.
Әмма тирән иде
балачакның гаме.

Урамнарда иде,
уеннарда күңел.
Ләкин күңел генә
хәл итүче түгел.

Безне көн дә көткән
сука иде, тырма.
Тамак хакы безне
куа иде кырга.

Елый-елый чаптык,
елый-елый урдык.
Атлар тыңламаса,
гарьләнүчән булдык.

Үтте балачак та,
үтте инде яшьлек.
Бүген әле менә
үткәннәргә дәштек.

**2**

Икебез дә, дөрес,
бик яшь идек әле.
Тамак хакы гына
түгел иде гаме.

Дөнья кушты безгә —
чәчтек, урдык, сөрдек...
Буразналар буйлап
шигырь ятлап йөрдек.

Тормыш авыр диеп
һич юк иде үпкә.
Җирдә иде язмыш,
хыял иде күктә.

Шигъри иде безгә
ул басулар, атлар.
Шигырь булып инде
җанга тирә-яклар.

Без бары тик Такташ
булачакбыз, дидек.
Валлаһи, дим, кордаш,
без бик бөек идек.

**3**

Зарланмыйм мин хәзер
яшьлек ялгышымнан.
Мин канәгать болай
тигән язмышымнан.

Кәгазь, каләм — инде
минем корал шушы.
Әллә язмыш кушты,
әллә йөрәк кушты.

Ә син безнең кырда
язын, көзләрен дә...
Син һәрвакыт шунда —
җирнең үзәгендә.

Кайткан саен кырда
синең эзне таныйм.
Шигырь укыган күк,
туктап укып карыйм.

Буразналар тирән,
буразналар туры.
Уҗымнарга тигән
изге кеше кулы.

Синең кулны тоям,
синең рухың таныш.
Шигырь юллары күк
дулкынлана арыш.

Ындыр тулып ята,
кордаш, көшелләрең.
...Икмәк күргәч йөзе
балкый кешеләрнең.

Минем икмәк — шигырь,
синең шигырь — икмәк.
Әйтеп кара, белсәң,
кайда күбрәк хикмәт?

Рәхмәт үткәннәргә,
рәхмәт сиңа, кордаш.
Мин аңладым бугай
шактый озак торгач:

Кайда изге гамәл,
кайда изге ният —
шунда икән шагыйрь,
шунда шигърият!

1985

## Көзге яз

Мин ышандым кабат тууларга,
яшәү кирәк, яңарулар кирәк.
Охшамыйлар кайчак еллар елга —
безнең гомер яңаруда, димәк.

Елларның да була төрле чагы,
охшамасын, әйдә охшамасын.
Гел көлеп тә,
гел елап та тормый,
табигать ул белә үз чамасын.

Миңа кара, кеше, дигән кебек,
төзәт, дигән кебек, ялгышыңны,
көне,
ае,
елы белән синең
ул искәртеп куя язмышыңны.

Бу язларым,
бу көзләрем диеп,
гомереңне ничек аерасың?
Шәйләп булмый кайчак,
шәйләп булмый
язлар белән көзләр аермасын.

Көзләр көткән идек — язлар килде,
еллар якты һаман,
көннәр якты.
Бакчаларда әнә алмагачлар
икенче кат быел чәчәк атты...

1983

## Алмалы ел

Алма пешкән кызарып,
алма пешкән алланып.
Иңләп йөрим базарны
алмаларга алданып.

Әллә нинди телләрдә
сатучылар мактыйлар.
Әллә кайлардан килеп,
көчләп кенә такмыйлар.

Сатучыга түгел, мин
алмасына табынам.
Бөтен хикмәт алманың
йөзенә үк язылган.

Алмаларга алданып,
сихерләнеп атлыйм мин.
Алмаларның йөзеннән
шул хикмәтне ятлыйм мин:

Язлар хәерле булган,
җәйләр хәерле булган.
Сөенеп яшик, туган,
көз алма белән тулган!

1983

## Карлар

Көтмәгәндә

(әллә көткәндәме?)
бер болытсыз ява карларым.
Дөньяларга бүген тагын бер кат
ап-ак карлар аша карадым.
Рәхмәт әйттем мин күкләргә карап,
рәхмәт әйттем ап-ак карларга.
Мин кулымны куйдым тагын бер кат
«Яшәү матур!» дигән карарга.
Кемнәргәдер, бәлки, гади кардыр,
минем өчен гади кар түгел.
Яусын әйдә сезнең иңнәргә дә,
минем күңел алай тар түгел.
Кар яуганын бик күп күргәнем бар,
көткәнем бар карлар яуганны.
Бу тормышта минем иңнәремә
чиста карлар гына яумады.
Барысын да юды шушы карлар,
пычрак тормый минем өстемдә.
Рәхмәт сезгә
яуган өчен
миңа
шатлык, юанулар китереп.
Кар бөртеге очып йөри күктә,
безне уйлы-моңлы иттереп.
Бик сөенеп күккә карап торам:
рухым бүген түгел ялангач;
бу дөньяның шушы карлары да
куандырып мине ява алгач!

1985

## **Яраннар***

*(Җыр)*

Өйдә матур, өйдә җәй минем.
Тәрәз төпләрендә үсә гөл.
Урамнардан узып китүче
тәрәзәмә карап үтә гел.
Мин дә карыйм, ләкин бу яктан.
Күренә миңа чиксез болыннар.
Тәрәзәдән кереп килә күк
чәчәк иснәп йөргән колыннар.
Көннәр буе уйга талганнар,
урамнарга карап арганнар —
тәрәзәнең бозын эретеп,
кызыл чәчәк аткан яраннар.

1985

## ***

Җырга-моңга мохтаҗ чагым минем,
сусавымны басар моңыгыз.
Сезгә — җылы,
миңа моңнар кирәк,
түшләремә, кошлар, куныгыз.
Куныгыз сез, кошлар, минем түшкә,
куенымда әле җылы бар.

Бер тыңлыйсы килә онытылып,
кайсыгызның моңлы җыры бар?

1985

## Мәгънә киңәйгәндә

Көтмәгәндә
шундый бер көн килде,
язмыш аңа:
— Гомерең бетте! — диде.
Белә иде.
Ул бу көнне көтте.
Иң авыры
инде баштан үтте.
Кырда үскән
чәчәк сорап алды.
Язмыш белән
берьялгызы калды.
Бу чәчәккә
карап туймады ул.
Исе китеп
шуны уйлады ул:
«Бу чәчәкне
күпме күргәнем бар.
Бу чәчәкне
таптап йөргәнем бар...
Ант итә алам,
шунысы да хактыр —
күрәм аны
мин беренче тапкыр».
Елады ул:
— Рәхмәт сиңа, үлем!
Синең аша
матурлыкны күрдем
мин бары тик
әле бүген генә...
Язмышымдыр...
риза үлемемә.
Кинәт кенә
каян килде кодрәт?
Кинәт кенә
еш-еш типте йөрәк.
Әйтте язмыш:
— Тагын ялгышканмын,
күзгә карап
алдадылар тагын.
Кырда үскән
кыргый бер чәчәк тә
тыгыла бит
минем киләчәккә!

1985

## Яшел сагыш

Авылда печән өстедер,
монда да печән өсте.
Газоннарны чабып йөри

авылдан килгән кеше.

Авылда печән иседер,
монда да печән исе.
Газоннарның печәннәре
ислемай сипкән төсле.

Кырларда яшел арыштыр,
дулкыны җанга таныш.
Көтмәгәндә килеп басты
җанымны яшел сагыш.

1984

## Йөрәк турында

Кулыңны куеп йөрәккә
бер әйткән идең...
Бик тә инанып, кыйналып
син болай дидең:
— Шагыйрьләр йөрәк турында
бик күп яздылар;
йөрәкләр хакында бик күп
җыр чыгардылар;
йөрәкләр турында диеп
күп җырладылар,—
әмма безнең йөрәк өчен
бик тә аз болар.
Шәп итеп яз әле,— дидең,—
тагын да бер кат,
безнең йөрәкләр турында
бер уйлап ныклап.
Синең хисләреңне ул чак
дөрес аңладым.
Шуңа күрә кулга озак
каләм алмадым.
Әллә җиттеме вакыты?
Нигәдер бүген
йөрәк турында язарга
котыртты күңел.
Барлап чыктым үз йөрәгем
кичергәннәрне,
гомер буе шул йөрәктән
үткән хәлләрне.

Шатлыклы көннәре булган:
сөелгән, сөйгән.
Бүтәннәр шикелле ул да
янган да көйгән.
Хыялы канатларында
очып та йөргән.
Бәхетнең дә ни икәнен
татыган, белгән.
Хыянәтләр азмы анда,
азмы алдану...
Һәркайсын да яра итеп
үзенә алган ул.
Нинди генә гаеп аңа
кемдер такмаган...
Нинди генә пычрак аңа

кемдер атмаган...
Тау күтәрә алмас сүзләр
юкмы нахакка?
Йөрәккә яндырып язган
тормыш бу хакта.
Дусларын да, дошманын да
җитәрлек тапкан.
Күпме хыялларын тапкан,
күпме югалткан...
Барысын да кичергән ул —
эзләре калган.
Тормышның һәрбер мизгеле
тамгасын салган.
Барысын да үзенә алган,
кемне саклаган?
Аны сатсалар да күпме,
үзе сатмаган.
Барысын да үзе аша
үткәрә алган.
Икебез дә исән-сау һәм
яшь килеш калган.

Шушылар хакында, дидем,
язарга кирәк.
Кулыма каләм алуга,
туктатты йөрәк:
— Мин сине егет кешегә
санап йөргәнмен.
Карасаң, чыгарып селки
үзенең йөрәген.
Миңа менә шушы гына
җитмәгән иде.
Нәрсәгә соң сиңа йөрәк,
җебегән! — диде.—
Минем турыда лыгырдап
тик йөрмә генә.
Язасың бик килә икән,
яз йөрәгеңә!
Гарьләндем!
Шушы хәлдән соң
әрнеде күңел.
Ә йөрәк турында язарга
мин тиеш түгел!
Моннан соң да дөнья шулай
бик нык йөдәтсә,
язсам язармын
бары тик
шушы йөрәккә.

1985

***

Мин сиңа чәчәк
китергән идем.
— Бу чәчәкләрнең
тиңе юк, — дидең.

Аннары сиңа
җыр алып килдем.

— Мондый җырларым
юк иде, — дидең.

Асыл кошлар мин
китереп бирдем.
— Беренче күрәм
боларны, — дидең.

Мин йөрәгемне
китердем сиңа.
Йөрәккә карап
әйттең син миңа:

— Мин сине күптән
инде аңладым.
Синең үзеңә
берни калмады.

Чәчәгең, җырың,
кошларың миндә.
Ә йөрәгеңә
син берүк тимә.

Мине яратсаң,
ул сиңа кирәк.
Миндә дә тибә
нәкъ шундый йөрәк.

1985

***

Хискә дә бай тормыш, төскә дә бай,
барысы да бездән.
Һаман шулай дөнья, һаман шулай,
акыл, сыйфат — бизмән.
Хәтер тирән: чорлар, җырлар телдә —
шулай онытылмасын.
Мин уяндым әле бүген төштә
күреп Су анасын.
Уй-фикерләр, бәлки, кичәгедән
бүген зирәгрәктер.
Урманнарда шүрәлеләр генә
шактый сирәгрәктер.
Кануны шул: бөек халыкта да
затлы сирәк була.
Шуңа күрә мең еллардан соң да
бик тә кирәк була.

1983

***

Кал кошларың белән, дисеңме син?
Янымда шул минем кошларым.
Синнән башка алар белән инде
җәй җәйләдем,
кышлар кышладым.
Сайрый алар кунып күңелемә,
әле һаман өмет бар икән.
Аерылмый торган пар кошларга

ялгыз күңел генә тар икән.
Кал кошларың белән, дисеңме син?
Мин бит кала алам.
Йа Аллам!

1970

## Борынгы җыр

Бик борынгы бер җыр тыңладым мин.
Хикмәтле иде моңы, сүзе дә.
Ким дигәндә, мең ел җыелып килгән
моңнар барын тойдым үземдә.
Алып китте ерак үткәннәргә.
Чит тә кебек дөнья, таныш та.
Күмде мине бу җыр көтмәгәндә
әллә нинди татлы сагышка.
Җыр да бетте,
мин дә кире кайттым
бүгенемә, шушы көнемә.
Беркайчан да онытылмаслык бу җыр
бер төш булып калды өнемдә.

1984

## ***

Көзләр җитәләр икән ул,
кошлар китәләр икән.
Кошлар китеп, көтмәгәндә
ялгыз итәләр икән.
Кайчак онытып куябыз,
нигә искәртми хәтер?
Кошларның үз гомере бар, —
беләм инде мин хәзер.
Кирәк икән кош гомерен
белеп, тоеп калырга.
...Кош канаты яткан иңгә
сары яфрак сарыла.

1983

## Декабристлар хатыннары

**1**

Ак бураннар ярып,
кара төндә
Себер трактларын үтмәдем мин.
Әллә кайта башлар,
әллә юк дип,
Себерләргә себер китмәдем мин.
Хыялый чак ләкин,
яшь вакытта
патшасына барып җитә идем.
Декабристлар булып югалам да
Себерләргә кадәр китә идем.
Рудникларда үлдем елый-елый,
көлә-көлә үлдем —
саф күңелем.

Буш хыяллар икәнен дә белдем,
декабристлар туар чак түгелен.
Кемнәр тумас?
Кайтыш затлармыни?
Заманалар дәшсә,
Илең дәшсә...
Декабристлар булып өлгерәләр
гражданнар инде андый яшьтә.
Изге эшләр дәшеп ала икән,
шикләнмибез,
әле дә йөрәк җитәр.
Ул язмышка тарсак,
безнең башлар
Себерләрдә калмас,
ерак китәр...
Каһарманлык җитәрлек ул householdбездә,
үз йөрәгем белән тоя алам.
Кирәк булса әгәр,
йөрәгемне
өр-яңадан,
кабат коя алам!
Шуңа күрә бу батырлык мине
сокландыра,
ләкин көнләштерми.
Яшәеш ул,
батырларны җыеп,
чорны чорга куеп көрәштерми.

**2**

Көнләштерә мине башка нәрсә,
тезләндерә мине тезләремә;
мин бүген дә яшь коярга әзер
Себерләрдә калган эзләренә.
Себерләрдә калган гомерләре,
мәхәббәтне батыр итәр өчен.
Себерләрдә тора каберләре,
батырларны батыр итәр өчен.
Беләм, әмма бер сорыйсы килә:
батырлыкка тиңдәш сөю бармы?
Өч сүз булып ишетелә җавап:
гүзәл декабристлар хатыннары.
Ал чәчәктәй сөю сибелеп ята
Россиянең бозлы яртысында.
Тоныклана сыман батырлыклар
мондый мәхәббәтнең каршысында.
Һәркайсына гашыйк мин аларның.
Аерым-аерым гашыйк,
җаным белән.
Бәхетемә тисә шул мәхәббәт,
нишләр идем икән аның белән?!

1985

## Сагыну*

*(Җыр)*

Гөлләр арасында йөргән юк,
гөл чәчәген күптән күргән юк.
Чәчәк исләреннән исереп,

гөлләр өзеп таҗлар үргән юк.
Омтыла җан гөлләр янына.
Чәчәк төсен күңел сагына.
Гөлләр тулы болын авазы
сагыш булып җанга сарыла.
Юксындырмас гөлләр кемнәрне?
Гөлле итәсе килә көннәрне.
Эзли күңел һаман гөл илен,
бер табасы иде гөлләрне!

1985

## Болыт

Күкләр күкрәп,
яшеннәре яшьнәп,
саллы гына купшы болыт килде.
Карады да:
«Мондый кара җиргә
әрәм булып нишләп явыйм!» — диде.
Яшел болын,
зәңгәр күкләр эзләп,
бәхетләрен күрми үтте болыт.
Кире кайтып явар иде, белсә
шытачагын монда икмәк булып.

1985

***

Ни гомер күрмичә йөрелгән,
дөньяда син дә бит бар икән.
Ялгызлык килешми кешегә,
кешене ярату пар иткән.
Үкенеп уйларга калмасын
заяга узылган вакытлар.
Соң түгел,
беркайчан соң түгел,
яратыр өчен гел вакыт бар.
Дөньялар яктырак күренә,
син булгач йөрәктә, уйларда.
Кыен ул ярата алмасаң
яшисе гомерләр булганда.
Йөзә дә, яши дә яуганчы,
әнә бит күктәге болыт та.
Безнең дә гомерләр бар әле,
бары тик син мине онытма!
Бары тик син мине онытма!

1985

***

Аның белән бөтен буын телен ача,
җырларыбыз сыналалар аның аша.
Аның белән юлларыбыз туры, уңай.
Халык, дисәк, күз алдына килә Тукай.
Кардәш-ыру гомер итә бергә-бергә,

теле берлә, иле берлә, Тукай берлә.
Дулкынлана моңы Идел ярларында,
яши Тукай кешеләрнең җаннарында.

1983

## **Көчсезлегең белән...**

Көчле мохтаҗ түгел көчсезләргә.

*Рина Ланье,*
*Канада шагыйрәсе*

Көчлеме мин,
көчле түгелме мин —
бу турыда түгел уйларым.
Яратырга хакым булган чакта
булмас минем синнән туйганым.
Баштанаяк гашыйк сиңа, димим,
гашыйклардан инде көнләшмим.
Баш бирмичә чапкан хисләремне
тыярга дип тә мин көрәшмим.
Су буенда суга карап үскән,
моңга чумган ялгыз тирәк син.
Сагышларың белән,
моңың белән,
ялгызлыгың белән кирәк син.
Иреннәрне кыймылдатып кына
әйтеләсе гади сүзләргә
мохтаҗ бит син,
күңеленә генә
карап тора торган күзләргә.
Тиңнәремне эзлим дигән кеше
гел югалта бара тиңнәрен.
Миңа кирәк зәгыйфь канатларың,
сиңа кирәк минем иңнәрем.
Уйларыңа кирәк минем уйлар,
җаннарыңа кирәк җаннарым.
Мин бит инде сине күргәнче үк
шундый итеп сине аңладым.
Күңелеңне гөрләвекләр итеп
эретергә килгән бер яз мин.
Көчледер мин.
Шуны раслар өчен
синең көчсезлеккә мохтаҗ мин.

1985

## Ләйлә*

Исемә төшә
ничәмә-ничә
еракта калган
ялгыз бер кичә.

Уйламый-тоймый,
сизми, белмичә
бәхетле булган
шул ялгыз кичә.

Ләйләләр азмы?
Ничәмә-ничә.
Хәтердән китми
бары бер кичә...

Шул ялгыз кичә...

1970

## Ышану

Бер гадәт бар.
Гадәт кенә түгел,
ул кагыйдә инде тормышта.
...Әйтерсең лә
шушы кагыйдәләр
ияреп килә безгә тумыштан.
Нигезе бар үзенең,
формуласы:
«шулай тиеш», «шулай кирәк» ди.
Исбатлап та бирә:
бу дөньяда
ышанырлык кеше сирәк, ди.
Акылга да сыеп бетми кебек:
Кеше дигән затка ышанма!
Актарыла минем хисләр кайчак,
йөрәгеңне тот та тышаула!
Бәгыреңә пычак булып керә,
алдануы авыр авырын...
Кыенлыгын беләм
ышануга
алданулар аша баруның.
Алдасыннар мине, —
бер алдасын,
ике,
өч кат мине алдасын.
Түзә алам,
бары минем аңа
ышануымны ул аңласын.
Аллага да,
кешегә дә биргән
ышанырга дигән антым юк.
Ышанмасаң, бәлки, ансаттадыр,
ышанмаска ләкин хакым юк.
Ышанамы миңа кеше үзе?
Ышанмаса бик тә кызганыч.
Җанымдагы бөтен законнарның
кодексы — минем ышаныч!

1985

## Уен

Каты уйный, оста уйный, шайтан,
уйный минем олан;
үземә үзем карап торган кебек
шуны карап торам.

Исән булсын кулың-аякларың,
тик уенны бүлмә.
Җиңелсәң дә, елый-елый җиңел,
түзеп тора белмә.

Аяк чалса берәү, сикереп тор,
уйна томырылып.
Ят кулларда бүрек колакчының
калсын умырылып.

Бар дөньясын фида кылып уйный
без тудырган буын.
...Башлый кеше шушы уеннардан
тормыш, көрәш юлын.

1984

***

Әле кошлар китә,
әле кошлар куна.
Кеше күңеленең
төрле чагы була.

Бар көенгән чагы,
көенмәгән чагы.
Бар сөенгән чагы,
сөенмәгән чагы.

Сөйгән вакытларда
сөеләсе килә.
Сөяләр икән дип
сөенәсе килә.

Кошлар тора сайрап,
күңел тора эреп.
Гомер буе шулай,
шулай булыр кебек.

1984

## Гөлләрең шау чәчәктә

Гөлләрең белән матур син,
гөлләрең белән яшәп.
Мәгънәләр киңәеп китә,
гөлләрең торса яшьнәп.

Үсәләр. Нигә үсмәсен,
суларын сибә торгач.
Үстереп калырга кирәк —
соң булыр гөлләр коргач.

Карасаң, күзләр камаша,
гөлләрең чәчәк аткан.
Суларга һавасы иркен,
дөньяның яме арткан.

Анысы да безнеке бит,—

карарбыз киләчәктә.
Бүгенгесе кыйммәт әле,—
гөлләрең шау чәчәктә.

1985

***

«Ник сабырсыз,— дисең,—
бу йөрәгең,
кая җаның болай ашкына?
Хәерлегә булмас мондый хәлләр,
ашкынулар җитәр башыңа».

Тыеп тору мине кирәк түгел.
Булдыра алсаң әгәр, ашкындыр.
Йөрәгем дә минем берәү генә
һәм кадерле газиз башым бер.

Үкенечле булыр минем гомер,
ашкынудан тынса бу йөрәк.
Ашкынулар кирәк хәзер миңа,
хәзер кирәк, бүген бигрәк.

Ни чакыра мине ашкындырып?
Үзем беләм, табам мин аны!
Сабырлыгым җитми җиңәр өчен
ашкындырып торган дөньямны.

1985

***

Бәйрәм итә берәү...
Шатлыклары
ургып тора, тәмам ташыган.
Уйлап куйдым:
менә бу кешегә
бәхет капкалары ачылган.

Ялгышасың, диде миңа кемдер,
көн дә бәйрәм, көн дә туй аңа.
Үз бәйрәме аның булганы юк,
кеше бәйрәменә куана.

Дөрес эшли.
Кеше сөенгәндә,
нигә дип ул бәйрәм итмәсен?
Үз бәйрәме булмаса да ярый,
кешенеке генә бетмәсен!

1985

***

Сөйләшәләр кайчак: олгаябыз,
үтә еллар берсен-берсе куып;

кайчан гына әле йөри идек
гүзәлләрне күрсәк гашыйк булып.

Гомер генә үтә, гомер генә,
матур хисләр яши, үтми бер дә...
Гашыйк булу безнең кулдан килә,
ничек итеп гашыйк иттерергә?!

1977

## Саҗидә Сөләймановага юксыну

Шагыйрь үлми дигән хакыйкать бар.
Үлми шагыйрь,
үлми икән шигырь җирдә.
Тик шулай да
мәңге сагыныр өчен
бер шагыйрьнең бер үлеме җитә.

Шигырең исән.
Мәңге исән булыр.
Язып киттең бугай йөрәкләргә.
Синең шигыреңне кулга алам,
тормыш ваклыклары йөдәткәндә.
Шулай булыр:
йөзләр,
меңнәр укыр.
Исемең яшәр һаман,
яшәр даның.
Халык йөрәгендә,
шигърияттә
балкып торыр һаман синең җаның.
Шагыйрә дип телгә алган чакта
шигырьләрең сөйли —
исән-саулар.
Күз аллары бераз томалана,
«Нинди иде ул?» дип сорасалар.
Юатырлык җырың — моңың калды,
кешеләргә теләп исән-саулык.
Тик барыбер сыкрый минем йөрәк,
«Саҗидәнең кабере...» дисә халык.
Шагыйрь үлми.
Дөрес, кеше үлә.
Исән дә син бүген,
түгел дә син.
Киләчәктә әле синең гомер
һәм җитмисең безгә бүгенгә син.
Үлемсез син
вакыт,
илең өчен.
Безнең белән калдың бездән китеп.
Тик барыбер үлемсезләрне дә
бик күрәсе килә исән итеп!

1983

## Роботлар турында гына

Ә роботлар шундый камилләште:
кеше кебек «зирәк», «акыллы».
Бар кушканны эшләп кенә тора,
куып җитәр безне, ахры.

Хыяллана инде гыйлем халык,
әллә чынлап, әллә дан кирәк.
Мөмкин эш, ди, имеш, роботларга
йөрәк кирәк икән, җан кирәк.

Кирәген ул, бәлки, кирәктер дә,
төшенергә шуңа аң җитми.
Роботларга, бәлки, иртәрәктер,
кешеләргә әле җан җитми.

1983

## Парадокс

Ансат кына ясап ташланмаган,
ямьсезе дә матур аның хәтта.
Нәфис итеп,
төгәл яратылган —
барысы да матур табигатьтә.
«Өйрән, — дигән гүя, — миңа карап,
иҗатыңа үрнәк эзлә миннән;
ясаганың мин ясаган кебек
нәфис,
төгәл,
матур булсын», — дигән.
Һәм өйрәнгән.
Мең ел...
Миллион ел...
Зур түземлек,
олы кодрәт салып.
Карап торган моны табигать тә:
«Үзсүзле икән!» — диеп,
хәйран калып.
Ялгышмаган кеше.
Табигатьне
вакытында,
дөрес аңлаган ул.
Бәхете бар икән:
гүзәллеккә
битараф зат булып калмаган ул.
Аның кулы тигән,
ул ясаган
һәрбер нәрсә мине сокландыра.
Нәфислеге,
төгәллеге белән,
матурлыгы белән балкып тора.
Балкып ята минем алда кәгазь,
кулда нәфис каләм балкып тора.
«Матурлыкны тоеп яз», — дигән күк,
кәгазь-каләм җанны тартып тора.
Тартып тора тагын бер матурлык,
шунда бүген бөтен күз карашы.
Шуңа карап,
тынын кысып тора
Җир шарыбыз — безнең күз карасы.
Ракеталар нәфис каләм кебек

зифа,
матур итеп коелганнар.
Төбәлгәннәр Җирнең йөрәгенә,
үлем белән генә корылганнар.
Кузгалырга һәрчак әзер булып,
оя-оя көтеп торалар күк...
Канатларын җәеп,
сабыр гына,
без сагынып көткән торналар күк.
Ясап куйган кеше матур итеп,
боларга да җылы кулы тигән.
Табигатьнең үзе ясаган күк
нәфис,
төгәл,
матур булсын дигән.
Үлем итеп тезеп куйган шуны.
Бүленгән Җир төгәл кисәкләргә.
Надан түгел Җирнең балалары,
бөтенесе төгәл исәпләнгән.
Без өйрәнеп җиттек шулкадәрле!
Табигатьне күптән узып киттек.
Вәхшилекне тудыра хәзер кеше
нәфис итеп,
төгәл,
матур итеп.
Ансат кына ясап ташланмаган,
үлем төясә дә, матур хәтта.
Барысы да матур безнең Җирдә,
барысы да матур табигатьтә!

1985

## ***

*Д.С. истәлегенә*

Дөреслектән узып яшәмәде.
Исеменә төшкән табы да юк.
Фанилыкка,
кешеләрдән урлап,
алып кайткан ширпы кабы да юк.

Тик гаебе шунда:
Сизми калды,
искәрмәде соңгы адымнарда.
...Рәнҗегәндер
аяк астындагы
йомычкага килеп абынганда.

Егылып үлде.
Үлгәч хурладылар:
Йомычканы ничек күрмәгән ул?!
Гаепләде дөнья:
Ник егылган,
аягүрә нигә үлмәгән ул?!

1985

## Бүген төнлә...

Бүген төнлә минем Җирем үлде.
Бик авырып үлде Җир шары.
Бөтен күктә гаҗәп тынлык иде,
тетрәтмәде бу хәл җиһанны.
Үз үлеме белән үлмәде Җир.
Иртә иде әле үлемгә.
Бер кабынып,
балкып алды да ул,
сүнеп калды галәм күгендә.
Еларга да яшь килмәде.
Тоймадым мин хәсрәт-сагыш та.
Әзер иде инде
Җир дә,
Күк тә,
Кешелек тә мондый язмышка.
Гомер иттек.
Җәннәт-йортыбызны,
күпме яшәп,
күпме сакладык!
Һәм,
ниһаять,
бөтен галәм өчен
бер буш куык кебек шартладык.
Башларымны күккә бәрә-бәрә:
«Нигә үлдең инде?!» — димәдем.
Эзләп йөрдем кабер казырга дип,
табалмадым ләкин ирләрен.
Мин күтәреп йөрдем Җир гәүдәсен,
шундый җиңел,
шундый буш калган...
Әйтерсең лә
бөтен хәсрәтеннән,
кайгысыннан Җирем бушанган.
Җир шарына зират эзләп йөрдем,
бар галәмне айкап актардым.
Чиксез дисез аны...—
ә мин анда
бер каберлек урын тапмадым.
Каберләрдә шаулап торсын дисәң,
каен да юк анда,
җил дә юк.
Чиксезлеге аның нигә миңа,
кабер казыр өчен җир дә юк!
Кара төндә,
чиксез караңгыда
киттем бугай артык еракка.
Йолдызлардан йолдызларга йөрдем,
мәхрүм булып бер уч туфракка.
Яктырмады галәм,
күпме генә
көтсәм дә мин, таңнар атмады.
Томаннарга Җирне тапшырдым да,
әллә кайттым,
әллә кайтмадым.
Мин үзем дә калдым бугай шунда,
томаннарга кереп,
кабенсез...

Мин соң нәрсә!
Чиксез галәмендә
Җир булып Җир хәтта кадерсез!
Бүген төнлә минем Җирем үлде.
Сез, кешеләр, кайда идегез?
Җирләмичә мәет калдырмыйлар,
күмелмичә калды Җиребез.

1985

## Каен җаны

*(Әкият-поэма)*

**1**

Кемнән сорыйсың ерак үткәнне?
Йөз ел үткәнме, мең ел үткәнме?
Кемнәр һәм кайчан утырткан аны?
Халыктан калган бары тик даны:
бу каеннарның, имеш, җаны бар;
каен төбендә халык каны бар.
Халыкның сүзен әгәр онытсаң,
бу каеннарның җанын корытсаң,
дучар булырсың гомерлек чиргә,
кайгы килер, ди, үзеңә, Илгә.
Авыр еллар да дөньяда булган.
Исән-сау калган бу каен урман.
Беркем дә аңа кагылмаган да,
утын итеп тә ягылмаган да.
Аңардан халык йорт та салмаган.
Себеркегә дә өзеп алмаган.

Кечкенә түгел, бик зур да түгел,
шундый бер урман бар әле бүген.
Тимәгән аңа бер бәла-каза.
Каеннары төз, шома һәм таза.
Карап торды да кызыкты кеше.
Кызыкты кеше, эшлекле кеше.
Карады бер кат, карады ике...
Үзенә үзе ул болай диде:
«Халык сүземе? Борынгы ялган.
Безнең заманга сүзләр күп калган.
Каен кискәннән урман корыймы?
Урманга карап йортсыз торыйммы?»
Төкерде учка, эшкә тотынды.
Төкерде сүзгә, курку онытылды.
Каеннар үскән җиргә төкерде.
...Мәһабәт зур өй җиткереп керде.
Сөенде кеше, куанды кеше:
башкарып чыкты бик мөһим эшен.
Яшәрмен, диде, шушы өемдә
тыныч, бәхетле килер көнемдә.

Бер көн дә үтте, ун көн дә үтте.
Ләкин, ни хикмәт, тынычлык бетте.
Талчыгып кайтып ятса да хуҗа,
ничә төн инде йокысыз уза.
Башын мендәргә куюы була,
бөтен өй эче моң белән тула.
Төнгә керүгә һаман бер көйгә

үкси дә үкси нәрсәдер өйдә.
Чуалып бетте хуҗаның уе.
Өй елап тора төннең төн буе.

Озак чыдады. Өй елый һаман.
Бетте түземе хуҗаның тәмам.
Мичтәндер, диде. Кайтып бер кичне
иште дә атты өр-яңа мичне.
Бик яхшы оста чакыртып алды.
Бик яхшы итеп яңа мич салды.
Йоклады ятып, төн тыныч иде.
Шөкер дөньяга, котылдым, диде.
Иске останы бик нык хурлады.
Яңа останы бик нык зурлады.
Гаепле булган, диде, мич кенә.
Күп бүләк бирде яңа миччегә.

Тагын көн үтте, тагын төн җитте.
Тагын хуҗаның йокысы китте.
Башын мендәргә куюы булды —
бөтен өй эче моң белән тулды.
Төнгә керүгә һаман бер көйгә
үкси дә үкси нәрсәдер өйдә.
Чуалды кабат хуҗаның уе.
Өй елап тора төннең төн буе.

Озак чыдады. Өй елый һаман.
Бетте түземе хуҗаның тәмам.
Урыннан, диде, урыны шундый,
башка урынга күчмичә булмый.
Карамаган җир бер дә калмады.
Хуҗа иң әйбәт урын сайлады.
Җилләр дә йөрми, тыныч үзәндә.
Төшми бирегә чит-ят күзләр дә.
Сүттеләр өйне, җыйдылар кабат,
җекләрен җеккә китереп карап.
Яңа урында менә өй әзер.
Тирә-ягында шундый тын хәзер...
Йоклады хуҗа. Төн тыныч иде.
«Котылдым микән бу чирдән?» — диде.
Икенче төн дә ул-бу булмады,
йокыдан хуҗа бик шат уянды.
«Тинтәк булганмын, — диде, — мин үзем.
Кайларда булган соң минем күзем?
Салганмын өйне җилләр чатына,
шундый шәп урын булган чагында.
Шушы урынны алдан сайласам,
тыныч яшисе булган лабаса».
Тагын көн үтте, тагын төн җитте.
Тагын хуҗаның йокысы китте.
Башын мендәргә куюы булды —
бөтен өй эче моң белән тулды.
Чуалды кабат хуҗаның уе.
Өй елап тора төннең төн буе.

Озак чыдады. Өй елый һаман.
Бетте түземе хуҗаның тәмам.
Ул төннәр буе йоммады күзен.
Кая куярга белмәде үзен.
Тилмерде хуҗа: нәрсәдә сәбәп?

Йокласаң иде бер генә сәгать!

Бик аптырагач, калгач чарасыз,
койма койды ул, биек, чамасыз.
Тәрәзәләрен тыштан каплады.
Мичне-морҗаны япмый ятмады.
Көчәйде генә елау, тынмады.
Хуҗа төн буе шуны тыңлады.
«Нишләргә, — диде, — нишләргә хәзер?!
Мин үз өемнән качарга әзер!»
Уйлады ятып төн буе үзе.
Исенә төште халыкның сүзе.
Исенә төште каеннар даны.
Әллә өйнең дә бар микән җаны?
Шушы уй аның башыннан үтеп,
алгандай булды миләрен өтеп.
«Нишләргә, — диде, — нишләргә хәзер?!
Мин үз өемнән качарга әзер!
Инде түземлек чигенә җиткән.
Кемнәргә барып сөйләргә икән?!»

Бар иде илдә, бер карт бар иде.
Йөз яшьтән артык яшәгән инде.
Белмәгәне юк, ди иде халык.
Үзе дә олпат, исеме — Алып.
Барды да хуҗа Алып каршына,
сүз катты аңа, салып башыннан:
— Мин сиңа килдем чарам калмагач,
инде бернәрсә эшли алмагач.
Яши идем мин хәвеф-кайгысыз,
халык сүзенә булдым ваемсыз.
Үземә үзем алдым мин каза,
өемдә хәзер бары тик газап.
Нишләргә миңа, нишләргә хәзер?!
Мин үз өемнән качарга әзер!
Тик әйт син миңа, сере нидә соң?
Минем бу өем елый нигә соң?
Нигә андый сүз калдырган халык?
Тик әйт син миңа, әйт, олпат Алып!
— Хәлеңне беләм,— диде ил карты,—
ялгышкансың син, олан, бик каты.
Алып кайт мине бер килгән килеш.
Мин синең өйдә булырга тиеш.
Бүген мин синдә куна калырмын.
Бәлки, шуннан соң әйтә алырмын.

Черем дә итми төн чыкты хуҗа.
Йокысыз төннәр, һай, озак уза.
Әллә йоклады, әллә юк Алып,
ләкин торды ул соңгарак калып.
Әйтте хуҗага:
— Бүтән сөйләмәм,
оныкларыңа
җитсен сөйләгән.
Бу каеннарның, шушы урманның
тарихын белсен синең улларың.
Миңа да бабам сөйләде аны.
Бар ул урманның,
бар аның җаны.

**2**

Белми беркем дә: кайчан, күптәнме,
йөз ел үткәнме, мең ел үткәнме?
Яулы ел булган җир-суда, илдә.
Талап, яндырып дошманнар килгән.
Кешеләр илдән кача торганнар,
Урман эчендә тормыш корганнар.
Яулар килгән дә җирен таптаган.
Җирен таптаган, халкын тапмаган.
Яндырган тоташ ачудан, үчтән.
Кешеләр һаман урманга күчкән.
Алдаган халык, яуны алдаган.
Дошманга илдә азык калмаган.
Корыган сулар, корыган үлән.
Яулар әкренләп сугышмый үлгән.
Дошманның тик бер чарасы калган:
табарга илне теләсә кайдан!
Ташланган дошман урманга, тауга...
Җайдаксыз атлар кайтканнар яудан.
Эзләмәгән җир инде калмаган.
Бер эзгә дошман төшә алмаган.
Таралган яулар, кимегән дошман.
Яуның башлыгы болай дип кушкан:
— Атланыгыз да барлык атларга,
таралыгыз да төрле якларга,
бер исән кеше миңа табыгыз,
кадерле булса әгәр җаныгыз!

Тапканнар эзләп. Ерак бер тауда
малай белән кыз очраган яуга.
Яуның башлыгы сөенеп туймаган.
Котылдым диеп башлык уйлаган.
Әйткән ул шунда ике әсиргә:
— Без кунак булып килдек бу җиргә.
Безне ни өчен каршы алмыйлар?
Кунакны болай каршыламыйлар.
Кайда бу халык, кайда илегез?
Кая качтыгыз, сөйләп бирегез!
Ничек барасы кайсы авылга —
юл күрсәтегез минем явыма!
Малай белән кыз башны игәннәр.
Аннан башлыкка болай дигәннәр:
— Сез кунак түгел, без качкын түгел.
Безнең йортларны яктыгыз бүген.
Кире кайтырлык хәлең юк синең.
Каберең якын, еракта илең.
Безнең Ил исән, халкы да яши.
Синең үлемне көтә ул дәшми.
Син аңа юлны мәңге тапмассың.
Урманга керсәң, кире кайтмассың.
Сорама бездән, сорама юкка.
Ассаң да дарга, салсаң да утка,
әйтә алмыйбыз. Серне сатмыйлар.
Дошман ияртеп өйгә кайтмыйлар.

Ярсыган башлык һәм әмер биргән:
— Акыл кергәнче кыйнагыз! — дигән, —
китә алмаслар, баулары әйбәт.
Ялгыз каенга куйганнар бәйләп.
Ярсыган дошман ачтан, ачудан.

Кан сеңеп аккан каеш камчыдан.
Кыйнаган дошман, чама белмәгән,
бала димәгән, үләр димәгән.
Каен кәүсәсе кызарып беткән.
Әсирләр һушсыз. Инде кич җиткән.
— Әйтерләр, — дигән башлык, — иртәгә.
Әйтмиләр икән — икесенең дә
башын кисәргә!
Төн үтеп, илдә таңнар атканда,
дошманнар әле йоклап ятканда,
алып коралын, булган кадәрен —
чалгы, пычагын, балта, сәнәген —
хәл иткән халык яуга барырга,
кызны, малайны йолып алырга.
Килгән дә халык, яуны ураган.
Үлем хакында уйлап тормаган.
Кайнаган җаны, кайнаган ачу.
Җитәрлек булган гарьлек һәм ярсу.
Үчкә өндәгән түгелгән каны.
Үчкә өндәгән кимсенгән җаны.
Бер йодрык булып яуга ташланган.
Хәлиткеч көрәш илдә башланган.
Халык үзенең максатын белгән.
Буган дошманын коры кул белән.
Күргән газаптан бәгыре каткан.
Тәвәккәллеге, батырлык арткан.
Үлем турында уйламаган ул.
Инде дошманын аямаган ул.
Көн буе барган туралыш, кырыш.
Мәрхәмәтсез һәм әсирсез сугыш.
Каушаган дошман, башлык каушаган.
Уйлаган уе эшкә ашмаган.
Каушаткан аны халыкның үче.
Аңлаган дошман халыкның көчен.
Һәм аңлаган ул: мәрхәмәт көтмә!
Дошманның инде куәте беткән.
Бер дошманы да исән калмаган,
берсен дә халык әсир алмаган.
Тынган дау кыры, тынган даласы.
Эзләгән халык ике баласын.
Юлыккан килеп ялгыз каенга,
ялгыз каенга — тирән кайгыга.
Малай да, кыз да исән калмаган,
каен аларны саклый алмаган.
Шуңа күрәме үскән урынында
ямь-яшел каен үзе корыган.
Елаган халык, баткан кайгыга.
Елаган карап корган каенга.
Калыккан инде каен янында
ике яшь кабер ике ягында.
Икенче көнне күреп алганнар,
бу гаҗәп хәлгә хәйран калганнар:
яңа терелгән авыл янында,
корган каенның ике ягында
ике яшь каен үсеп утыра!
Гүя кыз белән яшь егет тора.
Бу могҗизага бик хәйран калып,
ике каенга караган халык.
Безнең балалар җаны бу, дигән.
Изге урын дип, чал башын игән.

Шуннан бу җирнең даны таралган.
Буыннар аңа изге караган.
Шуннан бу җирдә һәрбер ел саен
чыккан, ди, үсеп икешәр каен.
Аларга тисә, киссә бер кеше,
саналган, ди, ул зур гөнаһ эше.
Каеннар һаман үсә торганнар.
Каеннар инде урман булганнар.

Беркем дә белми: кайчан, күптәнме?
Йөз ел үткәнме, мең ел үткәнме?
Урман яшәгән, исән-сау калган.
Тарихы гына югала барган.
Изгелеген дә изге урынның,
күргәннәрен дә үткән буынның
оныткан кеше, каеннарын да,
ул каеннарның кайгыларын да.
Кемнәр үстергән карап, кадерләп —
каеннар гына калган хәтерләп.

**3**

Тынды Алып карт. Бетте хикәят.
Башын күтәреп әйтте, ниһаять:
— Бик тыныч кына йоклады димә.
Өйнең елавын тыңладым мин дә.
Бер генә сиңа, олан, киңәшем...
Каен җанына инде тигәнсең.
Олы хатаңны төзәтәм дисәң,
кайсы урында син каен кискән,—
яшь үсентеләр калгандыр анда.
Төпләп алып кайт, урманга бар да.
Утырт аларны өең янына.
Шул шифа булыр каен җанына.

Куанды кеше, ә шиге калды.
Көрәген алып урманга барды.
Һәр каен төбен эзләп тапты ул.
Һәр төп яныннан алып кайтты ул
берәр үсенте — берәр яшь каен —
кисеп алынган һәр каен саен.
Чын күңеленнән утыртты җайлап.
Чын күңеленнән урыннар сайлап.
Сөеп, кадерләп суларын сипте.
Эше дә бетте, тагын төн җитте.
Арып, талчыгып йокларга ятты.
Шик күңеленә яңадан кайтты.
Башын мендәргә куюы булды,
бөтен өй эче моң белән тулды.
Чуалып бетте хуҗаның уе.
Өй елап тора төннең төн буе.

Иртүк таң белән Алыпка әйтте:
— Алдадың мине! Булмады! Бетте!
Юк! Кирәк түгел йорты, каены...
Күргән юк иде мондый кайгыны!
— Сабыр ит, — диде Алып карт аңа, —
туфрагы яңа, тамыры яңа.
Каеннар әле терелмәгән бит,
тамыр тамырга үрелмәгән бит.

Каеннар алар кешеләр сыман.
Тагын өч көнгә сабыр ит, олан.

Алыпның әйткән өч көне үтте.
Тагын борчылып көткән төн җитте.
Йокламады ул, күз дә йоммады.
Нәрсә булыр дип һаман уйлады.
Еламады өй, менә таң ата.
Ә кеше һаман ята да ята.
Еламады өй, ә кеше ятты.
Өенә бүген тынычлык кайтты.
Куанып шулай уйлап ятканда,
беренче тыныч таңы атканда,
тәрәзәсенә чирткәндәй булды
кемнеңдер бик сак һәм сабыр кулы.
Тәрәзәсенә килде сак кына.
Карады тышка каушап чак кына.
Тәрәзәләрен ачып җибәрде.
Сарылды аңа каен җилләре.
Шаккатып калды кеше бер мәлгә:
урман эчендә уянды мәллә?
Бер төн эчендә үсеп киткәннәр.
Өй түбәсенә кадәр җиткәннәр.
Өен каеннар уратып алган.
Өе гел урман эчендә калган.

*

Беркем дә белми: кайчан, күптәнме?
Йөз ел үткәнме, мең ел үткәнме?
Яшәгән кеше, яшәп туймаган.
Өендә инде кайгы булмаган.
Тыңлаган саен каеннар шавын
ул аңлый барган каеннар җанын.

## Туфан белән сөйләшү

*(Поэма)*

Сөйләшәсе килә.
Мөлдерәмә
тулып тора күңел нигәдер.
Минем генә түгел,
башканың да
бүген ачыласы киләдер.
Заманага таянуым түгел...
Дөрес,
сүзгә кирәк ирек тә.
...Әйтер сүзләр,
кылыр гамәл кала
чикләнмәгән ирек биреп тә.
Еллары да китә...
Кешеләр дә...
Киңәшергә кала кем белән?
Бер җаныңны меңгә ярып кына
аңлатуы кыен —
мин беләм.

Югалтулар...
Саубуллашу...
Сагыш...
Адым саен яңа аяныч...
...Газаплары артык йөдәткәндә
эзләгәндер ул да таяныч.
Андый чакта
еллар, чорлар бетә.
Киләчәге,
бүгене,
үткәннәр —
барысы да сыя бер шәхескә,
онытылып тора бүтәннәр.
Сызланганда кемгә сыенасың?
Үз Такташын сагынып җан атты.
Илен,
Халкын,
Телен —
Шигъриятне
барыннан да күбрәк яратты.
Еллар гына һаман ага тора,
безнең дә шул халык,
шул илең...
...Сөйләшәсе килә:
Туфаннан да
якын кешем бүген юк минем.

Әле ярый аңа гомер биргән.
Әле ярый кайтты...
яшәде...
Мәгънәләре тулы булмас иде,
ул булмаса, безнең яшәүнең.
Исән килеш ике гомер үтте:
Такташ чорын,
Туфан чорларын.
...Баш очыннан чәчрәп үлем үтте...
Ул яңадан торып җырлады.
Шул торудан Туфан яшәп китте,
шул торудан без дә Туфанлы.
Югалтырга мөмкин түгел икән
мәңгелеккә диеп туганны!

Икенче кат яшим Туфан белән.
(Бер яшәдем исән чагында.)
Туфаннарга сыеп бетмәгән моң
кайный бүген минем җанымда.

Заманага таянуым түгел,
сүз әйтергә хәзер ярый дип.
Дөрес сүзне нинди заманда да
туры итеп әйтү ярый бит.
Үзебезнең сүзне әйтер вакыт.
Кыйммәте зур һәрчак хак сүзнең!
Дөреслекне ярып салыр өчен
Туфаннардай булыр чак безнең.

**1**

Гомеремнең соңгы көненәчә
Бу юксыну, ахры, сүрелмәс...

*Х.Туфан*

Урманнарга качып укый идек,
яфрак шавы итеп ятладык.
...Без тормышның төбеннән үк чыктык,
тик төбендә аның ятмадык.
Мокамай да идек,
разбойник та...
Буйларыбыз җитте Айга да.
Дөньяларның бөтен ишекләре
ачык иде безгә кайда да.
Беркемдә юк иде ул хыяллар...
(Беркемдә юк әле бүген дә.)
Беркемдә юк иде ул мәхәббәт, —
ничек сыйган безнең күңелгә?!
Рәхәтләнеп чәйнәр идем дисәң,
авыз тулы ипи юк иде.
Эчләребез безнең буш булса да,
күңелебез безнең тук иде.
Туңа иде безнең аяк-куллар,
туңа иде тәндә каныбыз.
Кайнар иде ләкин хис-хыяллар,
җылы иде безнең җаныбыз.
Ничек?
Каян безгә туры килгән?!
Язмыш дими, моңа ни дисең?
Анам,
Илем,
Җирем белән рәттән
бәгыремә сеңгән бу исем.
Безнең өчен генә туган икән,
без туганбыз икән Такташта.
Такташ рухы һаман китми миннән
үзебезне үзебез тапкач та.

Син юк идең, Туфан, ул елларда.
Көфер сүзгә, зинһар, санама:
Ялгышкан да бик нык...
бөек бер эш
башкарган бит ул чак замана.
Яшереп куйган сине Илдән-Җирдән,
көтеп торган синең беткәнне.
Уена да килмәгәндер
сине
башка замананың көткәне.
Җиткән иде Такташ ул елларда.
Суыгында җаныбыз туңмады.
Безнең өчен язмыш
киләчәккә
бик кирәккә тоткан Туфанны.
Рухыбызны Такташ йолып калды
мескенлектән,
гарьлек,
коллыктан.
Рухыбызны мәгърур итәр өчен
гомеребез сиңа юлыккан.
Ә син безне юлда көтеп алдың.
Китермәдең янга ятларны.
Байлыгыбыз моң да хыял иде,
син очрадың —

Алла саклады.

...Ята идем үрләр итәгендә.
Канап беткән тезләр, терсәкләр...
Мәтәлгәндә,
тәнең генә түгел,
яралана уйлар, теләкләр...
Көтмәгәндә синең хатың килде,
«Кысам,— диеп,— сөенеп кулыңны»*.
(Мин ул чакта инде белә идем
тормыш дигән кырыс уенны.)
«Җырларыңа каршы бар,— дип яздың,—
тоясың,— дип,— моңның кадерен».
Белсәң икән
синең бу сүзләрдән
нишләгәнен минем бәгырьнең!
Иң беренче хатың.
Син бит мине
бер тапкыр да әле күрмәгән.
...Туфан тавышы килде,
чакыру килде
Туфан басып торган үрләрдән.
Карлыгачлар гына иде бит ул,
шигырьгә юл яңа башланган.
Ә мин инде,
лаек түгел, диеп,
өметләрне өзеп ташлаган.

Өч ел тоташ бер юл язылмаган,
якын бармыйм кәгазь-каләмгә.
Үземә үзем үгет-акыл бирәм:
ник керергә сиңа хәрәмгә!
Шагыйрьләрнең, кара, ниндие юк,
буяулары төссез лак кына.
Юк!
Рәнҗемәм шагыйрь булмасам да,
күңелләрем калсын пакь кенә.
Кем ялгышмый?
Син дә балачакның
хыяллары белән саташкан.
Шагыйрь диеп, бәлки, әйтерләр дә,
оят булыр үзеңә Такташтан.

Туфаннары исән...
Сибгатләре...
Баһадирлар монда,
Алыплар...
Тик шул гына шагыйрь —
кем иелми
сөрлеккәндә хәтта халыклар.
Бүген баш тарт,
көчең җитмәс булса
шул мәйданда урын алырга.
Рөхсәт итмәс намус
шигъриятнең
теләнчесе булып калырга!

Шул вакытта килде синең ул хат.
Әйләндереп атты уйларны.
Мин үземне-үзем белмәгәнмен —

тыела алмый җаным уйнады.
Үземне үзем сүктем, битәрләдем:
син ваемсыз,
бәгырең туң икән!
Туфан кадәр Туфан яза сиңа,
чигенергә хакың юк икән.
«Иманыңны ата шайтанга да
бирмә, энем», — диеп язгансың.
Өстәгәнсең шунда:
«Хәерле юл!
Күңелләрең генә азмасын!»

Өч ел тоташ бер юл язылмаган,
авыр булды минем оятыма.
Күзләремә карап сорадым мин:
кая җавап Туфан хатына?
Кыен иде кинәт җавап бирү,
без уяндык кына ул чакта.
Менә хәзер карап утырам мин:
дөрләп яна утлар учакта.
Җавап булып янсын бу учагым.
Сүрелмәскә инде кабынган.
Йөрәгемне шул учакка аттым,
утларына бүген табынам.
Уты аның Туфаннарыннан.

Айлар гына,
еллар гына түгел,
гомерләр дә үтәр зарыгып.
Сагышлардан бер котылып була,
сагынудан булмый арынып.
Без аңлаган,
безне аңлый торган
кешеләр бар,
җитә иптәшләр.
Үзебезнең күңел киң чагында
беркайчан да ялгыз итмәсләр.
Тик бераү дә сине алыштырмас:
рухың башка,
күңел,
җан башка.
Бүтәннәрне белмим.
Бусы дөрес —
Туфаннар юк икән алмашка.

Җиребезне,
күгебезне ачып,
гашыйк итте Такташ җаннарны.
Шул җаннарга илһам-иман салдың,
кодрәт бирдең, Туфан, аннары.
Югалмады моң һәм хыялыбыз,
сынап тордың рухның ныклыгын.
Без тоймадык үгет-нәсихәтнең,
хәер-догаларның кытлыгын.
Агымнарда бәрелә-сугыла йөзеп,
агып китә адәм башлары...
Маякчысы булдың каекларның,
урап үтә алдык ташларны.
Аркабыздан кагып үстердең син,

ятимлекне күңел сизмәде.
«Иманыбыз исән-саумы?» — дисәк,
синдә иде аның бизмәне.

Сагышлардан бер арынып була,
сагынудан булмый котылып.
Рәсемеңне алып ике кулга,
карап торам кайчак онытылып.
Безне һаман алга дәшеп тора,
хуплап тора балкып карашың.
Элеккечә һаман,
син хәзер дә
тузан ярып алдан барасың.
Сиңа барып баеп кайта хисләр,
ике арада алар туктамас.
Замана да,
ерак аралар да
уебызны безнең бутамас.
Без тоябыз синең якынлыкны
теләгәндә сине күрергә.
Синең уйлар,
синең җылы куллар
кирәк булыр безгә гомергә.
Мәңгелеккә барсын бу сагыну,
сары сагыш булып бармасын.
Сагыну калсын,
килер көннәр генә
сагынулар булып калмасын.
Кирәк булыр безгә бу сагыну,
сагынулар белән исән без...
Киләчәкне уйлап,
үткәннәрне
сагынуга дучар икән без...

**2**

Кайсыгызның кулы җылы? —
Бәйлисе бар йөрәкне...

*Х.Туфан*

Еллар үткән саен
бер үк борчу
кайтып-кайтып мине йөдәтә.
Үз-үземне күпме юатсам да,
китмәс, ахры, минем йөрәктән.
Инде күптән соң икәнен беләм,
тик җәберлим һаман үземне.
Нигә икән кайсы вакытта без
кирәгеннән артык түземле?
Ник табылмый вакыт
вакытында
иң кирәкле сүзне әйтергә?
Гомер буе газапланыр өчен
калдырабыз бикләп хәтергә.
Җылы сүз дә,
җылы кул да кирәк —
җылы кирәк тере чакларда.
Якыннарны эзли янган йөрәк,
һич каласы килми ятларга.
Әйтер сүзләр сиңа әйтелдеме?
Йөрәгеңне бәйли алдыкмы?

Әллә сиңа, Туфан,
мәңгелеккә
без бурычлы булып калдыкмы?
Син бит безне
хаста йөрәкләрне
дәваларга үзең өйрәттең.
Күчсен иде минем йөрәгемә
яралары синең йөрәкнең.
Бирмәс идең.
Күпме янып-көеп
көенечеңне безгә бирмәдең.
«Хәлең ничек, энем?»— дия идең,
«Хәлем авыр минем», — димәдең.
Сызлагандыр йөрәк яралары.
Йөрәк яши күбрәк сызланып.
Үз-үзеңне безгә күрсәтмәдең
беркайчан да ләкин кызганып.
Җылы сүзең,
нурлы күзең белән
тылсым иясенә әйләндең.
Сыкрап торган яраларын күреп,
күпме йөрәкләрне бәйләдең!

Бик хәтердә...
(Бетми,
югалмый да
йөрәктәге яра җөйләре.
Яралардан туа
һәм үлгәнче
яра җыя кеше йөрәге.)
Иңнәремә канат чыккан вакыт.
Хыяллар да чиста,
уйлар да.
Иң еракта янган йолдызына
җитәр кебек безнең буйлар да.
Күңелләрнең төптән ачык чагы,
керә тора яшәү ямьнәре.
Бөтереп алды мине моңлы җилләр,
сагышлары,
назы,
гамьнәре...
Шигырь булып шытты алар миндә.
Шигырь булып яфрак ярдылар.
Шигырь булып чыкты алар миннән.
Шигырь булып миндә калдылар.
Янып торган йөрәгеңә бозлы
су сипсәләр —
тирән ярасы.
— Хакың юк! — дип әйтте бер «зур абзый».
— Хакым бар! — дип, кая барасың?!
Ышандым мин.
Миңа әйтелгәнне
тиеш хөкем итеп санадым.
Үз-үземә шактый гөнаһлы бер
сөмсез кеше итеп карадым.
Без китаптан чыккан малайлар бит,
укый-укый,
ышанып,
инанып...
Акыл керде бераз яшәп кенә,

акыл керде безгә кыйналып.
Мин тәгәрәп төштем үрләремнән,
син бәйләдең, Туфан, яраны.
— Үзеңне дә җәберләмә, — дидең, —
гаепләмә, — дидең, — заманны.
Бер мин генә түгел.
Бу тормышта
егыла-тора кеше чыныккан.
...Күңелемә салкын йөгергәндә,
сине уйлап аны җылытам.

Бурычыбыз олы сиңа, Туфан.
Син табибы булдың заманның.
Түләп булыр аны,
киләчәктә
югалтмасак кына дәвамын.
Җылы кулга,
безнең җылы сүзгә
бик тә мохтаҗ җаннар бар әле.
Дөньялар да хаста,
замана да,
күп йөрәкләр бүген яралы.
Синең кебек,
инде үзебезнең
йөрәк яраларын онытып,
дөньяларны савыктыру өчен
яшисе иде
зурдан,
ныгытып.
Син беләсең бик тә җитмәгәнен,
табибларның бик тә кирәген.
Үз йөрәгең — үзеңнеке,
чыдар,
бәйлисе бар халык йөрәген.

**3**

Ә син дә бит, йөрәк, туктарсың бер?
Ә шулай да нигә син... тыныч?

*Х.Туфан*

Тыныч иде, дөрес, синең йөрәк.
Тыныч иде бик тә бер яктан:
намусыңа кер дә кундырмыйча
урап кайттың безгә еректан.
Синең язмыш туры килгән булса,
туры килгән булса бүтәнгә...
«Суйды тормыш!» диеп кайтыр иде,
нәләт укый-укый үткәнгә.
Кайтыр иде
көнен,
данын даулап
кәгазь белән,
йодрык,
сүз белән...
Кайтып кердең Казан каласына
бәллүр йөрәк,
дымлы күз белән.
Син рухыңны саклап йөри алдың
Халкың,
Илең,

Җирең каршында:
үз баласы булып кабул иттең
хаксызлыкны,
хакны —
барысын да...
Гаеплегә гаеп ташламадың.
Заман үзе дәште акланып.
Тыныч иде, Туфан, синең йөрәк,
кимсенмәде җаның вакланып.
Тыныч түгел иде башка яктан,
борчылуың булды башкада.
Язып киттең безнең хәтерләргә,
бәгырьләргә,
җанга,
ташка да:
«Мин дә аңа — ерак киләчәккә —
Сүзсез генә
Сораулар бирәм:
«Безгә анда — яңа гасырларда —
Укучылар очрарлар микән?..»
Ул борчулар күчә килә икән,
гамьлеләрдән күчә гамьлегә.
Бик куанып йөрер чаклар юкса
хозурлыкка,
тормыш ямьлегә.
Тыныч түгел әмма бүген йөрәк,
бик кыйммәткә төшә сабырлык.
Тын кысыла,
җанга һава җитми
күкрәк тутырып сулыш алырлык.

Татар китапларын сатып йөрим,
шәһәрләрдән китеп авылга.
Кол Галине алып килче, диеп
сорадылар соңгы баруда.
Нинди сүзләр белән җавап бирим
Кол Галине көткән абзыйга?
Кәгазь җитми, дисәм, ялган булыр,
оят кирәк, дияр, аз гына.
Дөньябызны инде кәгазь төргән.
Җитә генә, димим,
артык та.
Бетеп куя ләкин
Кол Галигә...
Кол Галигә кирәк вакытта.

Китап кибетләре киштәсендә
Такташ,
Җәлил,
Кәрим тезелгән.
...Без тормышка килеп кергән идек
шундый баһадирлар эзеннән.
Ибраһимов тора,
Әмирханнар...
Классиклар баткан тузанга.
(Нидер сөйли китап язмышлары...)
Өлгермиләр хәтта тузарга.
Кем укысын?
Өлкән буын таныш.

Бүгенгенең теле киселгән...
Аерылып китеп бара бугай,
туган моңнан,
туган хисеннән.
Каты буын үсә.
(Кем буыны?!)
Барысы да килә кулыннан.
Машиналар шавы кыйммәт бүген,
кыйммәтрәк халык моңыннан.

Һәр заманның була гөнаһысы,
һәр заманда була хаталар.
Шигырь өчен илдән сөреләләр.
Шигырь өчен терәп аталар.
Шигырь белән илләр исән кала.
Шигырь белән газиз баш китә.
Шигырьгә чит салкын битарафлык,
яклый шигырь
яки фаш итә.
Шигырьгә дә булмый битарафлар.
Булмаган да,
була алмый да.
(Була икән әгәр,
яшәве дә,
үлеме дә хәрәм андыйга!)
Кем өчендер шигырь — олы хәвеф.
Кем өчендер шигырь — таяныч.
Шигърияте булмаганы — бер хәл,
шигърияте беткән — аяныч.

Рентабельле түгел, диләр бүген,
матди яктан аклый алмый, ди.
Нәшриятка бары зыян гына,
бер тиен дә табыш калмый, ди.
Сорау да бер сиңа,
җавап та бер:
бастырудан аны ни файда?!
...Буш күзләргә карап тора шагыйрь,
һуштан китеп тора:
«Мин кайда?!»
Рентабельле түгел!
Мохтаҗ түгел
сүзгә,
хискә,
гамьгә,
моңга без!
...Акчабызны учлап,
моңсызлыкка
көннәр буе чират торабыз!
Мәк башларын урлап кыркып йөри
өметебез —
варисларыбыз.
«Каян килде болар,
кемнәр бу?» — дип,
үзебезгә-үзебез карыйбыз.
Гаеп эзләп булмый бездән хәзер
заманадан артта калуда.
Исерешеп йөри бала-чага
тараканга дигән агудан.

Ана теле кала чыгар-чыкмас,
ана сөте юк шул чит телдә.
Моңын җуйган былбыл баласыдай,
ике арада бала интегә.
Кайсы теле бүген үзенеке?
Әй буталды дөнья,
буталды...
...Татар теле дәресе:
укучылар
тәрҗемәдә укый Тукайны.
Кая китә, дөнья, кыйммәтләрең?
Бәяләнә алмый торганнар...
Ничә тиен тора безнең шигырь?
Ничә тиен тора бу җаннар?
Кирәк түгел, диләр, бүген шигырь:
маҗаралы роман укыйбыз.
Кая китте безнең
моңлы сүздән
канатланып йөргән рухыбыз?!
Сатылмаслык,
сатып ала алмаслык,
йөрәкләргә үзе керерлек
дару кирәк,
бөердәге түгел,
йөрәктәге ташлар эрерлек!
Шундый вакыт хәзер:
елый-елый
шигырь генә бүген язарлык.
Шагыйрьләрнең сүзен йөрәкләргә
укол итеп бүген кадарлык.
Шигырьләрнең кирәк чагы алда,
бәяләре булыр чамасыз...
Булыр микән шигырьләре генә,
калмас микән кеше чарасыз?
Җитмәбезме шундый заманага? —
Сүзләрнең дә бетәр ихласы.
Шигырьнең дә,
җырның,
моңнарның да
тимәс инде җанга шифасы.
Коткарырга кирәк җаннарны да,
шигырьне дә кирәк сакларга.
Шундый вакыт хәзер,
үзебезне
үзебездән кирәк якларга!

Туа тора көннәр нидер өстәп,
үтә тора нидер югалтып.
Тыныч түгел, Туфан, безнең йөрәк,
ә йөрәкне булмый юатып.
Алдыбызда шул ук сорау тора:
кемнәр укыр икән иртәгә?
Тарих белә:
шагыйрьләре белән
халыклар да шулай китәләр.
Безнең исәп ләкин алай түгел.
Рөхсәт итми тарих,
үткәннәр...
Кайгыртмасак бүген үзебезне,

кайгыртмас бит безне бүтәннәр!
Кайгыртырга вакыт җитте хәзер,
киләчәкне күрер көннәр бу.
Дөнья әнә
безгә карап тора:
кая бара болар,
кемнәр бу?
Учакларда ята тере күмер,
утлары бар,
җиле дөрләтә...
Тынычлык та,
ял да кирәк түгел,
яну җитми бүген йөрәккә!

**4**

Киләчәккә хатлар барып җитә,
Ә үткәнгә хатлар бармыйлар...

*Х.Туфан*

Үткәннәргә хатлар бармый, дисең.
Бармый да ул болай...
бара да.
Адреслары әгәр дөрес булса,
югалмый хат ике арада.
Хатлар юлы ерак,
бик тә мөмкин
очрап кую бәла-казалар.
Хатлар бару-бармау шуннан тора:
ул хатларны кемгә язалар.
Үткәннәргә түгел,
хәтта кайчак
киләчәккә хатлар бара алмый.
Йә хатлары туза,
йә адресы,
йә аласы кеше ала алмый.
Күпме генә язма...
Кая киткән?
Адресы юк.
Беткән.
Югалган.
Бик барырдай була хатлары да...
Борылып кайта ерак юллардан.
Тарих кына:
фәлән елда туып,
фәлән елда үлде, диячәк.
Йә үткәндә кала,
йә бүгендә,
кабул итә алмый киләчәк.

Сорасалар, Туфан кайда, диеп,
кирәк булса җавап аңарга,
әйтә алам:
Туфан көн дә туган
һәм туачак безнең таңнарда.
Үткәндәме Туфан?
Бүгендәме?
Киләчәктәме ул?
Кайда ул?
Бу сораулар безне борчымыйлар.

Халык кайда —
Туфан анда ул.
Үткәннәргә хатлар бармый, дисең.
Син бик ерак инде үткәннән.
Бу егетләр миңа язадыр, дип
көтәсеңдер инде күптәннән.
Ә егетләр яза,
ник язмасын,
өзелмәскә тиеш буыннар.
Буш торуын тоеп сыкранмасын
Туфаннардан калган урыннар.
Әйтеләсе сүзләр кимемәгән,
арта тора көн дә чак кына.
Туа тора көннәр,
туган берсе шаһит итеп безне чакыра.
Язабыз без шул көннәргә карап,
шул көннәргә карап туганбыз.
Әйтмәс дошман:
— Бетте болар, — диеп, —
калды болар, — диеп, — Туфансыз.
Җанда иман,
янда Туфан барда
үзебезгә карап кимсенмәм.
Без язганны еллар бутамаслар,
җибәрәбез синең исемгә.
Ә син ерак.
Ерак киләчәктә.
Кодрәт кирәк сиңа җитәргә.
Хатларыбыз — шигырь.
Әзерме алар
шушы юлга чыгып китәргә?
Күптәннән юк,
инде булыр микән
шигърияттә синең ишеләр?
Китеп бетте бугай
дөньяларның
ут-суларын кичкән кешеләр.
Фронтовиклар китте...
Чын остазлар...
Алар урынын бүтән алалмый.
Аксакаллар иртә китеп бара,
калганнарның сакал агармый.
Низагларга урын артып китте,
зур мәҗлестә җитми мәртәбә.
Сез кабызган шәмнәр яна әле,
янар алар,
сүнмәс иртәгә.
Балкып йөри бүген безнең буын,
йөзләрендә Туфан яктысы.
Бәхетле без,
сиңа туры килдек,
шигъриятнең зирәк сакчысы!
Сират күперләрен үткән кебек,
үтеп заманалар арасын,
белеп язам,
безнең язган хатлар
тоткарланмый сиңа барасын.
Кая язсам,
шунда барыр хатым.
Адресың бар,

табар ул аны:
үткәндә дә табар,
бүгендә дә,
киләчәктә табар Туфанны!

Заманалар затны юк итәләр,
чүп итәләр,
туфрак итәләр.
Бетте! диеп озатып кала дөнья —
хур ителеп,
сөрелеп китәләр.
Җиңә бәндә.
Ирешә теләгенә.
Көрәш тәмам —
нокта куелган.
Суд та беткән,
судьялар да киткән —
ике як та чыккан уеннан.
Тарих кына,
көннәр,
еллар булып,
бара тора,
аның эше бар:
җилкәсендә,
кичә үтерелеп,
киләчәктә туар кеше бар.
Туа башта киләчәкнең җаны
җәбер,
золым,
михнәт,
кан булып.
Бөеклеккә хурлыклары илтә,
кайта җиңелүләр дан булып.
Кайвакытта
дөреслекне бары
тарих кына раслый хак итеп.
Әшәкегә батырып карый дөнья
күрер өчен чиста,
пакь итеп.

Заманага таянуым түгел.
Кешеләрне яхшы, яманга
заманалар бүлми,
кеше үзе
үз шартларын куя заманга.
Ничек кенә еллар килмәсеннәр:
кара булсын алар...
ак булсын...
үз иманы белән яши адәм,
үз иманы гына хак булсын.
Һәр заманның була фәрештәсе,
сволочы...
(Шагыйрь сүзләре!)
Йә, әйтегез,
кайсы заманадан
карап тора Туфан күзләре?!
Карашларын суыта алмаган бит
ак еллар да,
кара еллар да...

Ә без артка чуан чыккан саен
әзер бүген ятып еларга.
Әллә ничә замананы үтеп,
шушы караш керә нур булып.
Туфан булыр өчен яшәү кирәк
заманадан бераз зур булып!

1985 — 1986

***

Җырлый-җырлый ата көн дә таңнар.
Өр-яңа җыр көн дә Кояшы.
Тоя белсәң әгәр,
бер сулавын
илаһи җыр итеп тоясың.

Яңа җырлар кебек йөзә болыт.
Яңа җырлар кебек ага су.
Өр-яңа җыр кебек бөтен дөнья,
югалыр җыр кебек ямансу.

Табылмаган җырдай йолдыз ерак.
Табылмаган җырдай күңелләр.
Табылган җыр кебек туа кеше.
Югалган җыр кебек үлемнәр.

Табылмаган җырлар табылырмы?
Табылганы — Җирдә каласы.
Җырда коенып,
җырга сусап йөри
дөньяларның күпме баласы!

Җырлый белгәннәргә җырлар кирәк,
белмәгәнгә кирәк бигрәк.
Җырны табулары ансат түгел,
җырны югалтулар — гыйбрәт.

Ике гомер безгә насыйп булмас,
бер яшибез җирдә
бер туып.
Шушы Җирдә бик каласы килә
бер югалмый торган җыр булып.

1985

## Кифая

*Түбән Кама шәһәренең талантлы үзешчән җырчысы К.Галиева истәлегенә*

Иреште миңа бик соңарып,
кайларда йөргәндер бу кадәр?
Иреште соңарып,
бөтенләй
килмәсен иде ул — бу хәбәр.
Үземне кызгану гына бу.
Барыбер киләчәк иде ул.
Килде дә...
аяусыз рәвештә:
«Кифая юк инде!» — диде ул.
Бер генә идең син.

Безнеке.
Моңлы да,
көләч тә,
чибәр дә...
Оҗмахка омтыла иде җан,
Кифая,
син җырлап җибәрсәң.
Моңнарың канатлы моң иде.
Муртайган җанны да яшәртте.
Синең моң, җырлатып, елатып,
мәхәббәт күгендә яшәтте.
Күңелем әле дә ышаныр,
башкара Кифая, дисәләр.
Кимеде җырларның моңнары,
саекты «Җидегән чишмә»ләр.
Сәхнәдә бер урын буш тора.
Күңелдә сызлана бер урын.
Җырларны халыкка илтүче
өзелеп калды күк бер буын.
Бөтенләй булмасын иде ул,
килмәсен иде ул — бу хәбәр.
Белмәгән икәнбез,
сине без
яраткан икәнбез никадәр!
Кимемәс сагыну сагышы —
кайгырып,
офтанып ни файда?!
Моң булып,
җыр булып гомергә
калдың син йөрәктә,
Кифая!

1985

***

Көннәре Кояшлы түгел,
төннәре Айлы түгел.
Гомернең шундый вакыты —
күңелләр җайлы түгел.

Сызланып ала, сыкрап,
суынып китә кинәт.
Йөрәккә җылы кирәк бит,
йөрәккә җылы кирәк.

Учакларда яна утлар,
ник суык ялкыннары?
Безгә кирәкләре ерак,
җылытмый якыннары.

1986

## Кыңгыраулы яшел гармун моңы

*Хәниф Әхмәдуллин*

*истәлегенә*

Зур да булмый кайгы-хәсрәтләрең.
Безгә бит ул зур күк тоела.
Вак-төяк тә житә безнең өчен —
юктан гына җаннар кыела.
Саллы гына сагышлар да килә.
Китми торган булып,
гомергә...
Рәнжи күңел,
риза булырсың күк
җәһәннәмнең үзенә керергә.
Күңелеңне кайда юатасың?
Сер бирәсе килми ятларга.
...Әкрен генә килеп чыга идек
синең янга шундый чакларда.

Бер кечкенә генә шатлык кисәге дә
күңелләрне иркен,
киң итә.
Кайчакларда дөнья елмая да
хакимнәргә безне тиң итә.
Яхшылыкка тик яхшылык белән,
уны белән риза түләргә.
Риза җаның
якты дөньяларның
этләрен дә кочып үбәргә.
Серләреңне кайда бүлешәсең?
Кирәк түгел алар ятларга.
...Гөрли-гөрли килеп чыга идек
синең янга шундый чакларда.

Авыр уйлар белән киләбезме,
киләбезме көлеп,
елмаеп —
таба идек синдә бер юаныч,
китә идек синнән куанып.
Сөйләшмәдең артык.
Күп сөйләшсә,
кешене дә бераз сөймәдең.
Кулларыңда сайрап торды гармун —
уйнадың син татар көйләрен.
Син уйнадың халык көен генә.
Синең моң да анда бар иде.
Ургып ташты безнең хисләребез —
бу дөньялар инде тар иде.
Башка дөнья алып китте безне.
Җаннарыбыз янды яктырып.
Йолдызлары белән,
Айлар белән
җыр тыңладык таңнар аттырып.
Рәхмәтне дә безнең,
мактауны да,
хуплау сүзләрен дә көтмәдең.
Гамьсез чакта безне гамьле иттең,
моңсыз чакта моңнар өстәдең.

Син сыйдырган идең күңеленә
халык җырларының бар моңын.
...Һаман тыңлыйм:

йөрәкләрдә чыңлый
кыңгыраулы яшел гармуның.

1986

## Сокланам

Хөрмәтем зур минем артистларга.
Артистлыгым гел юк тумыштан.
Сәхнәләрдән мине ерак йөртте,
өйрәтмәде аңа тормыш та.
Чыккан чагым була.
Сәхнәләрдә
мин барыбер озак чыдамыйм.
Артист булып түгел,
сирәк кенә
шагыйрь булып кына чыгам мин.
Шигырь укыйм.
Үзем карыйм залны.
(Мин өйрәндем моңа күптәннән.)
Мине тыңлап утыручыларны
үз күңелем аша үткәрәм.
Берәү тыңлый тәртип өчен генә.
Эше юкта берәү кергәндер.
Бардыр берәү:
безне күргәндер дә
шигырь тыңларга дип килгәндер.
Бик күрәсе килә шул кешене,
килә аны эзләп табасы.
Эзләп табып,
шушы күрешүдә
килә аны танып каласы.
Шул вакытта шигырь ярдәм итә.
Әллә каян гына күрә ул.
Үзен яратканны күреп алып,
йөрәгенә барып керә ул.
Мин дә күрәм инде.
Мин дә таныйм.
Уртасында залның кыз бала...
Эзләп тормыйм бүтән,
инде таптым,
карап укыйм инде мин аңа.
Уе-хисе аның күзләрендә.
Миңа карый —
күрми мине дә.
Уятмагыз,
кагылмагыз гына —
ул кыз инде шигырь илендә!
Хуҗа түгел инде мин шигырьгә,
тапшырырга аны мин әзер.
Һәрбер сүзне йотып бара кызый,
бу кызныкы инде ул хәзер.
Күзләреннән шуны күреп торам.
Күреп торам тирән караштан.
(Андый кешеләрнең күңеленә
кереп китсәм, мин дә адашам.)
Шигырь кирәк аңа.
Күңел шундый.
Хисләренә хисләр кирәктер.
...Бөтен кеше андый була алмый.
Андый җаннар аздыр,

сирәктер.
Бөтен залга, бәлки,
бирәүдер ул.
Авылына, бәлки, бирәүдер.
Шушы караш
иҗатыңа, бәлки,
иң зур тариф белән түләүдер.
Сатылмый да,
сатып алынмый да,
бәяләнми шигырь базарда.
Шушы кызый өчен генә дә мин
гомер буе риза язарга.
Дан җырлавым түгел шигъриятькә.
Бәя куймыйм шагыйрь эшенә.
Сокланам мин,
шигырь язмаса да,
шагыйрь җанлы булган кешегә!

1977

## Бишек җыры

Йоклый бала. Йөзе тыныч.
Керфекләре йомылган.
Йоклый бала. Сүздән түгел,
йоклый җырның моңыннан.

Көе бер үк, моңы бер үк —
кем генә җырламасын.
Аңлый аны — кайсы илдә
кем генә тыңламасын.

Аналар чыгарган аны,
аналар язган аны.
Аналар җыры — бөек җыр,
җырда аналар җаны.

Җылыта Җир балаларын
йөрәктән чыккан җылы:
халыкларның уртак моңы —
илаһи бишек җыры.

1986

## Туган йортта

Таң ата. Керә яңа көн —
ачылган тәрәзәләр.
Таңга манчылган пәрдәләр
шул таңнар кебек зәңгәр.

Бөркелеп керә җаныма
сулышы иртәләрнең.
Беренче кат тоям кебек
җилләрнең иркәләвен.

Гомергә җитәр шикелле,
тирән итеп суласам.
Мин бәхетсез булыр идем,

әгәр монда тумасам.

Йоклап буламы ул чакта?
Йокылар күптән туйган.
...Алмагачы ботагына
ике кош килеп кунган.

Сайрыйлар. Инде суламыйм:
берәрсе ялгышыр күк.
Монда һәр кошның тавышы
сандугач тавышы күк.

Карап ятам тәрәзәдән
чиясен, миләшләрен...
Беренче кат ишетәм күк
яфраклар сөйләшкәнен.

Гомеремнең хозурлыгы
бары тик монда гына,
...Өр-яңадан туып ятам
туган як моңнарыннан!

1986

## Әни

Тавышлары булмаса да,
әллә каян ишетәм:
аяк очларына басып
керә әни ишектән.

Уянмасын ди ул мине,
таң йокысын бүлмәсен.
Күзләремне йомып ятам,
уянганны күрмәсен.

Куанып ятам әнинең
исән-сау көннәренә.
...Аяк очларына басып
су сибә гөлләренә.

Атасы, дип, балалар, дип,
үзе дә сизми бугай,
аяк очларында йөрде
гомере буе шулай.

Тыңлап ятам: мин әнинең
бар гомерен ишетәм.
...Аяк очларына басып
чыга әни ишектән.

1986

## Ветераннар күрсәм

Яшь тә шактый.
Инде чәчләремнең
каралары агы аралаш.
«Күпме гомер узган икән!»— дисең,
артларыңа борылып карагач.
Миңа инде күптән әти диләр.
Олы кеше итеп карыйлар.
Бу тормышны авызлыклап тоткан

булдыклы ир итеп саныйлар.
Тик бирәү дә белми:
«әти» сүзе
кадала да кереп күңелгә,
малай итеп,
бала итеп куя
шушы яшьтә мине бүген дә.
Чал чигәле өлкәннәрне күрсәм,
ветераннар диеп әйтүгә
уйлап куям:
менә шушы яшьтә
булыр иде минем әти дә...
Күз алдыма килә:
кара-каршы
утырабыз менә сөйләшеп,
замананың бөтен низагларын
хәл итәбез икәү киңәшеп.
Ике ир без.
Ата белән улы.
Бер кан,
бер җан —
шушы бер итә.
Ни уйласак —
шул эш килә кулдан,
ни теләсәк —
шуңа көч җитә.
Ул да кирәк.
Ләкин мөһим түгел —
кем булыша кемгә яшәргә.
Әти дигән кеше кирәк икән
әти диеп әле дәшәргә.
Ата кирәк диләр бала чакта.
Мин ышандым ата кирәккә.
Мин ышандым тагын:
ата кирәк
үзең ата булгач бигрәк тә!

1986

## ***

Җылы мамык булып өскә ява,
сөенечкә ява, дисеңме?
Мин карларга язып йөргән идем
былтыр кышта синең исемне.

Алар инде эреп беттеләр шул,
еремәсә карлар, яз булмый.
Язларында, белмим, нәрсә булыр,
быел карлар ята язылмый.

1983

## Рәхмәт, әби!

Әби юмарт иде.
Ачлык елда,

килеп кергәч сукыр теләнче,
елый-елый мичтән алып бирде
соңгы алабута күмәчен.
«Бабагыз да сукыр иде, — диде, —
бу кеше дә сукыр...
жәлләдем...»
...Яннарында менә басып торам,
белергә дип кайттым хәлләрен.
Ике кабер.
Рәттән.
Әбинеке
биегрәк кебек,
яңарак.
Кырынайган бераз бабай кабере
әбиемә —
түбән табарак.
...Истә тора минем шул ачлык ел.
Теләнче дә истә,
күмәч тә...
Кабат-кабат кайта хәтеремә
күпме елдан,
әби үлгәч тә.
...Без әбигә шундый үпкәләдек!..
Яратмадык аны ул көнне.
«Сабыйларның авызыннан өзеп
бирдем бит...» — дип, ул да үкенде.
Мин аңладым еллар үткәч кенә
аңа ничек кыен булганын.
Соңгы күмәч...
Бәгыреннән өзеп
биргән икән аңа ул аны.
Алабута,
ат колагы,
юкә...
алып калды безне үлемнән.
Алар түгел,
китми әбиемнең
кешелеклелеге күңелдән.
Суынып беткән
ул бер күмәч кенә
коткара алмас иде ачлыктан.
Саклап калган әби рухыбызны,
җаныбызны ялангачлыктан.
...Каберендә торам.
Ел да кайтам
шушы сүзләремне әйтергә:
Рәхмәт сиңа теге күмәч өчен,
бик хәтердә, әби,
хәтердә!

1986

## Тора дөнья

Йөзә дөнья галәм диңгезендә.
Күптән йөзә дөнья,
күптән тора.
Бер уйласаң,
гади генә кебек —
бөтен дөнья Җирдән, Күктән тора.

Туабыз да Җирдә,
Күккә карап,
без китәбез кабат туар өчен.
Керәбез без дөнья дигән йортка
төшләр күреп,
төннәр кунар өчен.
Ә төн озын.
Дөнья йоклатмый ул
тыныч кына сине,
оныттырып.
Күрсәтә ул сиңа хуҗалыгын,
бер төнендә кат-кат,
торып-торып...

Туктап тора дөнья.
Туймас туктап.
Дөнья тора әле тагын ачтан.
Йөзә дөнья муллык диңгезендә,
тора дөнья әле ялангачтан.
И замана!
Ничек кыйммәт тора
бу дөньяда өс һәм тамак хакы!
Африкадан Ауропага йөри
хәер эстәп бүген адәм заты.
Җирнең әле ертык җире җитә.
Халыкларның куыш-түбәсе юк.
Туйганнары ачтан үлми торып,
ачларының икмәк күрәсе юк.
Юктан түгел.
Күп булганга шулай —
артык тукка артык ачлар кирәк.
Иске хәл бу.
Әмма шунысы яңа, —
тук та зирәк бүген,
ач та зирәк.

Оятсыздан тора.
Гаделсездән.
Гаделләрдән тора,
горурлардан.
Юк!
Бу дөнья
бер дә уйламыйча,
бер дә белми генә корылмаган.
Кемгә дөрес.
Кемгә дөрес түгел.
Кемгә гадел.
Кемгә гаделсезлек.
Һәрбер буын шуны тәкрар итә,
һәм оныта...
Нинди хәтерсезлек!
Кабатлаудан тора мәллә дөнья?
Гел кабатлау мәллә бер үк эшне?
Нишлибез без?
Миллион еллар буе
туа мәллә һаман бер үк кеше?!
Ышанабыз —
арта безнекеләр.
Ныгый сафлар.
Тыгыз бу сафларда

гаделләр дә, горурлар да җитә...
Тик шик туа миндә кайчакларда:
үкчәләргә басып килә әле,
тотынам дип килә итәкләргә.
Туа мәллә Җирдә гаделлекләр
гаделсезлекләрне җитәкләргә?!
Кайсы туган алдан?
Иң беренче
бүген бездә кайсы туа аның?
Кайсы белән үлчәп була бүген
кешелекнең шушы чуар җанын?
Яхшылыкны кыен үстерүе.
Яманлыгы аның артмас микән?
Кешелекнең изге ниятләре
гаделсезлек булып кайтмас микән?

Гамьсезләрдән тора.
Гамьлеләрдән.
Дөнья тора тагын битарафтан.
Карап торсаң,
бар да парлы-парлы,
кимсетмәгән бер дә —
тиң яраткан.
«Кайсыгыздан тора бу дөнья?» — дип,
юри генә тот та син бер сора.
Илһамланып,
дулкынланып әйтер,
өчесе дә әйтер:
«Миннән тора!»
Өчесе дә алар бик хак булыр
һәм өч төрле булыр ул хаклык та.
Кайсынадыр кайгы булып килер
кайсынадыр килгән зур шатлык та.
Гамьсезләрне сүгә гамьле кеше,
гамьсезенең анда гаме дә юк.
Гамьле кешесенә бу дөньяның
гамьсезләрдән башка тәме дә юк.
Гамьсезнең дә бүген үз гаме бар,
ул гамьледән көлә «юләр» диеп.
Ә битараф язып элеп куйган
«Икесе дә бетә, үлә» диеп.

Имансыздан тора әле дөнья.
Иманлыдан тора,
инанганнан.
Югалмый ул иман җәберләүдән,
югалмый ул иман кыйналганнан.
Сатылган ул элек-электән үк,
ирләр,
илләр,
дәүләт арасында.
Таянганы барыбер иман булган,
иман булган адәм баласында.
Ныгый бара Җирдә инанулар,
имансыз да арта хикмәт белән.
Буш сүз булып саналадыр инде
ант итүе бүген икмәк белән.
Дөньяларның шундый чуар чагы,
ышанычлар кими сүзгә, хискә.

Иртән канун булган төшенчәләр
челпәрәмә килә инде кичкә.
Хәзер дә ул иман сатучы бар,
алучы бар,
әгәр сатып калсаң...
Ул гомердән булган дөньяларның
аулак җире,
әгәр ятып калсаң.
Кыяр-кыймас тора кайчак кеше,
«оят саклап»,
ягъни «иман саклап».
Кемнәргәдер тик шул гына кирәк —
имансызлар үтә иман таптап.
Һәм уяна иман.
Уяталар.
Соңга калган бераз,
кичегелгән.
Имансызлар инде кереп тулган
ачык калган заман ишегеннән.

Барысы да булган.
Шул булганнар
арта тора бүген,
үсә тора.
Кеше хисле һаман,
дөнья һаман
мәхәббәт һәм нәфрәт-үчтән тора.

Күп нәрсәдән тора,
күп нәрсәдән...
Дөнья тора тагын ятимнәрдән.
Дөнья тора яралганнан бирле
усал коллар,
явыз хакимнәрдән.
Кол да туа,
хакимнәр дә туа:
кая китсен алар —
дөнья шундый.
Тапкан инде үзенә шушы юлны,
китеп булмый читкә,
китеп булмый...
Көрәшкәннәр коллар,
ә хакимнәр
көрәшмәгәнмени җанын салып?!
Көрәшләрдә туа,
көрәшләрдә үлә,
көрәшләрдән тора бөтен халык!

Гел көрәштән тора безнең дөнья.
Җиңүчесе кая,
җиңелүче?
Туа тора яңа төзүчеләр,
туа тора яңа җимерүче.
Уй-фикерләр,
хисләр,
көчләр каршы,
көрәшергә кушкан,
куша язмыш.
Көтеп торып,
карап торып булмый —

бик кыйммәткә төшә хәзер ялгыш.
Зур көрәштән тора бүген дөнья,
ул элек тә торган көрәшләрдән.
Ләкин әле
беркайчан да кеше
болай зурдан кубып көрәшмәгән.
Бөтенесе булган электән үк.
Дошманына кеше таянмаган.
Кеше киткән.
Көрәш дәвам иткән,
берсен-берсе яклар аямаган.
Күп нәрсәләр булган,
күпләр беткән,
көл калмаган кайчак йорттан-илдән.
Киткән адәм җанын-канын биреп,
ә көрәше һаман кала килгән.
Дуслары күп,
дошманнар да җитә
көрәшләргә аны дәшәр өчен.
Шул көрәшләр аны тудырганнар,
шул көрәшләр кирәк яшәр өчен!

Йөзә дөнья галәм диңгезендә.
Шыплап тулган бүген безнең кораб.
Бара дөнья киләчәккә таба,
бара дөнья алдын, артын карап.
Артында да аның көрәш кенә,
көрәш кенә киләчәге аның.
Тик көрәштән тора бүген дөнья,
көрәш кенә йөртә дөнья канын!

1981

## ***

Бер ялгышсыз гомер итеп була.
Бүген дә бар әле андыйлар.
Ул яшәүнең шартлы икәнлеген
андыйлар да бик шәп аңлыйлар.

Аңлыйлар да...
Ләкин ялгышмыйлар.
Ялгышларның хакы югары.
...Горур булып,
ихлас булып йөрдек,
ялгышлардан котылып булмады.

Кемгә ялгыш,
безгә дөрес иде...
Шуны сорыйм әле язмыштан:
башкалары инде кабатланмас,
тик аерма син бер ялгыштан:

бу дөньяның бөтен мәшәкате,
авыр йөге безнең җилкәдә
дип уйлыйк без,
уйлыйк соңга кадәр...

һәм ышанып китик
киткәндә!

1986

## Улымның анасына

Үпкәләмә.
Гаеп-мазар эзләп
кимсетүем диеп карама.
Икебезнең уртак дөньябызга
күз салуым гына яңадан.

Күп вакытта безнең сүзләр уртак.
Күп вакытта уртак уйлар да.
Шулай кирәк.
Бурычыбыз шундый —
бергә яшәп, бергә уйларга.
Матур яшибез дип сөйли кеше,
туры килеп торса уй-шөгыль.
Ә шулай да
төрле чаклар була,
гомер итү җиңел эш түгел.
Җитешмидер кайчак сабырлык та,
хөрмәт-ихтирамда тирәнлек.
Ансат кына гомер уздырырга,
җиңел яшәүләргә өйрәндек.
Никадәрле дөнья иркенәйсә,
вакланулар артты шулчаклы.
Ансат түгел җылы тотулары,
сүндермичә өйдә учакны.
Ерактарак йөри бугай кайчак
олы хисләр,
тирән төшенчә...
Кешелектән чыгып куймыйбызмы
яшибез дип кайчак кешечә?
Уйлар уртак безнең,
сүзләр уртак —
шигем дә юк минем бу хакта.
Чатнап-чатнап китә әле тормыш,
бер йодырык кебек булсак та.
Шуңа микән
кайбер вакытларда
бик үк риза түгел икән мин.
Синең урыныңда булса әгәр,
әни нишләр иде икән? дим.
Хәтеремә килә күз карашы,
сүзләренең көче, кодрәте.
Үз мисалы белән тудырды ул
 әтигә дә безнең хөрмәтне.
Хөрмәт сүзе өйдә бизмән иде,
шуның белән барын үлчәдек.
Ач та булдык, ялангач та булдык,
гарип рухлы булып үсмәдек.

Үпкәләмә, кайбер эшләреңә
әни күзлегеннән карасам...
Хатын-кызның мин әнием кебек
булганнарын күбрәк яратам.
Горурлыгы,

олылыгы белән,
тугрылыгы белән хәзер дә
хатын-кызның эталоны булып
әни яши минем хәтердә.
Инде син дә күптән ана кеше,
кодрәте зур һәрчак ананың.
Тик бер теләк:
безнең әниләрнең
бик күрәсе килә дәвамын.

1985

## ***

Гомергә киткән түгел мин,
кайтырга киткән кеше.
Юатам сабыр күңелне —
азмыни минем ише...

Заманалар алып киткән...
Очрап куя якташлар.
Мин әйләнеп бер кайтырмын,
алар инде кайтмаслар.

Тапканыма үзем риза,
югалганы табылмас...
Туган җирләр... Туган илләр...
Кемнәр генә сагынмас?!

Килә бер ачыласылар —
кемнәргә барып дәшим?
Үзем читләрдә, үзем гел
Туган ил белән яшим.

Талпына күңел, талпына,
кайтырга әле ерак...
Җансызларга кайда да бер,
җанлыга кыенрак.

1986

## Пристаньнар

Ераклардан дәшеп үзләренә,
янып тормый ярда утлары:
пристаньнар бергә җыелганнар,
киткән инде пароходлары...

Үтте җәйләр.
Пароходлар белән
кавыштырыр кабат яз гына.
Тынды Кама...
Тынып калды ярлар...
Ял итсеннәр инде аз гына.

Кайсы ярдан кайсы килгән монда —
исемнәре ачык язылган.
Яшәү ямен төяп килгәндер күк
һәр пристань үзенең ярыннан.

Сыенгандыр кеше язмышлары,
айлы төннәр белән бәйләнеп...
...Йә киткәндер мәңге кайтмаска дип,
йә кайткандыр берәү әйләнеп.

Кемнәрнедер алар аергандыр...
Кемдер тапкан...
Кемдер кавышкан...
...Пристаньнар чайкалышып тора
җәйләр буе җыйган сагыштан.

1986

## Син төшләргә алай кермә бүтән...*

*(Җыр)*

Син төшләргә алай кермә бүтән —
югалмаслык булып өнемдә...
Күз алдымнан китми әле
сине
иң беренче күргән көнем дә.

Мәгънәләрен эзләп аптырамыйм.
Эзлим бугай сине,
үзеңне.
Онытма тик,
мин хәзер дә шулай —
кирәгеннән артык түземле.

Син төшләргә алай кермә бүтән...
Өннәремдә юкса чыдамам...
Сынама да минем йөрәгемне,
аны инде дөнья сынаган.

1986

## Төшләргә кереп йөдәтә...*

*(Җыр)*

Төшләргә кереп йөдәтә,
яңгырлы төннәр, имеш.
Җилләрдә басып торасың,
җилләрдә... шәрә килеш.
Тузгыта җилләр чәчеңне,
сүтелгән толымнарың.
Әллә нишләтә бәгырьне
шул басып торуларың.
Битләрең буйлап су ага,
күкрәктән, иңнәреңнән...
Салкын тамчылар йөгерә
сарылып билләреңнән.
Ике күзеңнең карашы
миңа төбәлгән кебек.
Күземне ачсам, яңгырда
бетәрсең кебек эреп.

Җилләрдә басып торасың,
яңгырда торасың бит.
Талпынам сиңа чыгарга,
күрәм мин, туңасың бит.
Күрәм мин, туңасың бит.
Уянам, чыгам атылып.
Төн дә тыныч, җил дә юк.
Дөнья һаман элеккечә:
яңгыр да юк,
син дә юк...

1986

## Кеше

Ач та булыр.
Ялангач та булыр.
Ышыкланырга булмас урын да.
Уйлар кеше,
хыялланыр кеше
патша сарайлары турында.

Авыру булып яшәр.
Тоткын булыр.
Гомере буе кеше кол булыр.
Котылырга аны чакырып торган...
хыялында берәр юл булыр.

Яратмаган кеше белән торыр.
Туры килер начар хатынга.
Хыялында хур кызлары булыр
мәхәббәтне чынлап татырга.

Түзәр кеше.
Чыдар гомере буе.
Гомере буе шулай яшәр дә.
Каршысында аның үлем торыр,
хыяллары булыр яшәүдә!

1986

## Карап торам җирдән...

Үтерәм дип бер-беренә аткан,
үтерәм дип үзен яклаган.
Үлемен дә,
гомерен дә тапкан,
тик тынычлык кына тапмаган.
Сугышканнар Җирдә,
үлешкәннәр —
үч алмаган кемнәр кемнәрдән!
...Без бурычка алып яшәмибез
гомерләрне килер көннәрдән.
Бүгенгә дип бирелгәне яна,
сугышларда яна...
Көл булып.
Ни хикмәттер
көеп үлә тормыш,
шытып чыга тагын гөл булып.

Мәхшәр, дисең,
инде бетте дөнья...
Тыеп булмас кебек сугышны.
Шул вакытта
илаһи бер куәт
тирәнәйтеп куя сулышны.
Яшәүләрнең шундый бөеклеген
искәртә күк кинәт замана.
(Ямьсез, диеп, дөнья,
үзен-үзе
яратмаган кеше зарлана.)
Биек йолдызларның иминлеген,
иминлеген Айның,
Кояшның
таң йокыңны бүлеп торган саен
җаның-тәнең белән тоясың!
Кем кодрәте белән имин дөнья?
Шунысы хак —
бүген Җир исән!
...Төшләремә кереп аптыраткан
йолдызларны күрәм, «Җир!» дисәм.
Күз алдымда алар яна минем,
миннән соң да күпме яначак!
Тудык,
тордык,
үлдек монда, димим —
Җир әле ул безнең балачак.
Җир дә кирәк безгә,
Күк тә кирәк:
башланмаган юллар галәмдә.
...Штык кына түгел,
тынычлыкны
тотып тора Җирдә каләм дә.
Үлем булып кермимени сугыш
шагыйрьләрнең тере җанына?!
Бүген шагыйрь әле үз каләмен
манып яза үзенең канына!
Җирне яклап Җирдә шагыйрь йөри.
Шигырь йөри яклап Күкләрне.
Йолдыз дигән,
галәм дигән сүзләр
уйландыра бүген күпләрне.
Исәнлеге Җирнең кирәк безгә.
Йолдызларга юкса кем үрләр?
Бик аяныч булыр,
Җирдә туып,
Җирдә генә калса гомерләр.
Имин дөнья олы кодрәт белән,
исән дөнья
сугышып яшәп тә...
Җиргә булган,
йолдызларга булган
зур мәхәббәт безне яшәтә.
Җиребез яна.
Ерак йолдыз яна,
өмет булып яна —
сүнмәсен!
Чиксез икән галәм,
чиксез булсын,

чиксезне дә килә күрәсе.
Йолдыз ерак.
Анданиләр булмас!
Без булырбыз әле анда да...
Карап торам Җирдән...
Яшәү әле ул
яңа башлап куйган баллада!

1986

## Глобус

Алып кайтып куйдым өстәлемә.
Кирәкме ул миңа,
түгелме?
Чын Җир шары түгел икәненә
ышандыра алмыйм күңелне.
Һәр көн саен аңа күзем төшә.
Карап чыгам,
барлыйм,
тикшерәм...
Һәр шәһәрнең кайсы параллельдә
торганлыгын яттан мин беләм.
Елгаларын карыйм,
диңгезләрен,
йөреп чыгам кат-кат тауларын.
Сәяхәттә минем кичләр була,
сәяхәттә ата таңнарым.
Җир шарымны һаман әйләндерәм,
һәр ноктасын аның барлыйм мин.
Һәр көн саен,
җиргә соңгы тапкыр
караган күк әрнеп карыйм мин.
Әйтерсең мин бер авыру саклыйм.
Үзем белмим:
исән калырмы?
Җибәрергә Җирнең тамырына
сорарлар күк әле канымны.
Инде үзем авыру мин хәзер.
Бүтәннәр дә бүген чирдәдер.
Авыруым, бәлки, бетәр иде,
вируслары аның Җирдәдер.

1985

## Малах курганы

Курганнарның уртак тарихлары,
курган язмышлары —
сугышта.
Курган башларында хәл ителә
соңгы сугыш
соңгы сулышта.
Йөз елдан соң килеп баш иябез,
баш иябез халык канына.
Җирне,
суны канга күмгән афәт
әверелә курган данына.
Язмышлары шундый курганнарның.
Меңнәр анда...
Меңнәр кабере.

Курган булып калка,
һәйкәл булып
кешеләрнең изге хәтере.
Тезелешеп тора чыршылары.
Яшеллеккә, гөлгә чумган ул.
...Ә ул чакта
туфрак,
таштан торган
гади бер тау гына булган ул.
Тынлык монда.
Һәйкәл...
Чәчәк...
Сагыш...
Тантаналы моңга күмелгән.
...Җиңелсә дә,
саклап кала алган
Россияне,
Илне үлемнән.
Чыршы төпләрендә туплар тора.
Мәңгелеккә алар суынган.
...Севастополь,
Кара диңгез калган
бу курганда үлгән буыннан.
Сугышларның чиге булмаган күк,
каһарманлыкның да чиге юк.
Курганнарның һәркайсы да бөек,
курганнар күп,
әмма тиңе юк.
Бу курган да аерым.
Бу сугыш та.
Ике як та үлгән,
кырылган...
Бирешмәгән курган,
чигенмәгән
бер солдат та сугыш кырыннан.
Чигенмәгән!
Үлекләргә басып
күтәрелгән дошман курганга.
Батырлыгы белән җиңмәгән ул,
җиңә алган көчле булганга.
Батырлыкка ничек сокланмыйсың!
Башын игән,
җиңдем, димәгән.
Үзенеке белән
русларны да
бер кабергә салып җирләгән...
Яшәгәннәр.
Яши французлар,
үз җирендә яши бүген дә.
Шуның өчен кирәк булды микән
монда килеп,
монда үләргә?
Обелиск.
Ике милләт кабере.
Мәрмәрләре актан,
карадан.
Солдатлары ята заманының,
төрле илдән —
төрле анадан.
Диңгезгә үк агып төшкән каннар.

Үлә торган алар бергә-бер.
Кан дошманнар булып сугышканнар,
берләштергән аннан бер кабер.

Курганнарга карап уйланасың,
заманасы шундый булганга.
Әверелмәсме, дисең, үзе бу Җир
дөнья өчен үле курганга.
Җиңелүче дә булмас,
җиңүче дә...
Кирәк түгел сугышып үләргә.
Кабере дә инде кирәк булмас,
кеше булмас кешене күмәргә.
Тезелешеп тормас наратлары,
каберләрдә үсмәс гөлләре.
Кемгә кирәк?
Кемгә кирәк булсын
Җиребезнең андый көннәре?!

Тора курган.
Мәңге шулай торсын,
батырлыкка хөрмәт,
дан булсын!
Курганнардан ерак карап була,
кешеләргә гыйбрәт,
аң булсын.
Тора курган.
Җирнең бер һәйкәле.
Мең үлемне җыйган җир булып.
...Итәгенә сарыла ике халык
улларының җаны җил булып...

1986

## Кара болыт

Ераклардан килде кара болыт.
Өскә яуды кайгы-хәсрәт булып.
Ил дә зәгыйфь, без дә зәгыйфь идек,
бетүебез түгел микән, дидек.

Болытларны куып үткәрдек без.
Ауган капкаларны күтәрдек без.
Ил дә исән, без дә исән идек,
гомеребез озын икән, дидек.

Ераклардан килде кара болыт.
Тагын яуды кайгы-хәсрәт булып.
Зәһәр булып, хәтәр булып яуды,
ирләр ауды, илләр-җирләр ауды.

Суырды ул безнең җелекләрне,
йотты безнең сөлек егетләрне.
Күкрәкләрне куеп исән калдык,
исән калдык, бик нык сабак алдык.

Сабыр идек, чыдам, түзем идек,
була икән моны җиңеп, дидек,
сытып-изеп, тотып буып кына —
үзеннән дә көчле булып кына.

Канлы иреннәрне тешләдек без,
бөтен аттан артык эшләдек без.

Яумасын дип шул ук кара болыт
балаларга кайгы-хәсрәт булып.

Болытларга безнең яшен әзер.
Бөтен арысланнан көчле хәзер.
Еракта йөр бездән, кара болыт.
Кара болыт, безнең күкне оныт!

1984

## Хәзергә исән-сау*

«Өегез җылымы, тормышыгыз
арумы?»

*Фатих Кәрим хатыннан*

Тукай хатлары...
Такташ хатлары...
Синең хатларың...
Хатлар Туфаннан...
Бер артка карап, бер алга карап,
ярты юлымда уйлап тукталам.
Офыкларына җитә дә караш,
томаннарына китә алмый кереп...
Язгы ташулар юган шикелле
югала юллар, суларда эреп...
Тетрәнеп куям:
болардан инде
миңа кадәр дә үткәннәр икән.
Сорауларына җаваплар көтеп,
җавап алалмый киткәннәр икән.
Синең хатларны укыйм да кабат,
(бик таныш инде алар танышын),
тагын бер тоям
гомеребезнең
тарихка таба агып барышын.
Булгансыңдыр син шундый ук Фатих,
шундый ук Кәрим —
нинди хатыңда:
сорауларың күп өең-җиреңә,
бик аз язасың үзең хакында.
Өебез җылы,
тормышлар ару...
Суыклар хәзер зәһәр, чатнама...
...Сезнең хатларны кабат укыйбыз
өйләр суынып туңган чакларда.
Син дә азагын күрмәдең анын,
сугышлар инде беттеме? — дисәң.
Җавап бер генә:
сугышлар бара,
үзебез, Фатих, әлегә исән...

Тукай хатлары...
Такташ хатлары...
Синең хатларың...
Хатлар Туфаннан...
Аларны укып, үткәнгә түгел,
киләчәкләргә карап офтанам.

1987

## Без сугышта һаман

Берөзлексез һаман дәвам итә,
сугышның юк тәмамланганы.
Җиңүләр һәм җиңелүләр булды,
җирдә сугыш тәмамланмады.

— Бетте! — диде аны минем бабай.—
Җиңдек,— диде,— дошман дөмекте.
Юа-юа канлы кылычларны,
яраларны бәйләп көн үтте.
Хәл алырга яткан җиребездән,
бик арсак та, тордык яңадан.
Сугыш гел шул иде,
исеме бүтән,
ә каныбыз — яңа ярадан.

— Бетте! — диде аны минем әти.—
Җиңдек, — диде, — соңгы дошманны.
Әти минем, бөтен кеше кебек,
сугыш бетүенә ышанды.
Ул бәхетнең белде ни икәнен.
Тик иминлек кенә юрады.
Бүген менә безнең өйдән үтә
шул сугышның яңа юллары.

Сугыш бара һаман.
Бөтен җирдә...
Күчеп кенә йөри утлары.
Туктап тора икән,
аның әле
тын алырга гына туктавы.
Илгә төбәп,
безнең өйгә төбәп
атмаса да, туплар корылган.
Мин атлаган саен әле һаман
сугыш ярасына орынам.
Кулдан-кулга кала килә кылыч,
антлар эчеп ала киләбез.
Солдатларның варислары булып,
солдат булып кала киләбез.
Улларыбыз тора бүген чиктә.
Аларның да өзелә сулышы.
Бабасыннан калган шул ук сугыш —
аларның да бүген сугышы.
Буыннардан буыннарга кала,
барыннан да мөһим эш булып.
Кешелеккә даим янап тора,
йөрәгендә яман шеш булып.

Сугыш озын...
Аның зәхмәтләре
кешелекнең җанын йөдәтә.
Җир шарының кайтавазы булып,
чаң каккандай кага йөрәккә.

«Бетте!» диеп бүген кем әйтә ала?
Беттеме ул минем оныкка?
Ул да бүген сугыш дигән сүзне

йокысында гына оныта.
Чабатаны күрсә:
«Бу нәрсә?» — ди,
ишетсә дә аны, күрмәгән.
(Андыйлары онытылды инде,
чабатаны алдык түрләрдән.)
Ә кылычны таный,
автоматны,
пулеметны таный,
танкны...
Уенчыгы — сугыш кораллары.
Ул да солдат,
сугыш — аныкы.
Унбиш тиен салып сугыш ача,
тешен кысып ата,
җимерә!
Тешне кысып куәт биреп торам:
тырыша күр, берүк җиңелмә!

Ирек бирсәң, яшәр иде сугыш
киләчәкнең канын эчеп тә.
Тәмамлыйсы иде бу сугышны,
тәмамлыйсы иде ничек тә.
«Бетте!» диеп бүген кем әйталсын?
Бер көне юк дошман атмаган.
Без сугышка күптән киткән идек,
без сугыштан әле кайтмаган...

1983

## Тарала картлар җомгадан

**1**

Авылның хәлле заманы,
начар йортлары сирәк.
Аларга шәп йорты түгел,
иң чиста йорты кирәк.

Тузан да кундырмый торган
авылның толы була;
аның йорты һәрвакытта
нур белән тулы була.

Аякны салып керәләр.
Түбәтәй киеп кенә.
Түргә үтәләр йорт-җирнең
хәлләрен белеп кенә.

Бик төгәл җыела картлар —
ата-баба йоласы.
Саваплы көн, җаваплы көн —
һәр атнаның җомгасы.

**2**

Җомгаларда мулла да юк,
юк инде хәзрәтләре.
Тик бетмәгән картлар өчен
замана хәсрәтләре.

Сөйләшәләр, гәпләшәләр, —
сүзләре җитди, сабыр:
дөньялар һаман болгана,
елларның хәле авыр.

Әфган чикләре кызу, ди,
сугыша бит туганнар;
Үлә халыкның уллары,
үлә безнең оланнар.

Көн саен үлә гарәпләр,
баласын җирли ана;
Ливанны сөрем каплаган,
Африка җире яна.

Ашкына кеше кайларга?
Бу кеше нигә аза?
Берүк язмасын чыгарга
зурырак бәла-каза.

Коралын ташып күкләргә,
кемне куркыта адәм?..
Яши белмәгән җаннарга
оҗмахтай Җире әрәм.

**3**

Намаз вакыты җитсә дә,
намаз заманы үткән.
Җомгалар шул ук булса да,
догалар инде бүтән.

Сөйләшәләр, гәпләшәләр, —
сүзләре салмак, саллы:
арышлар җитте өлгереп,
санаулы көннәр калды...

Бетмәгән печән... Җитешер
арпалар, бодайлар да...
Бездән дә ярдәм кирәктер,
җәмәгать, бу айларда.

Урагын яшьләр урырлар,
саламы калсын безгә;
зиратның киртәсе тора...
калдырып торыйк көзгә.

Бик әйбәт килә еллары —
мул булып, матур булып...
Җыелып булмас җомгага
ураклар бетми торып...

**4**

Тарала картлар җомгадан
уртак фикергә килеп,
алдагы авыр эшләргә
хәер-фатиха биреп.

Шөкер, мәртәбәле үтте
бүген дә җомгалары.
«Имин булсын
илләр-көннәр» —
иң соңгы догалары!

1986

## ***

Уйланып йөри,
фикерләп...
Эше бар, шөгыле бар.
Чәчләренә чык йөгергән —
гаме бар,
күңеле бар.

Җитди эшләргә
җитми шул:
Кодрәт тә юк, көч тә юк...
Үзенә дә, кешегә дә
мәхәббәт тә,
үч тә юк.

Күренеп тора:
ваклана...
Ваклыгы эре кебек.
...Карасаң,
күптән үлгән бит,
ә үзе
тере кебек.

Таянсаң,
таеп китәсең.
Ярамый ышанырга.
Ул да адәм баласы дип
кала тик
кызганырга.

1986

## Дөнья

Илләр белән илләр талашалар.
Ирләр булып ирләр адашалар.
Яза халык ата-бабасыннан.
Җир көйрәтә итек дагасыннан.
Дөнья кайчак авып ята сыман —
кем егыла кемнең хатасыннан?
Еллар түгел чорлар ялгыш үтә,
зыкымнары дәверләргә җитә.

Нинди хафа сиңа, нинди оят? —
Мич башыннан карап тик кенә ят.
Дөнья барыбер кала,
йөрәккә якын алма.

Уй-фикерләр китә кире якка.
Керле урында акыл авырып ята.

Дөреслеге кайда, кайда хата?
Януыбыз нәрсә булып кайта?
Таралмасны кемнәр тараттыра?
Ярамасны кемнәр яраттыра?
Кемнәр әле дөнья бутап йөри?
Кемнең җаны көеп, сусап йөри?

Нинди гаеп сиңа? Син — җиде ят.
Мич башыннан карап тик кенә ят.
Дөнья барыбер кала,
йөрәккә якын алма.

Кешеләрдә йөри шөһрәт, зурлык.
Тиктомалга килде сиңа хурлык.
Начар кеше диеп атадылар,
ашадылар сине, ашадылар.
Язмыш сине каян абайлаган?
Дөнья усал, дөнья аямаган.
Ике күзең әнә шул дөньяга
әллә инде өмет белән бага?

Кайгыларың — дәрья, и ташыган...
Төштеңмени, туган, мич башыннан?
Дөнья барыбер кала,
йөрәккә якын алма.

1978

## ***

И акыллы булып карап йөрим,
тыңлап йөрим кайчак кешеләрне:
бер карасаң, миңа охшамаган,
бер карасаң, үзем ишеләрне.
Дәшми генә утырасы чакта
бер дә юкка кызып киткәлиләр,
көлеп кенә үткәрәсе сүзгә
бер дә юкка кинәт үпкәлиләр.
Менә аңа,
ярдәм итәм дисәң,
тик бер генә яхшы сүзең кирәк.
Карап тора бирәү —
син күрмисең,
аңа синең якты йөзең кирәк.
Бик әйтәсе килә шул вакытта:
игътибарлы,
сабыр,
сөйкемле бул!
Әйтә алмыйм,
кинәт искә төшә:
мин үзем дә алар шикелле шул...

1987

## Хөкемдар

Исәпләми яшәп булмый икән
гомерләрнең үткән һәр көнен.
Мин бик озак көтеп тордым бугай

кешеләрнең гадел хөкемен.

Йөриләрдер мине уйлап дисәм,
бераүнең дә миндә эше юк.
Кайвакытта кирәк гаепләүче,
гаепләргә мине кеше юк.

Көтмәгәндә сине гаеплиләр,
яклаучы юк шундый чагында.
Гомер буе икесен дә бергә
тота алмыйм шул мин янымда.

Инде үземә алдым ул эшләрне,
барганым юк судья-казыйга.
Үзеңне-үзең хөкем итеп кара —
ансат түгел андый вазифа.

Көне-төне язып кына тора
пәйгамбәрләр ике иңемдә:
гөнаһлар да табыла,
дөнья булгач,
саваплар да була минем дә.

Кем гаепләр мине,
кем яклар дип,
як-ягыма инде карамыйм.
Кирәк чакта яклыйм
һәм гаеплим,
карарын да чыгара барам мин.

Үзеңне үзең хөкем итү авыр...
Минем моңа тулы хакым бар.
Шунысы дөрес:
хөкем гадел булыр,
мин ышанам сиңа, хөкемдар!

1986

***

Юл куймады язмыш хәрәмнәргә.
Эләкмәде кайчак хәләл дә.
Артта — еллар...
Алда — юллар әле.
Ниләр язар икән гамәлгә?
Кайгылары шатлыкларсыз булмас —
хәстәрләгән күптән газапны.
Дөньяларның богаулары җитә —
рухым минем колмы,
азатмы?
Кылган эшләр кеше күңелендә
бер яхшылык булып ятармы?
Яшибез дип йөрүебез
игелекләр булып кайтырмы?
Алга килми,
алдан белеп булмый,
без көтмәгән хәлләр азмы соң?

Заманалар төзәткәләп тора
ялгышларын күпме язмышның.
Кыска түгел юллар безгә кадәр.
Безнеке дә күпме үтелгән.
Үткәннәрдән өзелмәсәм бүген,
киләчәктә, бәлки, үкенмәм.

1986

## Чишмәләр ага тора...

*Эдуард Касыймов истәлегенә*

**1**

Чишмәгә йөрде көн саен,
чәйләре тәмле, диде.
Шәһәрдән чыгып китүләр,
кайтулар ямьле иде.

Сулады авыл һавасын,
тыңлады урман җилен.
Шәһәрдән авылга йөреп
киңәйтте торган җирен.

Ял итә, диде, йөрәкләр,
хәл ала тәнең-җаның.
Биштәре белән бидоны
аркада иде аның.

Суы да кирәк булгандыр,
бик кирәк һавасы да.
Ни кирәген кемнәр белә
йөрәкнең ярасына?!

Чишмәләр тора чакырып,
чишмәләр дәшә кайчак.
Чишмәләр эзләп китәбез,
тормыштан бераз арсак.

Чакыра безне табигать,
чакыра инеш-сулар...
Ничәмә тапкыр үлемнән
коткарып кала шулар.

Тик алар безнең гомерне
гел саклап бармый икән.
Йөрәктән тотса, чишмә дә
коткара алмый икән...

**2**

Җитмәде барып бу юлы
чишмәгә, суларына...
Бер йотым һава җитмәде
чишмәсе юлларында.

Чыкмаган иде үләргә,

суга дип барган иде.
Яшәүдә иде уйлары,
тик бераз арган иде.

Үзебезнең кулда, дибез,
юк, язмыш кулларында...
Йә саклый өстәл артында,
йә чишмә юлларында...

Белә ул безнең кайларда
үлемне көтмәгәнне.
Белә ул безнең тормышны
уратып үтмәгәнне.

Күрсәтә башта туйганчы
нужасын, азапларын...
Бальзамнар итеп эчәбез
иҗатның газапларын...

Ниһаять, инде тормыш та
карый бер матур итеп.
Ниһаять, үзебезне дә
тоябыз батыр итеп.

Җиңдек, ирештек дигәндә
язмышың харап итә:
куанып яшәп йөргәндә
хәләлне хәрәм итә.

Йөрәктә йөртә язмышын,
аны соң кемнәр белә?!
Аякта үлә язучы,
аякта йөреп үлә!

Килгәндер барып җитәсе,
чишмәсе дәшкән аның...
Чишмәләр чакырып торган,
чишмәләр көткән җанын.

Ни дисәң дә җанга авыр —
исеме, җисеме шул...
...Чишмәләр чакырып тора,
барып ук җителми шул...

**3**

И йөрәк, фидакарь йөрәк,
күп нужа күргән йөрәк!
Кабынасың да янасың,
янасың гына дөрләп.

Йөрәге! — дибез.— Йөрәге!
И йөрәк туктамаса!
Һәркемгә бирәү генә бит,
запаста юк лабаса!

Вакытлар алыр әле дип,
үтәр дип юанасың.
Югыйсә белеп торабыз:
кагылсаң уаласың.

Килә дә кагыла тора
тормышның каргышлары.
Җыябыз һаман йөрәккә
дөньяның сагышларын.

Якыннар да өя йөкне,
ятлар да өсти тора.
Ә йөрәк безнең талымсыз,
баһадир төсле тора.

Күрмибез ялкыннарын да,
күрмибез януларын...
Күрмибез йөрәк ярасын,
күрмибез аруларын...

Күрәбез бары туктагач,
эзлибез сәбәпләрен.
Күрәбез үткән елларын,
көннәрен, сәгатьләрен...

Гомере буе янган бит,
туктамый, сүнми янган.
...Салкын учакта йөрәкнең
көлләре генә калган...

И йөрәк, фидакарь йөрәк!
Кемнәр сиңа үпкәләр?!
Янар идең тагын шулай,
кабат кабынсаң әгәр!

**4**

Җитмәде барып бу юлы,
чишмәсе акты көтеп.
Чишмә юлында егылды,
йөрәген учлап тотып.

Кешеләр яши торалар,
йөрәкләр яна тора.
Дөньялар кала торалар,
чишмәләр ага тора...

1986

## Көньяк аты

Сабанда күрмәдем мин аны.
Мин аны күрмәдем ярышта.
Очраттым мин аны кайгыда,
очраттым мин аны сагышта.
Каштаннар, кипарис, пальмалар.
Котырган чәчәкләр, яшеллек.
Диңгезгә, тауларга уратып
куйганнар диярсең яшереп.
Тәненә, җанына көч ала,
ял итә кешеләр бу якта.
Бәхетле, сөйкемле, шат монда
кеше дә, җире дә, кояш та.

Күрдем дә мин аны шушында,
шатлыгым, рәхәтем онтылды.
Бүген дә йөрәккә текәлгән:
ул атның күзләре моң тулы.
Җәйләрнең җәннәттәй көнендә
әгәр сез ул якта булсагыз,
күрерсез сез аның күзендә
аяныч язмышка тиң сагыш.
Меңләгән көтүгә кушыгыз.
Әйтегез —
аралап табармын,
бер генә тамга да кирәкми,
мин аны күзеннән танырмын.
Бер генә күрдем мин бу атны.
Күрдем мин бик тирән сагышта.
Дөньяда башка бер ат белән
бутамам мин аны ялгыш та.

Күрә ул диңгезне, тауларны.
Ат бит ул!
Күзендә аның да.
Шул тауда кояшы байганчы
тора ул зәңгәр күл фонында.
Тора ул.
Басмасы таш аның.
Резина — аягы астында.
Хуҗасы бик төгәл,
һәр көнне
иртәдән китереп бастыра.
Куя да ул аны иярләп,
ипләргә оныта йөгәнен.
Хәтерли ат шунда
кайчандыр
тауларда иректә йөргәнен.

Атлыгып-атлыгып йөгергән
чаклары бар иде таңнарда.
Тояклар тавышын тарлавык
гөрелдәп таратты тауларда.
Көтүләр зур иде.
Хуҗасы
эшендә аңа нык ышанды.
Акыллы ат иде.
Шуңадыр
аяклар белмәде тышауны.
Чапты ул таулардан тауларга,
хуҗасы тезгенне алуга.
Рәхәте бар иде яшәүнең
чабуда, аруда-талуда.

Китсеннәр иде бер атланып,
хәзер дә тышау юк...
Тышау ни?
Җиксеннәр иде бер арбага...
Көн буе тора ул кымшанмый.
«Молодец! — ди аңа кич белән
хуҗасы (яңасы), канәгать. —
Эш бетте бүгенгә.

Иртәгә...»
Иртәгә тагын шул галәмәт.
Аңлый ул:
үтәлде кичә дә,
бүген дә планы үтәлгән.
Аңлый ул:
бу хәле — гомерлек,
котылу юк аңа бу хәлдән.
Көнкүреш хезмәте күрсәтә.
Кыйммәтле инвентарь санала.
Атка ни?
Табышы мул аның.
Анысын хуҗалар санаган.
Беркемгә аерып карамый,
мөлдерәп тауларга карый ул.
Беркемне инде ул аңламый,
үзенең язмышын аңлый ул.

Егет бу!
Айкаган, дисеннәр,
тауларны аргамак атларда!
Егет бу!
Ул әнә атка да
бер генә сикереп атлана.
Атлана —
куялар күтәреп
атасы, анасы ияргә.
Иңенә салалар шәп бурка,
папаха — башына кияргә.
Билләре сыгыла буркадан,
аяклар эзлиләр өзәңге...
Ябышкан дерелдәп ялына...
Шул менә үзәкне өзгәне!
Куялар «егетне» турайтып.
Кыяфәт!
Кыяфәт кирәк бит!
Чын атка атланган егетләр,
булса да, хәзер бик сирәк бит.
Нигә дип бу кадәр көләләр?!
Ат бит ул!
Түгел лә агач ат!
...Кесәдә — истәлек фотосы,
күңелдә җәрәхәт калачак.
Зәңгәр күл фонында төшәләр,
чиратлап-чиратлап атланып.
«Черт» итә аппарат.
Хуҗасы
күз кыса атына, шатланып.
Кирәкми өзәңге, тезген дә.
Буркасы,
папаха,
ат булсын!
Кирәкми, атым, син үзең дә,
бары тик төшүе хак булсын.
Төшәләр кызыйлар, малайлар —
атларны күрмәгән балалар.
Төшәләр,
атларны белеп тә,
белмәгән аталар, аналар.

Малай чак бездә дә булды ул.
Мин дә бит атларга атландым.
Бүген дә төшләргә керәләр,
йөрәктән китмиләр атларым.
Бездә юк бурка да,ияр дә.
Чаптык без ат белән берегеп.
Ат — безне,
без атны аңладык,
чөнки без ат белән бер идек.
Бәхетле балалар булганбыз.
Бәхетле икән без бүген дә.
Яшьтән үк күңелгә ат кергән,
ат яши бүген дә күңелдә.
Бу нинди малайлар?
Ат күреп,
шул атның күзенә карамый...
Бу нинди малайлар?
Шул атның
ялларын сыйпамый, тарамый...
Кая соң малайлар күңеле?
Ат бит бу!
Түгел лә агач ат!
...Бүгенге малайлар күңеле
гомергә атларсыз калачак.

Көн саен куялар бу атны.
Куялар иярләп, йөгәнләп.
Көн саен ясала фотолар,
ясала унарлап, йөзәрләп.
Ялларын, көннәрен уздырып,
кешеләр әйләнеп кайталар.
Җир буйлап,
ил буйлап тарала,
дөньяга тарала фотолар.
Рәсемгә уелып тарала,
тарала атларның сагышы.
Истәлек түгел бу.
Документ.
Фотода — атларның язмышы.
Тарихта урын күп.
Әкренләп
язмышлар тарихка калалар.
Аты да кызганыч күңелгә,
кызганыч бигрәк тә малайлар.
Атларның тарихын язабыз
шушылай рәсемгә төшереп.
Үзенең тарихын тарихка
язадыр шушылай кешелек.

Бер генә күрдем мин бу атны.
Күрдем мин бик тирән сагышта.
Дөньяда башка бер ат белән
бутамам мин аны ялгыш та.
Күрдем мин ул атның күзләрен,
дөньяга әрнүле карашын.
Тойдым күк мин аның җанында
төзәлмәс җәрәхәт ярасын.
Тора ул,
кайчан кич җитәр, дип.

Тора ул көн буе сызланып.
Киттем мин зәңгәр күл яныннан
атны һәм...
Кешене кызганып.

Абхазия. 1985

## Бер күкләргә менеп...

Актарабыз Җирне иңләп-буйлап.
Туендыра безне,
яшәтә.
Тик ярата белмибездер кебек
Җиребезне,
күпме яшәп тә.
Казынабыз.
Эзли,
таба кеше.
Нәрсәсе бар —
барысын алабыз.
Шартлатабыз,
агулыйбыз аны —
сабыр итә безнең анабыз.
Ни хикмәттер:
гомере буе көтә,
таләп итә кеше анадан.
...Йолдызларга карап сокланабыз,
бармы безнең Җиргә караган?
Карыйбызмы бала күзе белән,
гаҗәпләнеп,
сөенеп,
куанып?
Шатланамы күңел,
иртәләрдә
иминлеген тоеп уянып?
Карыйбызмы олы хөрмәт белән
өлкән улы,
җитди ир кебек?
Күрәбезме:
галәм чиксез,
әмма
дөньялар юк бүтән
Җир кебек.
Тыңлыйбызмы чишмә тавышларын?
Ишетәбезме һәрбер инешен?
Тыңлыйбызмы ятып күкрәгенә
Җиребезнең йөрәк тибешен?
Ышанам да,
горурланам да мин:
без баласы Җирнең —
без даһи.
Тик сорарга миңа рөхсәт ит син:
күрәбезме —
Җиребез илаһи?!

Өстәлемдә минем ике рәсем.
Җиребезнең ике кешесе.
Якын миңа үзем белгәннәрдән
кешеләрнең шушы икесе.
Бер туфракта,

бергә тумаганнар.
Берсен-берсе алар күрмәгән.
Уртак юллар,
уртак уйлар белән
бергә яшәп,
бергә үлмәгән.
Бер-беренә алар охшамаган.
Тик шулай да
рәттән торырлык.
Берләштерә шушы ике ирне
яшәештә булган тугрылык.
Нигә алар тора өстәлемдә?
Табынырга мөмкин күпләргә.
...Гашыйк иде алар
туган Җиргә,
йолдызларга,
Айга,
Күкләргә!
Моңга баткан Такташ...
Гагаринның
хыял белән тулы карашы...
Бу күзләргә,
күңелләргә сыйган
Җирләр белән Күкләр арасы!
...Аланнарга чыккан урман кызы,
толымнарын җилләр тарата...
Күрә алды Җирнең матурлыгын
агач башларыннан карап та.
Сөеп йөрде мәче балаларын,
кеше-кара күрер димәде.
Җиребездә туып үскән кызны
фәрештәгә генә тиңләде.
Яратмаганнарны
Җирдән сөрде —
җансызларга урын калмады.
Үзе Җирне артык яраттымы —
дөрләп алды,
яши алмады...
Кышка керсәм,
эзен табармын күк
Казан урамнары карында.
...Күпме карлар явып эреп бетте
Такташларның җылы җанында.
Маяклары калды...
Кышкы юллар...
Чаналарга ятып китәм мин...
Такташ белән таңнар аттырам да,
Айга кадәр менеп җитәм мин.
Җиребезне күрәм...
Әүхәдине...
Этләрен дә күрәм...
Казларын...
...Усак яфраклары лебердәшә —
Такташ моңы кайта язларын.
...Ай сокланып йөри Җиргә карап,
китмәс иде таңнар атмаса...
Мин дә гашыйк Җиргә.
Моның белән
бурычлы мин аңа —
Такташка.

Шигыре белән алып менде мине —
Айлар ерак иде ул чакта...
Айга басып,
Җиргә карап тордык,
чабаталы малай булсак та.

Гагаринда гына бу елмаю.
Сабыйларда гына.
Балада.
Ул булырга мөмкин
яңа гына
бала тапкан япь-яшь анада.
Гашыйкларда.
Йөзгә чыга икән
олы мәхәббәтләр ургылып.
Шатлыкларың әгәр чиксез булса,
күзләреңдә тора нур булып.
Ничек итеп җаның җилкенмәсен
Җиребезне урап үткәндә?!
Елмаюы,
Җиргә караулары
йолдыз булып янды Күкләрдә.
Күрде Җирне.
Карап туя алмады.
Йөзә Җире —
зәңгәр,
түгәрәк...
Ул елмаеп төште:
галәмендә
Җире аның
зәңгәр күбәләк.
Мәхәббәте артты,
горурлыгы.
Күкләренә менеп күрде дә,
горурлану хисе белән бергә
борчылу да туды күңелдә.
Җире ялгыз,
без уйлаган кебек
ЗУР да түгел икән Җир шары.
Караганда күктән
бу җиһанның
бер ноктасы икән ул бары.
Хозурлану,
сокланулар гына,
яратулар гына аз икән...
Мәхәббәтле бердәнбер Җиреңне
саклау икән —
синең вазифаң!
Гомерлеккә сеңде йөрәгенә.
Гомерләре генә аз булды...
Елмаюы калды.
Үзен бездән
алып китте Киек Каз Юлы...

Такташ күзе белән карап булмас.
Гагарин күк күрә алмамдыр.
Үз күгемнән
үзем карыйм әле —
күрәселәр бардыр,

алдадыр...
Җиребезнең гомере ике түгел.
Бер булып та,
безгә бәйләнгән.
Эленеп тора кылда,
шуны тотып
Кояш тирәсендә әйләнәм.
Карау кирәк.
Күрү кирәк
Җирне
югарырак менеп,
яратып...
Безнең бәя сукыр тиен булыр,
яшәмәсәк
Җир! дип җан атып!
Курыкмагыз,
Җирдән аерылып
ерагаер диеп арабыз...
Һәркемнең дә үзенең күге бардыр...
Бер күкләргә менеп карагыз!

1986

# «ГОМЕРЕМ ДУЛКЫННАРЫ» китабыннан (1966 — 1988)

# VII

*Дугаларга җитеп дулкын уйный.*
*Тургай тора таңнар атуга.*
*Сөендереп,*
*куандырып,*
*җәйнең*
ак моңнары туа басуда.

## Сандугачлы өч таң

Талчыкты җан.
Әлсерәде күңел...
Ишетелми йөрәк тибеше.
Күз алдыма килеп басты кинәт
тугайлары,
яры,
инеше...
Мин өч көнгә чыгып киттем өйдән, —
мин өч көнгә азат,
өч төнгә.
...Баш астымда минем яшел тугай,
август күге минем өстемдә.
Бер өн дә юк.
Яр буенда ялгыз.
Таң аттырам карап күкләргә.
Йолдызлары коелып төшәр кебек,
житешә алмам кебек чүпләргә.
Менә җитте таңның шул минуты...
Сандугачлар инде уяна.
(Хәтерлибез әле таллар барын,

сандугачлар барын дөньяда.)
Сүнде йолдыз.
Тынды суда балык.
Тик сандугач калды талында.
Колагыма,
йөрәгемә түгел,
керәдер бу моңнар каныма.
Уянды җан.
Иләсләнде күңел.
Ишетелә йөрәк тибеше.
Мин терелдем каты авырудан, —
шушы дару гына килеште.
Бу таңнарга
җаннар ничек бәйле —
аңлый алган әле кем аны?!
Бәхет икән —
сандугачлы булса
гомереңнең әгәр өч таңы!

1988

***

Агым сулар ага.
Карап торам ярдан.
Су буйларын — камыш,
мине сагыш сарган.

Елга борылмалы.
Бәрелеп-сугылып ага.
Язмышлары шулай —
ярдан ярга кага.

Китә алмый ярлар.
Туктый алмый су да.
Агымсулар моңлы
әллә инде шуңа?

Агар яңа сулар...
Үтәр көннәр, айлар...
Басып торыр һаман,
һаман шушы ярлар.

1988

## Илһам Шакировның юбилей концерты

Сүзләре дә шул ук,
көйләр дә шул,
шул ук Илһам җырлый онытылып;
дөньяларны кабат хәтерләтеп,
дөньяларны кабат оныттырып.
Шул ук халык тыңлый,
бер тапкыр да
ишетмәгән кебек,
ләззәтләнеп, —

бер тапкыр да аны күрмәгән күк,
Илһамына карый гаҗәпләнеп.
Әйтерсең лә
яңа гына чыккан
сәхнәләргә,
бер дә көтмәгәндә;
әйтерсең лә
җырлап килә-килә,
бу гомерләр бер дә үтмәгән дә.
Җырлап кына үтми шул гомерләр...
Кай тарафтан күпме җилләр искән...
Җырчы гына түгел,
җырчыларның
җырлары да үзгәрәләр икән.
Вакыт бара һаман,
гомер бара;
җил дөрләтеп тора —
йөрәк яна.
Тыңлый халык:
Илһамы да шул ук,
җырлары да шул ук —
моңнар яңа!

1985

## Сары моң

Бу елның да инде көзе җитте.
Еллар быел, шөкер, килеште.
Тагын бер кат кеше
яшәвенең
максатына җитте, иреште.
Бәрәкәтле көзнең шаһитлары —
басуларда калды камыллар.
(Җирнең өсте ачык калыр иде,
әле ярый җыеп алмыйлар.)
Еллар үзгә.
Басулар да үзгә.
Аларга да яңа сүз кирә.
Язлар, көзләр көтеп яши-яши
туфрагына кадәр искерә.
Көзләр булып шулай еллар үтә.
Көзләр булып чорлар үтәләр.
...Күз алдыма кабат килде әле
тәгәрәшеп яткан көлтәләр.
Онытылды учма,
көлтә сүзе;
онытылды бәбкә,
зуратлар...
Өлкәннәрнең генә хәтереннән
китә алмый үтмәс ураклар.
Онытылсын!
Яңа сүзләр керсен.
Яңа кеше сөрсен кырларны.
Бернәрсә дә ләкин алыштырмас
басуларда туган моңнарны.
Мәңгелектер алар!
Бу кырларга
килеп китәр бик күп буыннар.
Басуларда иген үскән чакта,
үзгәрмәсләр бары бу моңнар.

Күргән кеше.
Күрә һәр ел саен.
Моңсыз көннәр бер дә юк анда.
Өмет булып яшел моңнар туа
җирдә яңа икмәк туганда.
Дугаларга җитеп дулкын уйный.
Тургай тора таңнар атуга.
Сөендереп,
куандырып,
җәйнең
ак моңнары туа басуда.
Басуларның моңы булган чакта
мәгънәләре кими сүзләрнең.
Башакларга җирнең сүле тула,
үз моңнары туа көзләрнең.
...Илаһи чак!
Асыл көзе җитте
кырларымның,
туган ягымның!
...Көлтәләрен җыеп алып кайттык,
басуларда калды сары моң.

1987

## Зираттан чыккач

Тыныч кына үтеп китә алмыйм,
зират яннарында тукталам.
...Кечкенәдән башын иеп үсте
зиратларга шушы шук балаң.
Чәчәген дә өзә алмый идек,
ашамадык өзеп шомыртын.
Тынычызны кысып карап йөрдек
бабаларыбызның бу йортын.
Йөз яшәгән ялгыз имәненә,
кошларына аның тимәдек;
карт козгынның тавышын тыңлап яттык
сәерсенеп,
шүрләп,
имәнеп...
Усал идек.
Ләкин гөнаһ иде
бозулары зират кануным.
Аңлаганбыз шулчак ни икәнен
тәмугларга кереп януның.

Мин хәзер дә зиратларга керәм.
(Күңел китә кайчак тулып та.)
Көз көннәре монда бик ямансу, —
кирәк безгә ямансулык та.
Инде күптән ачканым юк иде
шәһәремнең зират капкасын, —
килде әле бүген
бу мәңгелек
дөньяны да урап кайтасым.
Баш киемен салып кына керәм,
башны иеп кенә керәм мин...
Монда
безгә гомер биргәннәрнең
ятканлыгын яхшы беләм мин.
Барысы да исән.

Картаймыйлар.
Үтми монда Вакыт.
Туктаган.
...Шулай дим дә
берни аңламыйча
гаҗәпләнеп кинәт тукталам.
Ыгы-зыгы килә нинди халык?
Кемнәр монда болай чуала?
Кабер артларыннан берәм-берәм
кесәләрен тотып чыгалар.
Сумкасыннан алып биреп тора
утырган да берәү җай гына;
кесәсенә тыгып китә тора —
ике бәя түләп ал гына.
Спекулянт монда урын тапкан,
хезмәт итә аңа кабер дә...
Кибетләрне бикләп,
зиратларны
ачканбыз бит бүген хәмергә!
Мондый хәлгә нинди сүз табасың?
Ничек итеп моны аңларга?
Кабердәге җаннар...
Ничек итеп
аңлатырга моны аларга?!

Зират капкалары биктә түгел,
ләкин аны кеше саклаган.
Сыерына салам ашатса да,
зиратында печән чапмаган.
Пычрак аяк белән,
кул юмыйча,
тәһарәтсез кеше кермәгән.
Сүгенү кая!
Кычкырып та кеше
сөйләшмәгән монда,
көлмәгән.
Зират капкалары биктә түгел...
Ул безнең дә соңгы йортыбыз.
Ата-баба сүзе кала килә:
зиратларны чиста тотыгыз!
Чиста тоткан.
Үзенең өендә дә
булмагандыр андый чисталык.
Зиратына барса,
рухы,
җаны
кайта торган булган чистарып.

Кешенекен кеше алмый монда,
һәркем белә үзенең чиратын.
Ул кешене
кеше диеп булмый,
мәсхәрәли икән зиратын.
Зиратларга качып яшәмиләр,
тормышы бар аның үзенең.
Инде күптән киткән буынның да
сыныйбызмы әллә түземен?
Була алыр кеше хәмерсез дә,
була алмас ләкин кабeрсез.
Үлгәннәрне әйтмим,

исәннәре,
исәннәре никтер кадерсез!..
Мокытлыкмы?
Зиратларга кереп
без кемнәрдән бүген көләбез?
Исән килеш,
тере килеш шулай
каберләрдә утырып үләбез!
Хәмернең дә үз урыны бардыр,
зиратларга күчү хатадыр.
Бабакайлар:
«И оланнар»,— диеп,
каберләрдә рәнҗеп ятадыр.

Инде күптән кергәнем юк иде...
Онытмыйлар алай,
кереп чык.
Үлгәннәр дә көтә тереләрне;
күзләр җитте,
хәлен белеп чык.
Ямансулык кайчак кирәк безгә, —
күз күннәре монда ямансу.
...Дөньялар да яши,
зират исән,
күктә — болыт,
җирдә ага су.
Чистарынып,
сабырлыклар алып,
тынычланып чыгам зираттан.
Әйтерсең лә
илләр, җирләр гизеп,
мин әйләнеп кайтам ерактан.

## Исемнәр хакында

Кешеләрнең яхшы гадәте бар —
исем кушу туган балага.
Әйбәтен куш!
Җанга якынын куш!
Кемнән туганына карама.

Исемнәрнең мәгънәләре тирән:
иркә,
назлы,
хисле,
матурлар.
Ир-атларның асыл сыйфатлары:
гадел,
тугры,
зирәк,
батырлар.

Шулай кирәк.
Исемнәрдә — өмет.
Кеше бит ул.
Әле өр-яңа.
Исем белән төшсен бишегеннән,
өмет белән керсен дөньяга.

Ә шулай да...

әйбәт булыр иде
дөнья аны таный башлагач,
өр-яңадан исем кушып булса,
кем икәнен яшәп раслагач.

1988

## Күке тавышын ишеткәч

Күке!
Гомерем күпме...
азмы?
Ничә язны
каршылармын?
Ничә тапкыр күрер күзләр
кар сулары ярсыганын?

Гомер бара.
Әйтеп кара,
күке.
...Ун кычкырды миңа бабаң.
Атаң биргән
тугыз ел да
юлда,
мин дә юлда һаман.

Дәшү сиңа
болай гына...
Йөрмим гомер сорап.
Ә шулай да
кычкыр әле,
күке,
тагын гомер юрап.

1968

***

Мин йокыдан әллә уяндыммы?
Ни кузгатты әле уйларымны?
Кемнәр йоклый? Кемнәр уйга талган?
Нигә дөнья болай тынып калган?

Үзәннәрне баскан тын моңсулык.
Йөрәкләрне кыса ямансулык.
Мескенлек бар урман шаулавында.
Ник күренми бөркет тауларында?

Баскан идем менеп кыясына,
җылыныр дип җаным кояшында.
Кояшларын каплап тора болыт, —
явар кебек өскә кар-боз булып.

Бетми торган нинди сабырлык бу?
Җилкәләрдә нинди авырлык бу?
Кайчан да бер төшеп калыр микән?
Йә гомергә шулай барыр микән?

Әйтерсең лә тоташ тере яра —
күккә ашып анда нәрсә яна?
Күтәрелеп офыкларга кара:
офыкларда кояш баеп бара...

Офыкларда кояш баеп бара...

## Урман күгәрчене

Нинди тавыш?
Нинди кош соң? дисәм,
бу бит минем иске танышым.
Бу арада ишетеп уянам мин
урман күгәрчене тавышын.
Үзен күрми тыңлый идек аны,
тыныбызны кысып,
куркышып...
Күңелләргә борчу сала иде
урманнарның моңлы бу кошы.
Күңел әле һаман саклый килә
урманнарның серле шомнарын.
Бала чакта аңламаган шул без
урман күгәрчене моңнарын.
...Бакчаларга кереп адашканмы?
Китәр юлын тапмый, күрәсең.
Бер агачта һәр көн
таң атканда
өзгәләнә шушы күгәрчен.
Көтеп алам.
Гел моңаеп тыңлыйм.
Бу моңнарны инде аңлыйм мин.
Үзем аңлыйм,
үзем аның нигә
моңайганын әйтә алмыйм мин.

1987

## Халыкара кыргый хайваннар

Иркен, дисәк, безнең Җиребез,
чиксез, дисәк, безнең Җиребез,
әйтер кебек торып табигать:
хайваннарга ирек бирегез!

Бер баласы булып бу Җирнең
күреп тору шуны бик читен:
ямаулыклар белән ямыйбыз,
җәрәхәтлибез дә Җир битен.

Халыкара аукционда
кыргый атлар әле сатмыйбыз.
Хайваннарны бүген кешедән
зоналарга бикләп саклыйбыз.

Яшәү урыннары билгеле,
һәркайсына тамга уелган.
Халык санын алган шикелле,
берәм-берәм барлап куелган.

Фәлән җирнең фәлән төшендә
фәлән кадәр әле калганнар.
...Иялəшə безнең тормышка
халыкара кыргый хайваннар.

1988

## И Табигать

Аягына басты,
таянды да олы күсәгенә.
Бәхетле ул: туры килгән икән
Җирнең үзәгенә.

Аякларда көч җитәрлек иде,
таза ике беләк.
Беренче кат кизәнде ул шунда,
Җиргә аяк терәп.

Бик аз гына кирәк иде башта:
тамак, өскә генә.
Табигатьнең мескен бер үгезен
җиңде көчкә генә.

Көрәште ул шушы көннән башлап
олы түзем белән.
Табигатьне җиңү ансат түгел —
моны үзе белә.

Яшәү өчен көрәш, тартыш белән
инде чорлар үтте.
Көче белән Җирдә бөтенесен
Кеше узып китте.

Кием алды, җылы алды Кеше,
торак, азык алды...
Өстендәге генә җитми, диде, —
Җирне казып алды.

Тимерен дә алды, бакырын да,
алды алтынын да.
Кирәк кадәр алды, тапкан кадәр,
алды артыгын да.

Атомын да алды. Бүген инде
җитә аның көче
Табигатьне, Җирне, үзен — бергә
күккә чөяр өчен.

Үзгәртә ул Җирне. Киртәләр юк
бүген аңа юлда.
Берәү түгел, унар күсәк бүген
аның һәрбер кулда.

Бер үгезне түгел, мең үгезне
бер сугуда ега.
Диңгезләре, далалары белән
кеше яуга чыга.

Хезмәт итә аңа Җир дә, Күк тә,
ут та, су да, таш та...

Миллиард еллар җыйган
акыл кайный
бүген шушы башта.

Куәт тә күп, акылы да җитә,
аңа бар да ансат.
Болыннарның чык тамчысын җыеп
куя сазлык ясап.

Юллар сала тау-ташларны,
мәрмәрләрне ишеп.
Киңәйтәбез «чәчү мәйданнарын»,
каеннарны кисеп.

Туймый нәфес.
Һаман кирәк безгә —
гомер буе алу.
Рәхмәт әйтеп, кайтарабыз кире
төтен, пычрак, агу.

Нык ябышты синең күкрәгеңә
Кеше дигән балаң.
Вакыт үткән саен тирәнәя
җәрәхәтең-яраң.

Кодрәте зур. Куәте күп бүген.
Кеше — бөек, зирәк...
И Табигать!
Барысын да алдык,
инде җаның кирәк!

***

Үзәкләрең өзелеп төшәр чакта
чакыра алсаң икән: «Кил!» — диеп.
Килсеннәр дә елмайсыннар иде:
«Килдем бит мин,
менә мин»,— диеп.

Кирәк икән без дә дөньяда, дип,
бер куансаң иде шул чакта.
Бездән бәхет китә алмас иде
нинди генә хәлдә булсак та...

1985

## Бер тау янында

Мин беренче тапкыр карап торам, —
күргәнем юк иде бу тауны.
Бу тау мине авыр хискә салды,
әллә нишләп уйлар буталды.
Гел ташлардан тора бу тау тоташ;
ташлар шәрә,
ташлар ялангач.
...Мин үземне бик бәләкәй сизәм,
зур тауларга килеп карагач.

Орчык кадәр булып күренеп тора
ялгыз нарат тауның башында.
Хәтерләтеп никтер күз яшьләрен
тамчы тама һәрбер ташыннан.
Миллион тамчы сарган тауның битен;
өзелә тамчы —
шуны күзәтәм.
Сыкрап-саркып чыга микән сулар
йөрәгеннән тауның,
үзәктән?
Ала алмыйм күзне:
әллә инде
үз ташларын үзе тау сыный.
Бар җир яшел,
көлеп тора көннәр,
ә таш җылый...
Шәрә тау җылый...

1989

## Абага чәчәге

Бик таныш та,
бик якын да күптән,
бик кадерле миңа бу урман.
Балачагым минем!
Синең дөньяң
нинди хозур,
нинди зур булган!
Бик ышанып көткән чаклар булган
чәчәк атар диеп абага.
Балачак та үткән...
Картлык көтә.
Ә абага тора арада.
Андыйларга күңел бик хәтерле:
бу урман да исән, —
бар анда.
Үтә кебек минем гомер һаман
абагалар тулы аланда.
Мин хәзер дә көтәм:
менә-менә
чәчәк атар кебек тоела.
Тик өлгерми кала абагалар:
көзләр җитә,
яфрак коела.

1988

## Кәкре нарат

Шаулап торган урман иде монда,
матур булып үсте наратлар.
Күккә карап үскәнгәдер,
Ходай
наратларны зифа яраткан.

Һәркемнең дә була бер гомере.
Наратның да була гомере.
Бүрәнәләр булып ятты алар.
Учакларда сүнде күмере...

Кисте кеше.
Кискән саен аңа
кирәк булды
төзе,
сөлеге;
төпләрендә тамып-тамып калды
ауган наратларның җелеге.

Тик бер нарат,
кәкре нарат калды,
берәүгә дә кирәк булмады.
Сөендеме,
әллә гарьләндеме? —
Бөгелеп-бөгелеп нарат елады.

1988

## Каф тавы

Кичләр буе әкият укый-укый,
төннәр буе яттык саташып.
Каф таулары тарлавыкларында
диюләрдән качып,
адашып
күпме йөрдек!
Ул диюләр безнең
ничә кызны тотып ашады!
Шул кызларны коткарабыз диеп,
ничәбезнең бетте башлары!
Аждаһалар...
Дию пәриләре...
Каф таулары ерак дөньяның...
Шул диюләр йота дигән чакта
ничә тапкыр сикереп уяндым!
Булмаган ул дию пәриләре,
булмаган ул андый таулар да.
Юкка гына булган «кан коюлар»
аждаһалар белән яуларда.
Ә шулай да
гомер итүләре
күңеллерәк икән алданып.
Әкиятләр әкият булып калыр,
без дөньяны инде аңладык.
Каф тауларын үтеп йөрисе юк,
эзлисе юк җенле җирләрне.

Үзебездә икән диюләре,
үзебездә икән җеннәре!

1988

## Үзебез турында

Яратмаган безне тигез итеп,
яратмаган безне тиң итеп;
бирелгәне яки бераз артык,
йә бирелгән бераз ким итеп.

Мин үземне синдә таба алмам,
син үзеңне миндә тапмассың.
Кереп кара,

әгәр керә алсаң,
ачып куям күңлем капкасын.

Син йөрерсең анның тирәсендә,
үталмассың ачык булса да.
Сак астында һаман
синдә, миндә —
ике җанда ике бусага.

Беләбез дә,
күрәбез дә кебек
без кешене гүя таныйбыз.
Җаннарына аның
үз күзебез,
үз җаныбыз аша карыйбыз.

Кем танысын?
Кем аңласын сине?
Таный алмас хәтта үз анаң.
...Игез бала көн дә туа тора,
игез җаннар әле тумаган.

## Сөяркәләр

Гафу итә-итә яшәп була:
хатын — ирне,
ире — хатынын.
Гафу итегез, дип китеп бара
мәхәббәтләренең актыгы.

Сөяркәләр белми хыянәтне, —
сөюләре аннан югары;
аталадыр шулай кешеләрнең
хыянәтсез сөя торганы.

Загсларда язып бирелмәгән
бурычларын тагып муенга.
Сөяркәләр алар җанда була,
сөяркәләр була куенда.

Ул хатын да түгел,
ир дә түгел,
яратылган бит ул сөяргә.
Барына да түзәр!
Хыянәтне
гафу итә алмас сөяркә!

## Балдыз йоклый

Ята йоклап, онытылып:
эштән арып кайткандыр.
Елмаеп куя: төшендә
мине күреп ятадыр.

«Апай!» диеп, Җизнәй!» диеп,
төшендә дә интегә.
...Тартып куегыз пәрдәне —
кояш төшә битенә.

Хатын исән, балдыз исән —

куана минем ише.
Барыбер бәхетлерәк ул
балдызлы булган кеше.

Хатының мырлаган чакта,
балдызың гаделлерәк.
Балдыз ул синең таяныч,
балдыз ул кадерлерәк!

Тыныч кына йокла, балдыз,
авыр уйлар уйлама.
Мине төшләреңдә күреп
йокла, балдыз, уянма.

Көндез йокыларың тәмле.
Төнлә йокы кала ул.
Йокла, балдыз, хафаланма —
җизнәң тора каравыл.

1992

## Җылы яктан язган хат

Көннәр якты.
Күкләр якты монда.
Төннәрен дә күгем йолдызлы.
...Йолдызлар да кайчак юаталар
минем кебек япа-ялгызны.

Көннәр җылы һаман бу якларда.
Күңелем дә җылы шуңадыр.
Йөрәк бит ул кеше суынса да,
көннәр суынса да туңадыр.

Яфрак әле монда һаман яшел.
Саргайдымы безнең якларда?
Яшел хатлар язып салам сиңа, —
саргаймасын иде хатлар да.

Табигатьнең үзе кебек монда, —
көләч көннәр кебек шат халык.
...Ятам әле мин дә
күкләр,
җирләр,
кояш исәнлеккә шатланып.

1988

## Орган залында

Уе-гаме әле бар вакытта,
исән чакта хәсрәт-кайгысы,
тумышыннан килгән моңнарына
була алмас кеше ваемсыз.

Тальяннарда безнең үз моңыбыз.
Таныш моңнар яши курайда.
Кубызлары,
думбралары якын,
бертуганнар уйный сорнайда.

Бу кемнеке?
Орган залларына
тыннарымны кысып керәм мин.
Бу кемнәрнең сулышлары икән,
җан авазы икән кемнәрнең?

Гасырларның бәгырь төпләреннән
ишетелә кебек бу аваз.
...Күңелләргә күзләр кереп тула,
күңелләргә кереп тула яз.

Авыруга сихәт булып керер.
Үләр җирдән кабат яшәтер.
Җирнең генә моңы түгелдер бу,
безгә шулай күкләр дәшәдер.

Бар халыкның җанын ничек итеп
тетрәндерә икән бу кадәр?!
Үткәннәрдән,
киләчәктәндер бу... —
мәңгелектәндер бу моң-хәбәр!

1988

## Иман

Яшәмәгән кеше ялгышмый, ди.
Бик уңайлы,
җайлы әйтелгән.
...Яши-яши туган ул ялгышлар
озак чыкмас әле хәтердән.
Онытылмас аның корбаннары.
Ялгышырбыз тагын...
онытсак.
Әрни күңел
(тик торганда түгел),
шушы ялгышларга орынсак.
Нишләтәсең хәзер
ялгышларның
төзәтеп тә булмый торганын?!
Без
«ялгышлык корбаннары» дибез.
Бу —
имансыз җаннар корбаны!
Ялгышуга сылтау кыен түгел,
ялгышу да җиңел, бик ансат.
Ялгышмыйча яшәү кирәк безгә, —
яшәргә дип әгәр уйласак.
Мин ышанмыйм —
ялгыш арты ялгыш,
төзәткән саен төзәтү булганда.
Гел ялгышып,
гел төзәтеп кенә
яшәп булмый газиз дөньяда.
Ялгышмый ул кеше,
дөрес эше,
дөрес уе алда барында.
Ялгышмый ул,
кырык төрле түгел,
бер иманы булса җанында.

Шәхес,
җәмгыятьнең исәнлеге —
бер вакланмый торган иманнан.
Кешеләрнең Кеше икәненә
иманына карап инанам.
Вакландымы иман?
Качты мәллә?
Кеше җанын кыйнап канаттык.
...Ул иманга ышануы кыен, —
һәр көн саен торсаң яңартып!

***

Яратуның күзе сукыр, диләр.
Хаклык була халык сүзендә.
Кемнәр белсен аны?!
Аңлап булмый
мәхәббәтнең әле үзен дә.

Күреп киләме ул?
Күрмиме ул?
Күрәбезме әллә аны без?
Шуны гына беләм:
ул кагылса,
өр-яңадан туа җаныбыз.

Йөрәкләргә юллар бик әйләнеч...—
ә ярату туры юл таба.
Мәхәббәтем икән —
килсен әйдә!
Ярар миңа сукыр булса да.

1987

## Риза түгел

Кабиләсе инде үлеп беткән.
Иле-җире,
халкы югалган.
Шуны гына раслар өчен җирдә,
шаһит булып кына...
ул калган.
Чукрак-телсез итеп карый аңа
бу илдәге халык күптәннән.
Башка телне белми,
аның телен
белми икән җирдә бүтәннәр.

Сөйләшәсең үзең белән үзең,
сүз кирәкми,
димәк, дәшмисең.
Ишетә торып,
сөйли белә торып,
чукрак-телсез булып яшисең.
Каушадым мин,
өшеде күк җаным,
аңладым да шундый хәл барын.
Йөрәгемә сукты салкын дулкын,

үтеп Австралия ярларын.
Бу яңалык түгел иде, юкса
дөнья баткан күптән бу чиргә.
Азмы халык туып яшәгән дә,
азмы халык киткән бу җирдән?!
Бөек халык һәрчак җиңә килгән,
көчсезләрне көчле бетергән.
Йортын-җирен алган,
мал-мөлкәтен.
Үзен аскан,
аткан —
үтергән.
Хәзер инде бетерү ысуллары
камилрәк,
каннар коелмый.
Эри халык!
Ә үзенә бер дә
бетәр кебек булып тоелмый.
Җиренә дә тими,
алмый йортын,
исән-имин тора малы да.
Бөек халык әкрен генә аның
кереп бара газиз җанына.
Чөнки белә:
тән ярасы бетә,
каны исән булса терелә;
җаны үлсен дисәң,
тәнгә тимә,
богау сал син туган теленә.
Азмы инде телсез халык?!
Җирдә шаһитлары гына калалар.
Азмы инде
ата-ана телен
аңлый алмый торган балалар?!
Яши әле минем халык җирдә,
шаһит булып кына калмадым.
Туган телем исән-сау вакытта
бүтән халык телен аңлармын.
Бетәргә дип түгел,
туган халык
ахыргача бергә барырга.
Беребез дә безнең риза түгел
чукрак-телсез булып калырга!

## Есенинны уйлап

Килми кеше үзе теләп җиргә.
Үзе теләп җирдән китми ул.
...Йә кайталмый,
артык ерак китеп,
йә каядыр барып җитми ул.
Беркайчан да әле булганы юк,
беркемнең юк әле күргәне —
кешеләрнең теләгәнчә яшәп,
теләгәнчә генә үлгәнен.
Дөнья белән килешүе кыен:
сатылырга кирәк,
сатарга...
...Утыз яшьтә телимени кеше
табутларга кереп ятарга?!

Синең кулга кайчак мылтык бирә:
үзеңә-үзең терә көпшәсен!
Мылтык тавышы инде шартлагач та
яшәүләрне әле көтәсең.
Тоттыралар кайчак кулга элмәк,
тик муенга гына такмыйлар.
Дөньялардан киткәч,
үзен-үзе
үтерүче диеп атыйлар.
Горур гына тумаган ул кеше,
үтерергә туган,
үләргә,
яшәү дигән чирдән котылу өчен
үлемнәре белән түләргә.
Яшәү, үлү яңа түгел, диеп
әйтеп киткән идең син кичә...
Ул бүген дә шулай —
яшәү, үлү...
Үтерүләр дә шулай —
искечә!

1988

***

Мин генәме әллә фани җирдә?
Әллә син дә бармы?
Булсаң әгәр, бу фәкыйрең сине
эзләп бер табармы?

Яши миндә сиңа дигән бер сүз.
Инде күптән яши.
Таныр иде йөрәк, таныр иде...
Йөрәк һаман дәшми.

Сүзем сиңа кайчан булса да бер
барып җитәр микән?
Әйтелмичә шулай үзем белән
бергә китәр микән?

Ялгыз мәллә мин бу фани җирдә?
Бармы әллә син дә?
Әгәр булсаң, сиңа гына дигән
бер сүз яши миндә.

1988

## Коммунистлар баш төзәтә

*Партиянең булды членнары:*
*эшчеләре булды,*
*эшлеләре —*
*гомерләрен илгә багышлаган*
*игелекле хезмәт кешеләре.*
*Алданганнар булды...*
*Кызыкканы...*
*Ялган булды шуңа эше, уе.*
*Күпме ялган чәчеп,*

*ялган җыеп*
*яшәделәр алар гомер буе?!*
*Күп очраттым мин аларны үзем.*
*Алар хакындадыр фәкать сүзем.*

Ерак юлдан кайтып килешләре:
фидакарьләр —
бик күп эшләгәннәр.
Куәт-кодрәт беткән,
хәлләр киткән —
коммунистлар каты өшәнгәннәр.
Ал комачка язган сүзләр уңган.
Кызыл билет та юк...
Байрак тузган.
Артта юллар ябык,
киләчәккә
поездлары инде күптән узган.
Эре балык белгән,
әзер торган:
җил-давылны сизеп төпкә батты.
Генсек үзе ата фәхеш булган:
партиясен,
юлдашларын сатты.
Хәзер гаҗәп.
Хуплап тыңлаган бит
буш сүзләрен —
үгет-вәгазьләрен.
Кесәсендә бөтереп йөри әле
генсек биргән конфет кәгазьләрен.
Каршылаулар,
озатулар бетте...
Шиңгән кызыл чәчәк букетлары.
Коньяклар да әллә кая китте,
ябык инде райком буфетлары.
Хезмәттән дә бизгән...
Һөнәр дә юк...
Бушка килә торган азык бетте.
Кеше икән ул да:
җиргә төште —
ялган намус,
ялган язык бетте.
Ярамады керү:
абруй бетә —
урап-урап үтә инде читтән.
Әле ярый барлар исән икән —
башлар чатный бүген,
ирен кипкән.
Юлын эзли сыра барларында
кызыл томаннарда адашканы.
Бәргәләнә бүген ярдан ярга
партиянең мәхлук алкашлары.
Юшкын авыр.
Җыелган бит озак
гомере буе ябык күңелендә.
Эретмәкче була бүген аны,
чайкый-чайкый сыра күбегендә.
Кемнәр күрсә:
— Ә, коммунист! — диләр.
Тоз сибәләр һаман ярасына.
Килеп керде сыра барларына —
керде инде халык арасына.

Сыра барларыннан башлый Гитлер...
Монда бүген инде сүнеп ята
Октябрьдә кабынып киткән утлар,
сыра бокалына бата-бата.
Үбешәләр сәрхуш халык белән —
йомшый йөрәк сыра парларында.
Махмырдан соң бүген баш төзәтә
коммунистлар сыра барларында...

1992

***

Минем шатлык белән шатланма син.
Кайгырма син минем кайгыдан.
Йөрәгемә минем керерсең дә
калырсың дип шунда кайгырам.

Андый хәлләр була алмый, димә.
Була гына түгел, бар алар.
Мәхәббәтең булып керәләр дә
яраларың булып калалар.

1987

## Гаеп

Йөри гаеп —
юлын кайчак белә,
кайвакытта алдан белми ул...
Ишегеңне бикләп маташма да,
шакылдатып, сорап керми ул.
Йөри гаеп —
елдан елга күчә,
кешеләрдән күчә кешегә...
Берәүләрдән бик тиз генә китә,
берәүләргә гаеп үчегә.
Гаеплибез.
Безгә ошамаса,
начар эш бу диеп атыйбыз.
Беләбезме,
әллә белмибезме? —
явыз кеше икән шактый без.
Гаепләргә ансат кешеләрне,
яшәү өчен шактый уңай бу.
Үзебезнең башка җитә торган
безнең әшәкелек бугай бу.
Гаеплибез үткәннәре өчен,
гаеплибез бүген кылганга;
гаеплибез йомшак булган өчен,
гаеплибез каты булганга.
Гаепләргә мөмкин күрмәгәнгә
яки белгән,
күргән өчен дә...
Гаепләргә мөмкин икән хәтта
туган өчен,

үлгән өчен дә...
Ул гаепли мине,
ә мин — аны.
Алар безне бүген тетәләр.
И гаделлек!
Иртәгесен безнең
гаепләүне алар көтәләр.
Ияләндек шуңа...
Аннан башка,
ул югалса, бер көн түзмибез.
Бөтен эшне ташлап,
гомер буе
шул гаепне йөгереп эзлибез.
Бик әйтәсе килә:
әгәр сиңа
кирәк булса гаеп тагын да, —
үзеңне-үзең тот та гаеплә бер,
гаеп үзе синдә чагында.
Тик батырлык җитми, —
менә мин дә
гаеп эзлим,
эзлим, «синдә» дип.
Мин гаеплим сезне,
ә шулай да,
ә шулай да...
гаеп миндә бит!

## Бер нөсхәдә

Уйламасын кеше минем кебек.
Яшәмәсен кеше минемчә.
Беркайчан да
беркем
бер эшне дә
башкара алмый икән синеңчә.
Тик үзенчә генә ярата ул,
җырлый,
елый,
дәшми,
көлә ул.
Тик үзенчә генә сөйләшә ул,
тик үзенчә тыңлый белә ул.
Зур ялгышлык булыр
таләп итү
«минем кебек бул» дип
бүтәннән.
(Андый уйлар белән саташалар,
ялгышалар инде күптәннән.)
Кеше берәү,
бер нөсхәдә генә,
кабатлана торган булмаган.
Әле ярый,
берәр ялгыш китеп,
минем кебек берәү тумаган.
Шуны белеп,
тыныч яшәр өчен
каян алыр идем түземне?
Һәр минутта тоеп торыр идем
артык кеше итеп үземне.

## Ашкын ат

Гомерендә чабып күрсәтте ул.
Ашкынып та,
гаярь булып та...
Мәйданнарны уктай тишеп үтте.
Тоталмады кеше куып та.
Түзә алмады өстә җайдак булса,
ачылып киткән чакта канаты.
Ярыш юлларында егылып төшеп,
күпме малай борын канатты!
Ул икенче булып килә алмый,
башкаларда аның эше юк.
Ул беренче килде!
Ялгыз килде!
Җилкәсендә тагын кеше юк.
Һәм салдылар тышау.
Утарында
чабышкылар башка токымнан.
(...Бер уйласаң, әле моңа кадәр
ул коллыктан кемнәр котылган?)
— Йөрәгендә моның.
Җелегендә...
Ашкын атлар алар тик тормас.
Баш бирәчәк түгел, — диде хуҗа, —
бер ычкынса, кабат тоттырмас.
...Болыннар да иркен.
Дөнья да киң.
Сулышлар да күпкә җитәрлек.
Чыклы таңнарында
кешни-кешни
офыкларга чабып китәрлек...
Яратмыйлар ялгыз йөгергәнне.
Яратмыйлар алай узганны.
...Күзгә керә
ярыш чатларында
башкаларның тояк тузаны.
Гомере буе
әле кайчан да бер
чабып китәренә ышанды.
Кага йөрәк һаман...
Аяклары,
аяклары гына тышаулы.

1987

***

Кайнар, диләр.
Кызу канлы, диләр...
Җитеп бетми, диләр, сабырлык.
Ул гаеплемени?
Дөнья эссе,
кабынып китеп йөрәк янарлык.
Тоя тормыш
дөрләп янган чакта
әле синең Җирдә барыңны.
...Кайнар канны суытучы булыр,

кем җылытыр суык каныңны?!

1987

## Бигрәк тә куркам

Яшь вакытта язып куйган идем:
«Без —
курыкмый торган затлардан!»
Бик еракка алып китте гомер
ул
курыкмый торган чаклардан.
Мин хәзер дә алай куркак түгел,
яшибез бит инде күптәннән.
Дошманнардан,
явызлардан түгел,
куркам инде бүген бүтәннән.

Көтелмәгән мәхәббәттән куркам, —
ул килер дә...
сине алдалар.
Ул бит сиңа көтелмәгән димәс,
көткәнең дип килер, —
аңла, бар!
Алданырсың
бик бәхетле булып,
алдым бит, дип, сине бер көтеп...
Килеп керер
гомерең буйларына
көткән мәхәббәтне өркетеп.
Аңлаганда инде
йөрәгеңне
пыскып торган учак итәр ул.
Яннарыңда торып,
гомереңне
ялгызлыкка дучар итәр ул.
Куркып качар көткән мәхәббәтең,
күмелеп калыр инде үткәнгә.
Китеп барыр ул да
көтелмәгән
бер мәхәббәт булып бүтәнгә...

Көтелмәгән дәрәҗәдән куркам...
Карамыйча кылган эшенә,
йә дошманы,
йә дуслары бирә —
кеше бирә аны кешегә.
Йөрерсең син бер ел,
ун ел,
бәлки,
гомер буе шулай зур булып.
Китәрсең син фани дөньялардан
бер эшлексез булып,
хур булып.
Йә дошманың,
йә дусларың
барыбер
синнән аны тартып алачак.
Ялган акча кебек,

синнән бары
ялган гомер генә калачак.
Исән чакта бирми китә калсаң,
кабереңә кереп алалар.
Дөреслеге җитеп бетми икән,
өстәр өчен тагын яла бар.
Гомереңүтәр дәрәҗәңне саклап,
и таушалып бетәр җаннарың.
Килми калыр
сине Кеше итеп
яшәтердәй лаек даннарың.

Көтелмәгән үлемнәрдән куркам...
Кыскара дип куркам
гомерем.
Бернәрсәгә алыштыра алмыйм
гомеремнең хәтта бер көнен!
Кызганычка каршы,
җиңеп булмый
бөтенләй үк әле үлемне.
Берәүдән дә,
хәтта үлемнән дә
алдатасы килми үзеңне.

Күпме генә яшәсәк тә,
дөрес,
чиксез түгел,
барыбер үләсе.
Үләсемне ләкин
азга гына
алдан килә минем беләсем.
Алып китсә мине көтмәгәндә,
өзелеп калса гомер,
киселеп...—
бу тормышның бөтен нигезләре
китәр кебек кинәт ишелеп.
Мин саласы соңгы ташы кала,
миннән башка аны кем салыр?
Кинәт кенә китеп бар да, имеш...
Минем өчен җирдә кем калыр?!
Инде миңа гомер биргән икән,
үлемен дә биргән янына.
Үз үлемем үзем белән минем:
көтелмәгән үлем, кагылма!
Бар үткәнем минем...
Тагын бер кат
ул үтәргә тиеш хәтердән.
Бар беренче сүзем...
Мин бурычлы
соңгысын да аның әйтергә.
Үзе башлап,
үзе бетермәсә,
гамәлләре кешенең бутала.
Яшәвенең мәгънәләре, бәлки,
куелгандыр соңгы ноктага.
Шуңа күрә кирәк үз үлемем,
аның белән килә китәсем.
Бер кеше дә,
инде үзем юкта,
качып китте бит бу, димәсен!

Көтелмәгән хәлләрдән мин куркам...
Алар кемгә бәхет китергән?
Кешеләргә килгән яхшылыклар
һәрвакытта озак көтелгән.
Көтмәгәндә килә илгә афәт,
көтмәгәндә килә сугышлар.
Көтмәгәндә җирдә кеше тумый,
көтмәгәндә өзелә сулышлар.
Көтмәгәне килсә,
кеше инде
көтеп ала алмый көткәнен.
Көтелмәгән хәлләр хәл итәләр
киләчәген,
бүгенен,
үткәнен...
Көтелмәсә инде көтелмәсен,
алданрак та килми хәбәре.
Авызлыклап тотып булсын иде
көтелмәгән шушы хәлләрне!

...Куркакны да,
батырны да беләм:
мәгънәләрен һич тә бутамыйм.
Бернидән дә,
бер дә курыкмаган
кешеләрдән бигрәк куркам мин.

1987

## ***

Моңаеп кына килдеңме?
Моңайтып килдеңме син?
Моңлыга сыена торган
моңлы бер кеше ич мин.

Моңнардан туган кеше мин.
Нинди моң юктыр миндә?
Моң булып килсәң,
күңелгә
сыярсың әле син дә.

1970

## Бер ноктада

Гомерен кеше өчкә бүлеп яши:
киләчәге,
бүгене,
үткәне.
Киләчәктә килер дип ышана
үткәннәрдән үзенең көткәне.
Бүгене белән яши.
Әйтми кеше:
и кызганыч, диеп, киләчәк.
Киләчәктә кемдер:

әрәм булды
үткән гомерләрем, диячәк.
Онытасы килә үткәннәрен —
онытырга кирәк кемгәдер.
Кемнәрнеңдер үткәннәре төшкә
кара кайгы булып керәдер.
Онытып булмый.
Үзенең яшәвенә
була алмас кеше хәтерсез,
хәтеренә әгәр төшми икән,
үткәннәре аның кадерсез.
Гомер бит ул!
Аның мизгеле дә
тоелмыйча үтә бик сирәк.
Үткәннәрен кеше сагынмаса,
үткәннәре аның юк, димәк.
Яше җитә адәм баласының
үзе генә тойган ноктага.
Үткәненә борылып карар өчен
шул ноктада кеше туктала.
...Үткәннәрне бүген искә алдык,
дуслар белән барлап утырдык.
Безнең үткән
калын китап икән,
бик игътибар белән укырлык.
Рәхәт булып китте,
җиңел булып...
Гомеребезне күрдек,
тойдык бер.
Тормыш безне урап үтмәгән дип,
горурланып уйлап куйдык бер.
Киләчәккә карап шәраб салдык —
чыңлап алды кулда тустаган.
Без үткәннәр өчен чәкештердек,
бүгенгесе,
шөкер,
узмаган.
Өчкә бүлә гомерен.
Өчесе дә
кирәк аңа гомер иткәндә.
Яши кеше.
Үзе белән бергә
өчесе дә кала үткәндә.
Үпкәләмәм.
Төгәл түгел, димәм,
бер көн артык,
бер көн ким булса.
Мин бик риза,
минем киләчәгем
үткәнемә әгәр тиң булса!

1987

# «ӘЙТТЕ ШАГЫЙРЬ...» китабыннан
# (1970 — 1993)
# VIII

*Ишетәм мин!*

*Гомер буе безне*
*кем чакыра?*
*Безгә кем дәшә?*
*Бар ул анда,*
*бар ул тере җаннар...*
Күкләр белән күңел сөйләшә!

## Әле ярый

Әле ярый яшьлек кинәт килми,
кинәт китми бездән,
күпсенеп.
Йөрер идең:
белми калдым, диеп,
күрми калдым, диеп,
үкенеп.

Әле ярый кинәт кенә килми,
кинәт кенә килми өлкәнлек.
Сабырлыгы җитә
яшьлекнең дә,
үзенең дә вакытын көтәрлек.

Әле ярый кинәт килми картлык.
Мөмкин хәтта килми калырга.
Әзер булып җитсен кеше, ди ул,
үз картлыгын каршы алырга.

Әле ярый,
әле ярый безгә
кинәт кенә алар килмиләр.
Бөтенесе бергә җыелып килеп:
— Бар гомерең шушы! — димиләр.

Килгән көннәр нидер алып килә.
Киткәннәре алып китәләр.
Бу — яшьлегең,
бусы — картлык, диеп,
безне уйлы-гамьле итәләр.

Вакыт җитә тоеп яшәр өчен
үткәнен дә, киләчәген дә...
Алачагың булса, алып була,
биреп була бирәчәген дә...

Барысы да килә вакытында.
Хода язганнарны күрәбез.
...Гомере дә болай җитә кебек,
тик шулай да
иртә үләбез!

1987

***

Мин икенче кабат яшим бугай:
җире бүтән,
һава,
көн бүтән...
...Мондый түгел иде минем гомер,
бер яшәгән идем мин күптән.

Без үлчибез кеше гомерләрен
әнкәсеннән туган көненнән.
Үлә, диләр, кеше бер мәртәбә,
ничә тапкыр туа —
кем белгән?!

1986

***

Хыялларда туа бөек эшләр —
кодрәт җитә торган.
Йөз елдан соң килеп карасалар,
исең китә торган.

Моңа кадәр беркем табалмаган
мәхәббәтләр туа.
Дөрли-дөрли илһам учагында
кабат яшәп була.

Нәфрәт туа. Гомереңдә тик бер
була икән андый.
Горур башың белән яуга чыксаң,
дошман исән калмый.

Ташланабыз гайрәт-йөрәк белән —
ныклап тотынабыз.
...Картаялар уйлар хыялларда —
бик тиз онытылабыз.

Кызганмаган, нәзек күңел биргән,
биргән сизгер йөрәк.
Кемнәрнедер тояр, назлар өчен
йомшак кул да кирәк.

Тотар өчен үзеңне-үзең шәбрәк
кирәк каты кул да.
Яшим дисәң, тыйма хыялыңны —
калма ярты юлда!

Калма ярты юлда!

1986

## Безнең моңнар

Моңлы дөнья,
моңлы тормышыбыз.
Безнең ишеләрне моң баса.
Моңлы җаннар җирдә булмас иде,
моңлы дөнья әгәр булмаса.
Үзе уйный,

үзе җырлый күңел.
Моңнар белән тулган ул күңел.
Лачын итеп күккә алып менә —
безнең моңнар мескен моң түгел.
Кирәк чакта иңә алар безгә,
әкрен генә иңә,
сиздерми.
Гел чистартып тора җаныбызны,
дөньялардан безне
биздерми.
Яшел бөре булып агыла моң,
яшел яфрак булып ярала,
сары яфрак булып җиргә ята,
кар бөртеге булып тарала.
Әкрен генә аткан таңнар моңлы.
Кояш моңлы,
моңлы иртәләр.
Җилләр булып кына исәләр дә
моңнар безне кеше итәләр.
Иркә генә,
йомшак кына алар —
гүя сөйгән кызлар карашы.
Шушы моңнар ялап алды инде
йөрәкләрнең күпме ярасын!
Кырлар моңлы,
моңлы авыл, шәһәр...
Моңлы сулар,
моңлы һавалар...
Сөйгән ярлар моңлы,
моңлы бала,
моңлы безнең ата-аналар.
Моңлыларга башны иеп үтәм.
Моңсызны да булды күргәнем.
Беркайчан да мин күрмәсәм иде
дөньяларның моңсыз көннәрен!

1985

## ***

Безнең инде азмы таңнар аткан.
Азмы өмет туган таңнарда!
Кайсылары чынлап эшкә ашкан,
җитәр, дидек, безгә алар да.

Безнең өчен әле таңнар белән
офыкларның күпме янасы...
...Юк,
җитмәгән икән,
таңнар атса,
өметләрнең туа яңасы.

1986

## Алай димәгез

*Алабуга шәһәре педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты укытучыларына*

Танышабыз шигырь укый-укый.
(Киләчәккә калыр сагыну.)
Бер җырламый безне җибәрмисез.
Зур бәхет ул җырга табыну.
Сезнең янда мин дә эреп китәм.
Күмеләм тагын туган моңнарга.
Җырыгызны,
җырлы күңелегезне
гомер буе әзер тыңларга.
Тик кушыла алмыйм,
сезнең белән
бик җырлыйсым килеп торса да.
Югалган шул тавыш,
җаным минем
моңнар белән тулы булса да.
Җырсызларны,
моңсызларны беләм.
Алар белән бераз йөрдәдем.
Сез җырлагыз!
Үзем дәшмәсәм дә,
сезнең белән җырлый йөрәгем.
Сезнең янга,
үзегезне сагынып,
җырыгызны сагынып киләбез.
Кушылмаса тавышым җырыгызга,
җыр яратмый икән, димәгез!

1988

## Борынгы башкорт җыры

Урал иле,
Урал дөньясының
инде монда соңгы таулары.
Татарларга килеп ишетелә
башкортларда урман шаулавы.
Ике тауның тоташкан бер җире,
ике халык кебек тамырдан.
Яланбаштан таулар.
Итәкләре
әрәмәдән юрган ябынган.
Ике тауның шул тоташкан җирен
сайладык без.
Күңел өнәде...
Очрашулы көннәребез үтте,
җитте саубуллашу көннәре.
Саубуллашу булып ишетелә
ике тауның искән җиле дә.
Саубуллашу көне,
соңгы көне
башкортларның татар җирендә.
...Тауда томан.
Җирне томан сарган.
Тау сихерле.
Урман сихерле.
Кичке якта таулар итәгенә
шул сихерләр безне китерде.

Тып-тын монда.
Әкрен-әкрен генә
эңгер иңә җәйнең кичендә.
Уй-хисләрне саллы-салмак итеп
чишмә ага томан эчендә.
Учак яна безнең уртабызда.
Ялкыннары тауның башында.
(Ялкыннарга карап хыялланган
бабайлар да күккә ашырга.)
...Җыр яңгырый шунда.
Яңгырамый.
Ишетелә,
тоела,
сизелә...
Утырабыз дөньялардан кичеп
шушы җырның моңы-сүзенә.
Хәтерләтеп «Иске карурман»ны,
алып китте башкорт артыннан.
(Мондый җырны тыңлаганда минем
күзем чыланса да тартынмам.)
Алып китте...
Йөзәр елга артка...
Бөтен чикләрне дә үттек без.
Урап чыктык Урал тауларын да.
Азаматны куып җиттек без.
Без бик ерак киттек.
Барып җиттек
башкортларның далаларына.
Без үткәнгә киттек.
Барып җиттек
башкортларның бабаларына.
...Без кайтканда учак сүнгән иде.
Уянганда инде төн иде.
Гомеремнең матур һәм мөкатдәс
көннәреннән бу бер көн иде.
Үлемсезлек булып туа икән,
халык йөрәгендә җыр туса.
Мең ел элек үлгән туганыңа
җитеп була икән, җыр булса.

1989

## Таныш кеше

Йөри кеше.
Башын күккә чөйгән.
Бакый кояш кебек балкыган.
Әйтерсең лә
кырык фил өстендә
кырык сандык килә артыннан.
Каян килсен?!
Бик күп булса, бәлки,
өч бүлмәле фатир алгандыр.
Йә,
йөрәге җитеп,
беренче кат
чит хатында кунып калгандыр.

Йөри кеше.
Борын җиргә тигән.

Хәсрәтеннән тәмам исергән.
Әйтерсең лә
менә яңа гына
атарга дип хөкем ителгән.
Ник атсыннар?!
Үтерүче түгел.
Үз гомерен бирер хаҗәттә.
Килмәгәндер сагынып көткән кеше...
Бирмәгәндер дусты әҗәткә...

Шатлыгының,
кайгысының сере
билгеледер аның үзенә.
Йөри кеше.
Яши кеше шулай.
Бөтенесе аның йөзендә.

1989

## Намус

Бик әйбәт булыр күк бу тормыш —
тигез дә, дөрес тә, гадел дә...
Һаман да җитешми бер нәрсә
бүгенге кешелек гамендә.

Берәүләр интегеп эзлиләр.
Булмаса, ул эзләп табылмый.
Булганда күренә. Беркайчан
намус ул өстенә ябынмый.

Намуска кагыла, намуска:
кыйныйлар, сүгәләр, хурлыйлар...
Кемнеңдер үзендә булмаса,
намусны кайвакыт урлыйлар.

Берәүнең җанына орына:
намусны асалар, аталар...
Кешегә тынгылык бирми ул.
Шуңадыр намусны саталар.

Бернәрсә тормый ул кемгәдер
сытарга намусны, таптарга.
Бик кирәк вакыты булыр, дип
тырыша кемнәрдер сакларга.

Кешегә бирелгән чамалап.
Кешегә күптәннән җитмәгән.
Караган ул теге дөньяга,
бусыннан гаделлек көтмәгән.

Намуска бәйләнгән, намуска:
йә өстә дөреслек, йә аста.
Намусның кирәксез чагы юк.
Намусны тотмыйлар запаста.

1989

## Хатын-кыз мәсьәләсе

Елан күрсә —
алай курыкмаган.
Дошман күрсә —
качыйм! димәгән.

Ә хатын-кыз юлны кисеп чыкса,
үлеменә моны тиңләгән.
Бик борыннан килгән хикмәт бит бу!
Нинди нигезләре бар икән?
Юлга чыкса —
үлем хәбәрчесе,
өйгә кайтса — аны яр иткән.
Заманалар ничек үзгәрәләр!
Үзгәрәләр ирләр, хатыннар.
Бер уйласаң,
хатын-кызның җирдә
артыграк яшәр хакы бар.
Хатын-кызлар йөртә матур итеп,
батыр итеп адәм баласын.
Булмасалар алар, бу тормышның
бер мескене булып каласың.
Гадел инде хәзер ир-атлар да.
Зирәкләнде инде хатын-кыз.
Семья түгел,
дәүләт эшләрен дә
хәл итмибез хәзер хатынсыз!

1988

## Әйбәт кеше

Калын тире белән туганбыз бит
абайламый гына
әле ярый.
Тормыш безне
(якын итеп инде)
кырыс холык белән «тәрбияли».
Инде күнеп,
ияләнеп беткәч
шомалыкка,
хәйлә,
әфирлеккә,
очрап куя сиңа шул бер кеше —
күңелләрне тагын әсир итә.
Әйтерсең лә килеп туктадың син
оҗмахына илткән борылышка.
Баш калкытып ала өметләрең,
ышанычың арта бу тормышка.
Алданасың
белә, күрә торып.
Очрак кына бит бу,
ялгыш кына.
Дөрес!
Ләкин
дару да ул үзе
тормышыңа,
хаста язмышыңа.
...Миһербанлык һич тә көтмәгәндә,
ул бутый да куя бөтен эшне.
Әнә шулай!
Очрап куя кайчак
миһербанлы кеше,
әйбәт кеше!

1992

## Һәвәскәр астроном

Чормасыннан төшми,
күккә карап,
күз дә йоммый төннәр үткәрде.
Һәр карышын капшап, барлап чыкты
күз карашы җитмәс күкләрнең.
Кызыктырмый аны бу йолдызлар.
Бардыр, диде,
бардыр яңасы.
Иске йолдызларда бер тапкыр да
тукталмады аның карашы.
Санамады,
ничә төне үтеп,
күпме йолдыз күктән атылган.
Яңа йолдыз кирәк иде аңа,
аның чормасыннан ачылган.
Табылмады, күпме эзләсә дә.
Тумагандыр.
Туар берзаман...
Яңа йолдыз инде эзләми ул.
Чормасында ләкин ул һаман.
Бөтен күкне күрә.
Бернәрсә дә
читтә калмый инде күзеннән.
Иске йолдызларга карый-карый
аерыла алмый күгеннән.

1990

## Күтеп алган яз

Елы шундый булган.
Язы шундый килгән.
Хәерлегә булсын —
котырып үсә үлән.

Җетерәк күк тоела
быел язның яме.
Яфраклар да быел
яшелрәктер әле.

Күзгә карап туа
табигатем кабат.
Яфрак кына үзе,
ә күңелгә канат.

Кошларның да быел
моңлылары кайткан.
Йә, әйтегез, кайчан
мондый таңнар аткан?!

Шифалы бу җилләр,
шифалы бу һава.
Кояш нуры күктән
дәва булып ява.

Алмагачы ап-ак.
Сибелеп китте сирень.
Кайтты кыр казлары

сагынып илен, җирен.

Уйный яшел дөнья
назлы язгы җилдә.
Елдан-ел бу язлар
матуррак килә.

Уйный әле җаннар.
Уйный әле сазлар.
Килә генә күрсен
безнең көткән язлар.

1990

## ***

Яратырга акыл кирәкмени,
дөрләп торган чакта учагың?
Бәлки әле, бөек вакытыңдыр,
даһи вакытыңдыр —
ул чагың.
Ул вакытлар үтә.
Ләкин кеше
яратусыз гомер итә алмас.
Ялкыннары күккә ашмаса да,
учакларын ташлап китә алмас.
Яратуны таләп итмәдем күк.
Андый шартым минем булмады.
Мин яраттым үзем.
Инде хәзер
кирәк мине ратулары.

1992

## Син*

*(Җыр)*

Язмышка язып бирелгән —
миңа ни кирәк тагын?
Иртәнге чыкларымдыр син.
Син минем атар таңым.

Бар минем тәрәз төбемдә
сулар сибәсе гөлем.
Син минем чыгар кояшым,
син минем аяз көнем.

Салкыннар тия күрмәсен —
минем җылыма төрен.
Син минем йолдызлы күгем,
син минем айлы төнем.

Уянсам югалыр кебек
бердәнбер якын кешем.
Уянасылар килми шул —
син минем якты төшем.

1992

## Гомер буе

Язларда ярат син мине —
гөрләвекләр аккан күк,
бөре ачылган шикелле,
сирень чәчәк аткан күк.

Җәйләрдә ярат син мине —
чыклы таңнары ул син.
Арыш серкә очырганда,
кайнар рәшәләр бул син.

Көзләрдә ярат син мине —
киек каз тавышыдай,
болытлар агышы кебек
шаулаган камышыдай.

Кышларда ярат син мине —
карлар күмгән чакларда.
Ап-ак бураннарга керик
уйнап торган айларда.

Язларга кайта алмабыз.
Җәйләр дә килмәс кабат.
Көзе дә, кышы да үтәр —
үтмәгән чакта ярат.

Кире кайтып булмый торган
юл бит ул гомер юлы.
Ел буе ярат син мине.
Ярат син гомер буе.

1992

## Син яратсаң...

Саргаймаслар яшел яфраклар да
яздан язга кадәр;
таңнарның да җылы нуры бетмәс —
син яратсаң әгәр.

Алып килә торыр көннәр һаман
сөенечле хәбәр;
күкләрендә кояшы да баймас —
син яратсаң әгәр.

Чиста тоту кирәк.
Мәхәббәтне
алдау бик тә хәтәр.
Кичке моңнар мәңге серле калыр —
син яратсаң әгәр.

Җиңә алмас кебек беркайчан да
бәла,
каза,
зәһәр...
Төннәре дә үтмәс,
ай да китмәс —
син яратсаң әгәр.

Нәрсәләрдән генә коелса да:
корыч,
алмаз,
мәрмәр... —
чыдый алмас,
эреп бетәр йөрәк —
син яратсаң әгәр.

1992

## Күзләреңнән күкләр карый

Нигә безнең ара ерак, димә.
Карама син миңа әрнелеп.
Бу ярату бер гомерлек түгел.
Бу ярату безнең мәңгелек.

Шуңа күрә күктән кара миңа.
Якын итеп караерактан.
Гашыйкларны күкләр сөендергән.
Гашыйкларны күкләр елаткан.

Югарыдан карап тор син миңа.
Күрә алмам кебек якыннан.
Кирәк икән, сиңа таба күккә
йолдыз булып җирдән атылам.

Миңа синең биеклегең кирәк.
Артык якын килеп карама.
Йолдызлары янып торсын күкнең
синең белән минем арада.

Ара ерак әле, ара ерак.
Киләчәк бит әле үтмәгән.
Күзләреңнән синең күкләр карый.
Бер төшәрсең әле күкләрдән...

1989

## Ике кеше

Көннәре бар, гомере бар,
җире бар, һавасы бар.
Үләннәр шытып чыгасы,
карлары явасы бар.

Нинди булып таңнар атар?
Нинди булыр кичәләр?
Әйтә алам, сорасалар,
кемнән тора? дисәләр:

Гамәлгә аша көчләрең,
кодрәтең җитмәс эше,
бер булып әгәр тотынса,
тотынса ике кеше.

Гамәлләр ялгышкан булса —
ике кешедән сора.
Алдагы гомер-язмышлар

ике кешедән тора.

Хәл итә икән барысын
ике кеше теләге.
Ике кешедә икән бит
дөньяның төп терәге.

Берәүне дә Алыпларга,
Илаһига тиңләмим.
Ә барыбер хәл итүче
ике кеше — син дә мин!

1991

## Чәчәк яши

Гомере дә озын түгел —
кисеп алып китәләр.
Тере килеш, тамырыннан
өзеп бүләк итәләр.

Бәләкәй генә бер чәчәк.
Гомере кыска димә.
Шушы кыска гомерендә
бу чәчәк яши белә.

Уяна Кояшка карап —
көнгә таҗларын ача.
Карый табигать җиһанга
шушы чәчәге аша.

Кич җитә, ябыла таҗлар —
калышмый Кояшыннан.
Гомер үтүен бу чәчәк
үзендә тоя сыман.

Чәчәк уянганын көтеп
утырган чаклар була.
Күңел шыр буш калган булса,
яңадан күңел тула.

И бөек, зирәк табигать —
син бөек хозурият!
Кешеләреңне дә, Хода,
шулай яшәргә өйрәт!

1992

## Мин танымыйм сезне

Бәхет итеп,
атап бирелгәндер
безгә туган-үскән авыллар.
Шул авыллар күңелләрдә мәңге
изге урын булып калырлар.
Бераз гына уйлы-моңлы,
бераз
мәрхәмәтле булса җаныбыз,
сау канаты булса рухыбызның —
малай чактан алдык аны без.
Шәрә тәнгә кояш ныграк үтте.

Безнең өстә көлмәк булмады.
Ат көткәндә, безнең күңелләргә
ай яктысы кереп уйнады.
Җилләр исте безнең күңел аша.
Инешләрдә сулар бүтәндер...
Ялан тәпиләрдән җаныбызга
җир җылысы ныграк үткәндер.
Нигъмәтләре —
урман аланында.
Миләшендә,
шомырт,
баланда...
Без йолкыган колхоз шалканында...
Женьшень тәэсирләре бар анда.
Тере идек без дә.
Тере иде
ярлар,
сулар,
кырлар,
урманнар...
Күңелебез исән-сау вакытта
җан сакчысы аңа булганнар.
Аңга түгел,
җаныбызга кергән.
Аңлап түгел,
тоеп алынган.
Хисләребез бүген олы булса —
орлыклары күптән салынган.
Бик күп нәрсә бирде миңа тормыш,
бик күп алды,
бик күп талады.
Туган-үскән җирем-суым биргән
бәхетемне ала алмады.
Авыл исән.
Карап йөрим кайтсам:
үз урынында апай-агайлар...
Минем күңел башка нәрсә эзли:
кайда икән безнең малайлар?
Бер әйләнәм таныш су буйларын.
Буасы юк.
Таллар корыган.
Сазлык кына калган
без муеннан
балык сөзеп йөргән урыннан.
Ишелгәннәр ярлар.
Беткән камыш.
Бәгырьләрең китә өзелеп.
Кайчан гына әле чыктык бит без
бу суларда атлар йөздереп.
Су буйлары ятим,
малайлар юк.
...Бер әйләнәм ындыр артыннан.
Кычкырасы килә:
«Әй, малайлар!
Кайттым бит мин!» — диеп.
Тартынам.
Кырларыма китәм,
әрәмәгә.
Елгаларга китәм,
урманга...

Малай чакның карт шайтаны очрап
котырта бит шалкан урларга.
Эзләп йөрим.
Кайда бу малайлар?
Кайда минем дуслар,
ишләрем?
Бүген менә малай була калсам,
берьялгызым монда нишләрмен?
Очрап куя кайчак
йә матайга,
йә сәпидкә инде атланган.
И бәхетсез җаннар,
бу замана
төшерде шул сезне атлардан.
Бик аптырап карамагыз миңа.
Үпкәләп тә миңа калмагыз.
Сез югалткан
үзенең малай чагын
эзләп йөргән бу бер агагыз.
Ни өчендер туган авылыбыз
күренә хәзер бераз ят булып.
Ни өчендер миңа сез дә бүген
күренәсез бераз карт булып.
Шул ук сүзне, бәлки, безгә карап
әйткәннәрдер безнең бабайлар.
Кызганам да бераз,
таныйм да күк,
танымыйм да сезне, малайлар!

1987

## Казлар

Инешләре аның елга-диңгез.
Урман иде аның камышы.
Су буйларын каз көтүе сарган.
Һаваларга сыймый тавышы.

Ана казлар ул чак горур иде.
Сәбәп тә бар горур тоярга:
ата казлар биеп кенә тора,
егермешәр бәбкә ояда.

Ярлар мескен хәзер.
Һавалар тын.
Ә колакта казлар каңгылдый.
Бала чакта тоеп үскәннәрне
булдыралмый кеше сагынмый.

Йөргән чакта туган яр буенда
шул уйларым белән буталып,
кинәт кенә әллә нәрсә булды,
тетрәндем дә калдым тукталып.

Казлар күрдем!
Бөтен яр буена
бер генә пар.
Нәрсә әйтәсең?..
Су буенда шушы пар каз йөри
ияртkән дә... ике бәбкәсен.

Әкрен генә,
оялып кына атлый.

Башын игән мескен ана каз.
Берни булмагандай
горур башын
күккә чөеп бара ата каз...

1989

## Чыпчык

Кайгысы юк көзен китүләрдә,
кайгысы юк язын кайтырга.
Кыш уздыру мәшәкате генә
сала аны бераз кайгыга.
Чатнама кыш.
Кошлар тәгәрәшеп ачтан үлә,
ә ул җим таба.
...Бөркет оялары туза күктә,
безнең чыпчык исән-сау кала.
Куып җибәрсәләр, кабат килә,
берәүгә дә үзе бәйләнми.
Берни булмаган күк көлеп килә,
әйтерсең лә бер дә гарьләнми.
Мут та үзе... Үпкәләп тә булмый.
Килми аңа никтер ачу да.
Каушамый да.
Аңа һәр келәтнең
түбәсендә тишек ачыла.
Җәен, кышын чыпчык җаен таба,
җылы урын таба —
шауламый.
(Кемнәргәдер кайчак чыпчыклардан
өйрәнү дә комачауламый.)
Яши чыпчык.
Артык мактанмый да.
«Син!» дигәнне көтә,
«мин!» дими.
Мактасалар, һич тә каршы түгел,
берәүдән дә үзен ким дими.
Ел тәүлеге аның тавышы килә.
Язларын да,
җәен,
көзен дә.
Башкаларга да ул тынгы бирми
һәм кызгана белми үзен дә.
Сайрыйм бит, ди.
Үзенең сайраулары
халык моңнарына тиң кебек.
Дулкынланып «сайрый»:
чык-чык, чык-чык...
Сандугач та аннан ким кебек.
Сандугачлар китә көн буена,
биш-ун минут сайрап ала да.
Көннәр буе чыпчык чык-чык килә
шул талларга кунып ала да.
Кош икәнен аның һәркем белә.
Тотмыйлар да аны,
тимиләр.
Илдә чыпчык үлми, дип сөйлиләр...
Чыпчык сайрый әнә, димиләр.

1988

***

Очрашты сабакташлар — дуслар.
Күпме җәйләр,
кышлар үткәннәр.
Икесе дә шәхес,
икесе дә
зур кешеләр инде күптәннән.
Сөйләшәләр:
олы фикер,
акыл
аңкып тора әйткән сүзләрдән.
...Ике малай бер-беренә карый
аптырашып
ачык күзләрдән.
1986

## Балык балалары

Суда әле,
камышларда караш...
Талгын сулар моңлы,
уйлата.
Онытылып,
йокымсырап торган
хисләреңне сулар уята.
Өерләнеп йөзә...
Сибелеп китә,
очкын сыман, суда вак балык.
Үтеп китеп бара кондызлары,
камыш кыягына атланып.
Суда әле,
тын суларда караш...
Шушы су да үзе бер галәм.
...Сулардан да күзне алып булмый.
Бик катлаулы кайчак син, адәм!
Балык балалары күмәч ашый.
Су өстеннән сикереп алалар.
Күз алдына килә
кайлардадыр
ачтан үлеп яткан балалар.
Быел җәйләр шундый матур килде...
Балыклар да ничек үрчегән...
Балык балалары күмәч ашый,
әллә нигә шуны күпсенәм.
Искә төшә...
уйланулы чакта,
тук заманда инде торсак та...
Әйтер берәү:
күпме язып була,
сөйләп була, диеп, бу хакта!
Үткән белән безне
өзелмәслек,
тузмый торган җепләр бәйлиләр.
Мин үземне онытырга әзер...
Күз алдында тора әниләр.
Якты язлар гына онытыла.
Онытылмый ачлык язлары.
...Көзеннән үк алар буш калдылар, —

алабута басты базларны.
Карлы-сулы язгы басуларда —
безнең икмәк,
безнең ашыбыз.
Шул кырларга куелырга тиеш,
и аналар,
кабер ташыгыз!
Ризыкларның тәмен беләм инде.
Тик тамактан үтми хәрәме.
Гомер буе язарыңа җитәр
тик ике сүз:
черек бәрәңге!
Шул ике сүз алып китә иде
әниләрне әче таңнарда.
Зирәклегем җитми минем һаман
әниләрнең җанын аңларга.
Күз алдында кайтып,
җылы эзләп
сыенуы салкын мичләргә,
сызлаганда арык аяклары
елаулары шомлы кичләрдә.
Исән чакта йокы күрмәгәндер,
күпме төне үтте калтырап!
Аягымы,
йөрәгеме, —
белмим,
сызлагандыр кайсы катырак.
Ул вакытлар барыбер кабатланмас,
әллә ниләр, бәлки, күрермен.
Безгә — яшәү,
ә үзенә әни
алып кайткан икән үлемен.
Күрмәм бүтән андый аналарны.
Яшәделәр алар бик күптән.
Сугышлар да беткән...
Ә аларны
нинди кодрәт,
нинди көч йөрткән?!
Буйсынмыйлар.
Шул елларга уйлар
кайта кайчак күңел тулганда.
И рәхәт ул
балык ашатулар,
авыз тулы икмәк булганда.
Балык балалары күмәч ашый.
Кисәк-кисәк суга атабыз.
Сикереп ала балык —
сөенәбез!
Икмәк булды быел, ашагыз!

1987

## Бердәнберең

Хаста булыр үзе.
Ә белгертмәс.
Исән-сау мин, дияр хатында.
Кайт! дип язмас.
Үлемнәре сөйләр

озак авыруы хакында.

Азып-тузып кайтсаң —
сыендырыр.
Кеше итәр сине —
сер бирмәс.
Соңгы кисәк икмәге дә бетәр —
беркайчан да,
туйдым, кит! димәс.

Бурычларың булса, и зимагур,
соңгы шәлен сатар түләргә.
Синең туган минутыңнан башлап
синең өчен әзер үләргә.

Үтә күрер сине.
Сүзсез аңлар.
Аның күңелен һични алдамас.
Нинди генә җинаятьләр кылма —
хөкем итәр,
ләкин каргамас!

Аның өчен син һәрвакыт кеше.
Мәңге шулай булып кала ул.
Аңлый алсаң,
бердәнберең синең
тик бер генә кеше —
ана ул!

1991

## Кабердәге чәчәкләр

Хуҗалар тавышны яратмый,
керсәгез, кычкырып йөрмәгез.
Чәчәксез каберләр юк монда,
кабердән чәчәкләр өзмәгез.

Җәнҗал юк, гауга юк, тавыш юк.
Талашып яшәми бу халык.
Бу безнең икенче дөньябыз.
Бу безнең мәңгелек патшалык.

Ел саен сиреньгә күмелә.
Каберләр ел саен уяна.
Сиреньнәр янына утырып
ярый ул кайчакта уйларга.

Мин күрмим зиратта үлемне.
Зиратта каберләр яшиләр.
Без аны тик тыңлый белмибез,
шуңа ул каберләр дәшмиләр.

Битемне куям мин сиреньгә,
ишетәм каберләр тынлыгын.
Тоям күк сиреньнәр исеннән
яшәүнең дәвамын, чынлыгын.

Кем белә? Бәлки, бу чәчәкләр
тишелеп чыккандыр бәгырьдән.
Зиратка керсәгез, күрсәгез,
чәчәкләр өзмәгез кабердән...

Кем белә? Бәлки, бу чәчәкләр
тишелеп чыккандыр бәгырьдән...

1990

## Кемнәр дәшә безгә

Балачактан Күкләр якын булды.
Үсә-үсә Күккә карадык.
Гашыйк булгач,
җиргә чалкан ятып,
Күккә карап йолдыз санадык.
Хәзер дә бит һаман Күктә күзләр.
Нәрсә көтәм?
Нәрсә юксынам?
Җиребездә нидер җитми кебек.
Яныбызда кемдер юк сыман.
Булмаганны кеше юксынмый ул.
Булмаганны кеше тоя алмый.
Тоя икән,
инде сизә икән,
йөрәккәен кеше тыя алмый.
Тарта мине,
магнитлардай тарта,
көтә анда безне кемнәрдер.
Эзли алар.
Алар да бит безне
йөрәкләре белән күрәдер.
Галәм иркен.
Тавыш ерак китә.
Сөйләшәсе килә:
Сез кем ул?
Галәм чиксез.
Шушы чиксезлектә
ялгыз булса бу Җир...
мескен ул!
Безнең өчен генә Кояш батмас.
Безнең өчен генә Таң атмас.
Ялгыз булу безнең —
мөмкин түгел,
ялгыз итеп Ходай яратмас!
Ишетәм мин!
Гомер буе безне
кем чакыра?
Безгә кем дәшә?
Бар ул анда,
бар ул тере җаннар...
Күкләр белән күңел сөйләшә!

1990

***

Җиттеләр китәсе көннәр дә.
Әле сез бәхилләп калмагыз.
Кызарып кояшлар байганда,

без киткән якларга карагыз.

Җитәр ул сагыныр вакытлар,
хисләргә бирәү дә баш түгел:
килер бер әйләнеп кайтасы,
безнең дә йөрәкләр таш түгел.

Утларын сүндереп китмибез.
Йөрәкләр калсыннар кабынып.
Калдырып китәбез сагышын,
көтегез безне дә сагынып.

1986

## Картлар йорты. Сентябрь

Каен яфраклары сөйләшмиләр.
Агачларның яшел шавы беткән.
Өзелә дә төшә,
өзелә дә...—
гомер үткән икән,
гомер үткән.

Ипләп кенә.
Җайлап.
Ашыкмыйча.
Уйлый-уйлый гына туктап-туктап,
яфракларга карап атлый картлар.
Кыштыр-кыштыр килә сары сукмак.

Күпме күзләр инде яфрак койган.
Уйлар җитә уй-моң кирәкләргә.
Гомер яшел чакта уйлар яшел.
Күзләр җиткәч уйлар зирәкләнә.

Тыңлый картлар яфрак кыштырдавын.
Ни кылганын тәкъдир үзе белә.
Илаһилык нуры балкып китә,
күзләр карый картлар күзе белән.

Өзелә дә төшә,
өзелә дә...
Салмак кына,
тыныч,
сабыр гына.
Күзләр җитте инде,
күзләр җитте...
Мәңгелеккә кала тамыр гына.

1990

## Һаман шул җир

Бер уйласаң, син бик карттыр инде.
Бер уйласаң, син бик яшь әле.
Аягына кеше басканнан соң
күпме генә әле яшәдең?!
Җир тарихын бүген,
Җир гомерен
кеше туган көннән саныйм мин.
Кеше гомере белән Җир гомерен
бер гомер дип хәзер карыйм мин.

Кыска гына шушы бер гомердә
бик күп нәрсә инде үзгәрде.
Җиргә бүген башкачарак итеп
карый бугай кеше күзләре.
Кайда, Җирем, синең бөек чагың?!
Чиксез чагың,
серле,
зур чагың?!
Күрер өчен шуны
туар идем
мең ел элек синдә мин тагын.
Йөзелмәгән диңгезләрең белән
менелмәгән таулар булганда,
үтелмәгән урманнарың аша
и ашкынган кеше юлларга!
Төрле юллар алып киткән аны...
Таба алмаган синең чикләрне.
Берәм-берәм юлда чишелә барган
синең серләр,
аның шикләре.
Ачылмаган җирләр дәшкән.
Төшеп күрер иде океан төпләрен.
Серләреңне укый-укый, кеше
җирдән тапкан күктән көткәнен.
Җаны булган җирдә һәрнәрсәнең,
серле булган һәрбер почмагың:
һәр агачың,
ташың,
суың,
һаваң,
хайваннарың,
очар кошларың...
Син зур булган.
Бөек булган.
Кеше гарьләнмәгән башын ияргә.
Без йөрибез бүген таптап сине,
башлар әзер күккә тияргә.
Үсте кеше.
Үзе үскән саен
кечерәя бардың син һаман.
Җир шары дип кенә атадылар
иксез-чиксез Җирне берзаман.
Ачыласы сереӊ калмагандыр,
син җитәрлек безгә ачылдың.
Инде күкләр яулап алды хәзер
кеше җанын,
кеше акылын.
Бетәр кеше,
әгәр бетә икән
Җир җылысы аның канында.
Бик кечкенә булып калдың бүген
кешелекнең чуар җанында.
Аяусыздыр яшәү кануннары.
Кеше җитәр үзенең ярына...
Бу галәмдә кеше генә бит без.
Син дә, Җирем, анда шар гына!

1987

## Кая таба...

Белмисең дә:
каян килеп баса?
Бәгыреңә таштай каплана.
Качасылар килә
сикереп менеп
болыннарда калган атларга.
Нинди хәсрәт?
Нинди афәт килә?
Шатлыкларны кемнәр урлады?
Кая безнең балкып торган күңел?
Күзебезнең кая нурлары?
Көннәр эссе,
ә кешеләр салкын.
Бу салкынлык кайсы тарафтан?
Ходай Җирдә адәм балаларын
җылы җанлы итеп яраткан.
Кояшның да нуры сүрелмәгән.
Кешеләрдә генә җылы юк.
Җилләр исә,
шаулый урман,
сулар...
Табигатьнең моңы-җыры юк.
Моңнары да безгә килеп җитми.
Җырлары да безгә ирешми.
Җылы сүздән курка кеше бүген.
Елмаю да безгә килешми.
Калырмы ул шулай?
Терелерме?
Ташка әйләнеп тәмам бетәрме?
...Кеше җаны
таулар күтәрә алмас
ул ташларны шактый күтәрде.
Күтәрә алмас кебек инде бүтән.
Менә шулар борчый,
куркыта.
Кая баккан бүген Кеше җаны?
Кая таба Кеше юл тота?
Йә Илаһым,
дучар итә күрмә —
таш замана, ахры, башлана.
...Җылы эзлим.
Битләремне куям
кояш нуры сеңгән ташларга.

1992

## Килгән иде болыт

Ачуланган усал мәче кебек,
әй күпергән булды.
Йөзде күктә һава шары сыман,
зурайды ул, тулды.
Туплар атты, гүя күкрәде күк.
Очты яшен ташы.
Өзелде дә китте аерылып
кинәт аның башы.
Ялт-йолт итеп торды җирләр,
күкләр

яшен утларыннан.
Тишкәләнеп бетте бөтен тәне
яшен укларыннан.
Инде күктә торыр хәле бетте,
яуды яңгыр булып.
Гөрләвекләр булып җыелды да...
агып китте болыт.

1991

## Адашкан поши баласы

Балалар күз алдында, газапланып,
поши үлеп ята.

*«Известия» газетасыннан*

Адашыпмы,
кызыгыпмы керде
шәһәр урамына нарасый.
Ничек инде кыргый хайваннарга
шәһәрләргә керү ярасын?!
Бәреп екты аны зур машина —
урам кагыйдәсен бозган бит:
машинага әнә юл бирмәгән,
кызыл утны күрми узган бит.
Аяк сынды.
Яраланды тәне.
Сызланса да сыкрап ятмады.
Ул агачлар күрде.
Урмандыр дип,
мәктәп бакчасына атлады.
Кереп ауды агач арасына,
бүтән барыр хәле калмады.
Талпынса да кабат,
җиргә ауды,
аягына баса алмады.
Бакча тулды шәһәр халкы белән
(пошины тиз күреп алдылар).
Укучылар,
бәлки, ашар, диеп,
алдына бер ипи салдылар.
Ашамады поши.
Аяк сызлый.
Ярасыннан һаман кан ага.
Ипи түгел,
канлы яраларын
бәйләү кирәк иде шул аңа.
Ярты шәһәр халкы карап торды —
кеше табылмады ярдәмгә.
Уйлагандыр мескен:
язмышларым
кала күрмәсен, дип, адәмгә.
Кичкә таба үлде поши улы.
Еладылар үксеп балалар.
Балаларга күчеп калды бугай
поши баласыннан яралар.

1992

## Көзге зират

Менә-менә күкләр ишелер күк,
җиргә төшәр сыман убылып.
Катлы-катлы болыт итәкләрен
җилләр алып китә умырып.

Кыйшык чардуганнар уртасында
тонып беткән кабер ташлары.
Җәй җәйләгән гөлләр үлеп ята,
шул ташларга салып башларын.

Нишләтәсең,
килде зиратның да
үз җилләре белән үз көзе.
Тереләрнең дә була,
үленең дә,
үлемнең дә була үз йөзе.

1970

## И Тәңре

Суына җан.
Нишләтергә икән
ташка әйләнеп барган бәгырьне?
Сезгә дәшәм:
Күгем һәм Кояшым,
сиңа дәшәм әле,
и Тәңре!
Бабаларым сиңа табынганнар.
Кирәк бүген безгә кичәге.
Әллә шуңа яшибезме һаман?
Әллә шуңа кеше исәнме?
Сезгә дәшәм, ташлар.
Сез мәңгелек.
Кеше буе җитмәс Тау иле.
Рәнҗетсәк тә,
үч алмыйча бездән,
саклап кал син безне, Таң иле.
Без талаган урман.
Каен, имән...
Куаклары җирнең, таллары...
Сездә бүген өмет.
Коткарыгыз!
Суынып бара кеше җаннары.
Бар шакшыны түктек.
Елый-елый
җыеп килдегез сез шуларны.
Инде сездән мин мәрхәмәт сорыйм,
елгаларым минем,
суларым.
Карашларым Җирдә, Суда бүген.
Кояшымда,
газиз Күгемдә.
Язмышымны куйдым кыл өстенә.
Бөтен гаеп минем үземдә.
Мин үземне-үзем белмим бүген:
әллә бетәм,
әллә яңарам.
Бабаларым сиңа табынганнар,
сиңа карап мин дә ялварам.

Кеше булып туган бит мин.
Яшим
һәм яшәргә телим мин мәңге.
Сүнми торган гомер бир син миңа,
мәңгелекне бир син,
и Тәңре!

1989

## Арык

Кулын чайкый суда үзбәк карты.
Күкрәкләрен,
битен сыпыра.
Әйтерсең лә
Амударьяларның
уртасында бу карт утыра.

Күргәне юк аның зур елгалар.
Күргәне юк аның диңгезне.
Шушы арык суы белән генә
исән аның җире-нигезе.

Гел бер көйгә ага тыйнак кына,
тереклеккә таба юл ярып.
Чишмәләрдән кыйммәт, елгалардан,
диңгезләрдән кыйммәт бу арык.

1989

## Безнеке

Басып алган колач җиткән кадәр.
Үзе туйган,
күзе туймаган.
Болар миңа мәңгелеккә, дигән,
баш әйләнгән татлы уйлардан.
Нинди иркен дөнья!
И хозурлык!
Тез чүктерде бугай барсын да.
...Ыңгырашкан халык сөякләре
каберлектә,
курган астында.
Ният зурдан:
гел аныңча булыр.
Киләчәктә — алда карашы.
Сизми калган:
киләчәктә икән
көннәренең әле карасы.
Зур хәвефләр,
олы эшләре бар —
мин тарихтан чүп-чар эзләмим.
Күренеп тора:
пычрак чабатасы
таптап үткән читек эзләрен.
Барысы да гел аныкы икән.
Кая гына үтеп кермәгән?!
Җирне,
Суны,

Күкне халыкларга
әйтерсең лә Ходай бирмәгән.
Урысныкы икән бу наратлар.
Аныкылар икән каеннар.
Безнең бәхет урысныкы икән.
Татарныкы — аның кайгылар.
Кырлары да,
урман,
елгалар да
тик аныкы гына.
Идел дә...
Йотым суга мәхрүм итеп берәү
йөртер иде газиз иленҗдә.
Әле ярый минем туфрагымда
яши икән шундый «туганым».
Әйтерсең мин мескен бер теләнче
зина бала булып туганмын.
Урманымда үсте,
каберемдә...
Булганым юк минем ваемсыз.
Татар каены дип атамадым,
калмадым мин ләкин каенсыз.
Кая тели —
шунда очты кошлар.
Мин бөртекләп карны бүлмәдем.
Тын кысылган вакытлар да булды —
Күгем-һавам иркен,
үлмәдем.
Минеке, дип исбат итәр өчен
табигатькә сала тамгасын.
...Болыны да, йә, аныкы булсын,
бер милләтсез яңгыр яумасын.
Татар хозурлыгы дип йөрмәдек.
Татарның юк мәллә минлеге?!
Калсын әйдә, йә, аныкы булып
дөньяларның хозур-киңлеге.
Атамадым аны чучка диеп,
йөз кат аннан чиста булсам да.
Аталмады татар мунчасы дип
мең ел алдан салган мунчам да.
Бер көрәштә
бергә җиңеп чыккан
батырларга урын калмасын,
җиңүче дип дөнья сугышында
атыйк бары урыс солдатын.
Ят туфракны таптап яшәп булмый —
халыкларның каны уяна.
Ирегенә Илнең богау салса,
андый халык үзе югала.
Сына сөңге.
Сөңге очындагы
бөеклеге белән зурлык та
эреп бетә,
чөнки булмаган ул,
булмаган ул анда чынлыкта.
Күпме генә көчәнмә син,
күпме
үзеңнеке диеп атама,
кышы,
җәе,

язы,
көзе, барыбер
ул безнеке диеп атала!
Мәңгелекне даулап җан кыйганның
гомерләре үтәр әрнелеп.
Барыр юлы Кояш баешында...
Җирләр,
Сулар,
Күкләр мәңгелек!
Синеке, дип әйтик,
(күңеле булсын)
һавасы да,
искән җиле дә...
Ә мин тыныч.
Басып торам бит мин
аяк терәп татар җирендә.
Аның исән-иминлеге өчен
мин үземне инде аямыйм.
Ышанычым минем,
инандым —
арттан килә минем дәвамым.
Алдап-урлап йөрмәс минем халык.
Үзләштермәс Җирне, Күкләрне.
Минеке дип әйтер хакы да бар,
Ходa шаһит —
күпне күтәрде.
Татар кышы,
татар кары, диеп,
бирәүне дә, шөкер, алдамам.
Барысы да Ходай Тәгаләдән,
Барысы да Тәңре-Алладан.

1992

## ***

Әллә нигә күңел кыбырсына,
әллә нигә тора пошынып:
бала чакларыма кайткан кебек
бер очасы килә кош булып.
Мин үземне һаман аңлый алмыйм.
Тик торганда, ахры, пошманган.
Кошлар әнә бала очыралар,
көнләшәмме әллә кошлардан?..

1985

## Егерме ике күл

*Кама буендагы бер урында гына да, аның суы күтәрелгәч, 22 күл су астында калды.*

Туа тора.
Үлә тора гомер.
Гадәти хәл туу, үлүләр.
...Күпме еллар үтте,
нигә генә
онытылмый һаман шул күлләр?!
Ниләр бирә кеше ашкынуы?
Кая бара аның юллары?

...Табигатьнең тулы бер дәүләте
су астына кереп югалды.
Әрәмәләр...
Болын...
Урман...
Күлләр...
Куяннары...
Сайрар кошлары...
Барысын да бергә суга салдык!
Кеше моңа бер дә пошмады.
Кыр казлары кайтты.
Таралышып
эзләделәр туган җирләрен.
Адаштык, дип елап китте казлар,
озатып калды салкын җилләре.
Басып торам көймә уртасында.
Офыкларга җитә сулары.
Суга салып була илне-җирне,
судан алып булмый шул аны.
Кеше үлеменә кеше әзер.
Мәңге яшәгәнен күрмәдем.
Гомер буе сызлый икән бәгырь,
күз алдында үлсә күлләрең!
Күзләремне йомсам,
ишетәм мин...
Һаваларда казлар тавышы...
...Гомер буе елап шаулар җанда
егерме ике күлнең камышы.

1990

## Җан тарта

Теләкләрең синең изге булсын,
сүзең алтын булсын —
тик дәшмә.
Кирәк түгел акыл,
йөрәк җитә.
Кирәк түгел кеше киңәшкә.
Кешене дә,
үзеңне дә хәтта
тыңлап булмый торган чаклар бар.
Тормыш үзе сиңа аерып куя,
якыннарың була,
ятлар бар.
Рөхсәт-мазар сорап тормый синнән.
Шакымыйча гына керә ул.
Кешеләрнең иң мөкатдәс хискә
сусап яшәгәнен белә ул.
Ничек кенә итеп яраттыра?
Ничек кенә үзенә карата.
Уең белән син каршыдыр, бәлки,
нишләтәсең аны? —
җан тарта!

1990

## Арал

Әлсерәгән комнар. Янып ята —

сулышлары кайнар ярларының.
Табигатьне тагын кайгы басты —
хәле начар бүген Аралының.

Чирен аның кеше өсти тора.
Табибына мохтаҗ, даруына.
Бер тамчы су кирәк, бер тамчы су
ирен чылатырга авыруга.

Диңгезгә дә сулар җитми әнә,
гомер буе әгәр таласалар.
Эчеп калыйк! Безнең гомерләргә
җитәр әле диеп карасалар.

Комсызлыкның чиге булмый калмас.
Андый чаклар килеп җитә икән.
Гомер иткән үз ярларын сулар
андый чакта ташлап китә икән.

Диңгез китәр. Китәр барлык сулар.
Һавасы да калмас суларына.
Кайнар комнар гына сибелеп ятар
бүген чәчәк үскән юлларына.

Кырын ята ярда кораблары,
һава җитми үлгән балык кебек.
Балыкчылар йөри башын иеп,
үле җиргә кайткан халык кебек.

Кайнар комга басып үтә кеше.
Дулкыннары килеп күмми эзне...
Шул кораблар кебек калырбыз без,
барысы да ташлап китсә безне.

1989

## Мәләкәс буе

Туган ягым түгел.
Балачагым ярларыңда синең үтмәде.
Ыштан белән маймыч сөзә-сөзә,
суларыңда чумып үсмәдем.
Син Идел дә түгел.
Чулман түгел.
Бөек елгаларга тиң түгел.
Син — Мәләкәс кенә.
Минем өчен
Иделләрдән ләкин ким түгел.
Күрештерде мине синең белән
кордашларым,
дуслар,
якыннар.
Якын итеп инде сиңа минем
сүз әйтергә хәзер хакым бар.
Йә сөенгән,
йә көенгән чакта...
Болай гына кайчак күрешеп...
очрашабыз бергә синең янда,
дөньяларның хәлен белешеп.
Сөйләшәбез ярларыңа ятып,
карый-карый синең суыңа,
үзебезнең хакта,
синең хакта,

яшәү мәгънәләре турында...
Башка җирләр исән,
җан сызлана...
Шифасы бар синең ярыңда.
Чирәмеңдә аунап сөйләшүләр
кирәк булган минем җаныма.
Белми кеше кайда югалтасын,
белми кайда нәрсә табасын.
Гомеремнең бер өлеше булып,
язмышыма кереп каласың.

1987

## Җәй

Җылыга сусаган күңел.
Җылы сорый тәне дә.
Җылысында булган икән
бу җәйләрнең яме дә.

Эреде җан, җылынды тән
җылы җәйләргә кергәч.
Без — тагын адәм баласы,
без — тагын чибәр, көләч.

Җәйләрне уйлап яшәсәң,
көзләр дә җылы сыман.
Көзгә керербез җылынып
җәйләрнең җылысыннан.

Һәркайсы матур булса да,
барыбер бүтән инде.
...Яфракларга сары төшә —
бу җәйләр үтәр инде.

Көзләр дә җитәр инде...

1991

## Сары чәчәк

Өченче ел инде,
өченче ел...
Дөнья тора тоташ сарыдан.
Кырларына,
урамнарга,
хәтта
юлларына кадәр сарылган.
Чәчәкләрнең булмый ямьсезләре.
Табигатьтә матур барысы.
Тик нигәдер
соңгы елларында
тишелә дә чыга сарысы.
Һәр төсенә халык мәгънә биргән.
Берсе шатлык.
Берсе кайгысы.
Кемнәр белә —
чуар язмышларын
алып килгән аңа кайсысы?

Гел бер төстә түгел үткән гомер.
Төрле чәчәк атты еллар да.
Кызыл чәчәкләргә карый-карый
туры килде шактый еларга.
Аклары да булды,
аллары да...
Шыту белән шиңде алары.
Булды әле шундый вакытлар да —
бер чәчәк тә илдә калмады.
Сары чәчәкләргә карап йөрим.
Бөтен җирне баскан бу чәчәк.
Ак булырмы?
Әллә ал булырмы?
Сары булыр микән киләчәк?

1990

## Шишкин наратлары

Җилкенә җан, ташый күңел,
чыгып бассам бу ярга.
Инде күптән йоклап киткән
хисләр кабат уяна.

Шушы күкләр, шушы сулар,
шушы ярлар, бу урман...
Туган җиргә беренче кат
карап торгандай булам.

Орынсам наратларына,
наратларына тисәм,
үземне бөеклек белән
күрешкән кебек сизәм.

Наратларына сыенып
килә бер дәшәселәр.
Алар мине аңлар кебек,
килә сөйләшәселәр.

Рәссамны аңлаганнар бит.
Рәссам да аңлый алган.
Рәссамны үлде димәгез,
рәссам ул монда калган.

...Ага Чулман, ага Кама,
ага пароходлары.
Ага еллар... Озатып тора
Шишкинның наратлары.

1989

## Тетрәгән җир

Көтмәгәндә бу Җир
кайчак убылып китә.
Ил кайгыга бата —
бер тетрәве җитә.

Йә чайкалып куя,
йә селкенеп ала.
Шәһәр торган җирдә
хәрабәләр кала.

Булганы юк аның
тыныч торган чагы.
Кайный Җирнең каны,
кайный Җирнең җаны.

Тетрәндердек Җирне
үзебез дә шактый.
Аның кайтавазы
рәхмәт булып кайтмый.

Телгә килер тагын —
тетрәр кайсы якта?
Җир тетрәүләр безгә
җавап булып кайта.

Тетрәр чагы аның,
тетрәр чагы бигрәк.
Кеше — Җиргә бәла,
кешегә Җир кирәк.

Тетрәсә дә бу Җир
кайсы төбәгендә,
тетрәү үзәкләре —
кеше йөрәгендә.

1990

## Ирләр елый

«Елыймы ирләр?» — дисәгез,
сорагыз, әйтер сезгә...
(Аңлашылып бетмәс, бәлки,
җансызга, бәгырьсезгә.)

Әйтер сезгә Әфганстан,
әйтер Пишаварлары...
унсигез яшьлек улларын
югалткан аналары.

Керегез госпитальләргә:
егетләр нык хәтерләр.
Ирләр елыйлармы бүген?
Инвалидлар әйтерләр.

Мәет булып кайтканнарның
тыңлагыз каберләрен,
исән-сау кайтканнарының
җаннары җәберләвен.

Күрделәр алар үлемне,
үтерүне күрделәр.
Иптәшләрен генә түгел,
җанны ярып күмделәр.

Бармадылар бәхет эзләп, —
Илдә урын тармыни?
Үлем алып баручыга
читтә тормыш бармыни?

Унсигез яшьтә уйланмый —
кеше гомере бер генә.
Шул бер гомер күпме тора:
алар шуны белделәр.

Еламый дип беләсезме
Әфганның егетләре?
Илгә тешләрне батырып
суырдык җелекләрен.

Елады безнең малайлар,
елады безнең ирләр.
Бәгырьсезләр аркасында
елады безнең җирләр.

Коточкыч булыр иде ул,
егетләр еламаса.
Үлем түгел, үтереш бит!
Мөмкинме еламаска?!

Еларга кирәк, еларга.
Елау көчсезлек түгел.
Елый-елый үсә кеше,
елап чыныга күңел.

Күз яшьләренә буылып
елый-елый аттылар.
Күз яшьләрен сөртә-сөртә
олыгаеп кайттылар.

1989

## Каргыш

Бәхет шунда, дисәң,
эзләп китә.
Җирнең кырыена җитә ул.
Утка салыр үзен —
бәхет эзләп
теге дөньяга да китә ул.
Алдаганнар аны гомер буе,
алып барабыз, дип, бәхеткә.
Башын салган
йә бәхетсез калган,
юлбашчысын илткән тәхеткә.
Бер кешене алдау кыенрак.
Кеше уйлый.
Көтү — дивана.
Бергәләшеп үтерүләр ансат,
тик «дошман»ын күрсәт син аңа.
Күршесенең йортын күрше яккан.
Бертуганы аткан туганга.
Ата улын аскан,
ул — атасын...
Бәхет кенә аннан булмаган.
Яңа тормыш!..
Яңа кеше!..
Ирек!..
Янып торган сүзләр ут булып.
Халыкларның йөрәгенә кергән
агуланган зәһәр ук булып.
Агуланган кеше,
ил,
җәмгыять.
Агуланып каннар акканнар.
Аерып кара илнең кан елгасын —

кайда кызыл,
кайда ак каннар?!
Гөнаһсыз җаннар каберлеге —
бу җир тора кат-кат үлемнән.
Йөз меңләгән кеше белән бергә
илнең рухы,
җаны күмелгән.
Уйнаганнар «бәхет» сүзе белән:
бәхетеңне әнә кем алган.
Кырылышкан халык.
Дәүләт ауган.
Йә, бәхетле булып кем калган?!
Җәза булып кайта бүген шулар —
җиңү итеп аны без алдык.
Каргыш булып кайта бүген шулар —
күтәрергә аны без калдык.
Язмышы дип карый әле кеше.
Ялгыш дими.
Әле куркыта.
Баласына,
безне мактый-мактый,
изге китап итеп укыта.
Күп ашады черек бәрәңгесен,
мана-мана тозсыз сүзенә.
Якты көнгә пәрдә булып тора
трахомасы халык күзендә.
Тәннәр тоткын.
Рухыбызда ачлык.
Көтүлекләр иркен —
азык юк...
Җан ишетми —
чукрак —
аның өчен
юк мәрхәмәт,
савап,
язык юк!
Алып кереп китте сусыз чүлгә
әкият-идеяләр ярышы.
Өрәк сыман тора ил өстендә
гражданнар сугышы каргышы.
Бер гаепсез атылганнар каргый.
Асылганнар каргый дарлардан.
Җирдән килә каргыш,
Күктән иңә —
кан исләре килә карлардан!
Шартлау булып килә бүген каргыш.
Сугышалар илдә халыклар.
Берсен берсе ата,
аса,
суя...
Бу гөнаһны кемнәр ярлыкар?
Ишетелә бүген кан авазы:
нинди җанның сызлый ярасы?
Әллә һаман илнең кайтавазы,
әллә инде бүген яңасы...
Шомландыра,
офыкларга баксаң,
алсу болытларның агышы...
Кан куера —

кызылая бара
офыкларда кояш баешы...

1991

## Гомерлек сорау

Кайлардан килде ул безгә?
Инде күптәннән таныш.
Гомерең буена бара
һаман шул бер уй-сагыш.

Елдан-ел ныграк бәйләнә —
тыныч көннәре сирәк.
Кеше дә бер, гомер дә бер —
язмышны аңлау кирәк.

Кемнәр без? Кайдан киләбез?
Юллар кайсы тарафка?
Аңлап булмый, белеп булмый
артка, алга карап та.

Ниләр көтә илне-җирне,
кешелекне ни көтә?
Менә шушы билгесезлек
бүген җанны өшетә.

Яшибез кебек. Әллә соң
белмичә яшәп була?
Гомер үтә, кичләр була,
җавапсыз көннәр туа.

Без кая таба барабыз? —
Алда шул сорау тора!

1990

## 1991 ел язы

Язлар алар сөю алып килә.
Гомерләрне матур итәләр.
Яратулар алып киләләр дә,
мәхәббәтле итеп китәләр.
Куанычы белән килә язлар.
Кайгылардан кеше арына.
Күңелләре сүнгән кешеләрнең
күңелләре язда кабына.
Язлар алар саулык алып килә.
Чир-хасталар китеп торалар.
Баш калкытып куя, язлар җиткәч,
күздән корып калган куралар.
Кояшына битен куя-куя
җылыналар кышын туңганнар.
Халыкларның бөек кешеләре
язгы көннәр белән туганнар.
Язлар алар бәхет булып килә.
Җылы булып,
якты нур булып.
Башын игән бик бәләкәй җан да
бер тураеп китә,
зур булып.
Барысы да барыбызга да бит.

Барысы да моның бушка бит.
Яз көнендә җирдә адәмнәргә
сөенергә Ходай кушкан бит.
Яз быел да килде.
Елдагыча,
күңелләрдә шатлык булмады.
Көннәре дә салкын,
кояшның да
сүлпәнрәк иде нурлары.
Язлар белән бергә хәсрәт килсә,
хәерлегә булмас ул гамәл.
Илебезнең ярлы бәндәсенә
кояш нуры бүген бик хәләл.
Яз көнендә кирәк миһербанлык.
Кайгырту һәм сөю,
сабырлык...
Ярамыйдыр якты яз көнендә
кешеләргә салу авырлык.
Яз килә ул,
син кем генә булма,
синең кемлегеңә карамый.
Кешеләргә язда шатлык кирәк,
кимсетергә язда ярамый!
Ярамый!

1991

## Уй

Яши алмый икән шунсыз кеше —
уйлау икән аның иң төп эше.
Киләчәген айкый кабат-кабат,
бүгенгесен уйлап, артка карап.

— Миндә генә уй, — ди, — миндә генә...
Төкерә ул кайчак синдәгенә.
Бетерәсе килә уйны уйлап.
Бер генә бит үтә гомер буйлап.

Уйлый кеше, уйлый гомер буе.
Үзеннән соң кала шул ук уе.
Бер гомерен яшәп кеше китә...
Калган уе мең гомергә җитә.

1988

## Ямьсез көннәр

Дөнья ямен эзләп йөри идем
сандугачлар кунган таллардан.
Эзли идем гомерләрнең төсен
кояш баешыннан,
таңнардан.
Табигатьтә генә түгел икән
дөнья ямьнәренең бизмәне.
Кешеләргә баксаң,
күренә икән
дөньяларның ямьнән бизгәне.
Кешеләрнең елмаюы сүнсә,
ямьсезләнә тормыш,

сүрелә.
Кеше матур булган чакта гына
дөнья матур булып күренә.
Табигатьнең ямьсез вакыты юк,
ямьле,
гүзәл була көзен дә.
...Карашлары сүнде кешеләрнең,
нурлар бетте кеше йөзендә.
Ник елмайсын берәү!
Йә еласын!
Йә шаркылдап берәү көлсен лә!
Шауламый да кеше,
дауламый да,
кеше бары авыр көрсенә.
Каный йөзләр,
кемдер төртеп екса,
тыныч кына атлап барганда.
Бер дә матур түгел икән дөнья,
халык мескен булып калганда!
Караңгы көн.
Ямьсез көннәр җитте.
Тоймадык та гомер үтүен.
...Ургыла да ага,
ага авыр болыт,
хәтерләтеп сарык көтүен.

1991

## Кайтабыз...

Кайта идек.
Капка ачык.
Күзләрдә — безне көтү.
Мәгънәләр бүтәнчә иде...
Бүтәнчә гомер итү...

Әни исән чакта һаман
без әле бала икән.
Олгаеп җиткәч тә кеше
бер ятим кала икән.

Бушлык җанга авыр икән...
Әни урыны буш тора.
Ничә еллар шушы бушлык
йөрәкне авырттыра.

Көтәбез кайтыр көннәрне —
туган бишек кадердә.
Ачык капкаларны үтеп
кайтабыз шул кабергә...

1991

## Татар көрәше

Йомшак тастымалын билдән урап
иплән кенә ала.
Чалкан ятып кына күтәрә дә
иплән кенә сала.

Бәрелмәсен, җайлы гына ятсын,
сырты тисен җиргә.
Аяк чалып өскә авып түгел,
чиста итеп җиңә.

Көрәшәләр баш аркылы гына,
кануннарны саклап.
Ак сакалын селкеп судья тора
гаделлекне яклап.

Тормышта да шулай. Гаделлек дип,
дөреслек дип яндык.
Гомер буе кемдер сызып куйган
юлдан гына бардык.

Көрәшкән дә булды, егылдык та,
һәм ышандык бүген:
аяк чалып екканнар бит безне —
көрәш дөрес түгел!

Аякланып, билләр язылганчы
әле җаннар сыкрар.
Эзләп кара көрәш гаделлеген —
җиргә тигән сыртлар.

1990

***

Мөстәкыйль һәм үзебезгә үзебез
хуҗа кебек булып йөрибез.
Кемнәргәдер нидер аңлатабыз,
акыл сата-сата йөдибез.

Әллә нәрсә генә йөртә безне.
Алып китәр микән кайларга?
Юк!
Кешегә ирек бирелмәгән,
хокукы юк аның сайларга.

Аңлыймы соң кеше үзен-үзе?
Үзен-үзе кеше күрәме?
Мең бәлагә,
мең хәсрәткә тарып,
үзен-үзе белми үләме?

Мин: беләм, дим.
Аңлыйм, дигән булам.
Гомер буе шулай алдашам...
Инде күптән даһи булыр идем,
мин үземне-үзем аңласам.

1990

## Гомерлек томан

Ачылып кына китте көннәр, дисең —
офык чиста сыман,
кай арада,
каян килеп чыга? —

каплап ала томан.

Бер таратып ташлар иде, бәлки, —
җилләре дә тынган.
Тынны кысып,
тәнне изеп тора
авыр,
салкын томан.

Кайсы якка иде әле юллар?—
Аңлый алмый торам.
Кая Кояш?
Кая көне, төне? —
Артта,
алда — томан.

Күнегәсе иде...
Без бит юкса
томаннарда туган.
Гомерлектер,
мәңгелектер инде
безне баскан томан.

Кайда дәва,
кайда чиста һава? —
Сызлый намус,
иман...
Тирә якта гына түгел шул ул —
җаныбызда томан!

1992

## Уйлап баксаң...

Тыныч булган әле табигатьтә —
бер кеше дә Җирдә булмаган.
Бәхетенә каршы,
ул вакытта
Җирдә әле кеше тумаган.
Кайчан туган?
Кайда туган кеше?
Бик телибез шуны белергә.
Ничә буын үзен багышлаган
шушы сергә үтеп керергә.
Ул да зарур.
Аныкларга кирәк:
кем баласы,
нинди заттан без?
Галәм биек әнә,
Күкләр биек,
ә үзебез кайсы каттан без?
Дөрес булмас ләкин,
гомер итсә
бүгенәнә кеше уй-гамьсез.
Җир дә матур юкса,
дөнья матур.
Әллә нәрсә генә бик ямьсез.
Без кем идек кичә?
Бүген кемнәр?
Кеше булып инде җиттекме?
Берәр ялгыш беләнән
әллә инде

кешедән дә узып киттекме?
Инде шактый гомер итәбез бит.
Яшәдек бит инде бу йортта.
Үлемнән дә калдык,
гомерләрне
кыл өстенә кайчак куеп та.
«Тормыш!» — дибез.
Карыйсың да аңа,
тирән кайгы теләә бәгырьне.
Булыр кебек иде
бик тә гадел,
бик тә гүзәл,
бик тә кадерле...
«Кеше!» — дидек.
«Бөек!» — дидек аны.
Иң гүзәл зат!
Камил!
Илаһи!
Үзебезне-үзебез күккә чөйдек:
галәмнәргә киттек —
без даһи!
Шушы даһи бүген ыштан ямый.
Бөтен гаме тамак хакында.
Хәер сорап чират көтеп тора
зыялылар ишек катында.
Үзен-үзе талап гомер итә
табигатьнең шушы җанвары.
Рухың тузса,
ямау салып кына
саклап булмый икән җаннарны.
Ни китерде?
Алып килде кеше?
Дөньялыктан үзе ни алды?
Кемнәр санар,
кемнәр барлар икән —
дөньялыкта безнең ни калды?
Бер сүзе юк.
Дәшми кеше бүген.
Бернәрсәдә аның эше юк.
Бер уйласаң,
кеше бар да кебек...
Бер уйласаң...
һаман кеше юк.

1991

***

Бу күкләрне нигә ачтың миңа?
Йолдызларны нигә күрсәттең?
Уй-сагышлар, ашкынулар икән
яшәргә дип биргән рөхсәтең.

Бер сәбәпсез җаннар ашкынмыйдыр.
Сәбәпләрен кайдан эзләргә?
Нигә йөрәк ешрак тибә башлый,
йолдыз нуры төшсә йөзләргә?

Нигә кирәк андый ашкынулар,
яшәр өчен җирдә ярасам?
Шунда менеп китәселәр килә,
күтәрелеп күккә карасам.

Мең ел элек сүнгән йолдыз яна.
Яктылыгы килә нур булып...
Бу галәмдә без бик кечкенә шул,
ә яшисе килә зур булып.

1990

## Аяк тая

Без бәхетле булган бала чакта —
«бабабыз» да булган,
«атабыз» да.
Шаккатабыз бүген,
үткәннәргә
бер әйләнеп кире кайтабыз да.
Без ничәнче буын?
Ничәбезнең
уйлар ялган,
сүзләр,
юллар ялган?
Кайда калган безнең бисмиллабыз?
Юлның башы безнең кайда калган?
Алдануны аңлау ансат түгел.
гомерләр дә әрәм,
кеше әрәм.
...Рәсеменнән көлеп карап тора
акылыннан шашкан бөек адәм.
Юл күрсәтеп тора мәйданнардан.
Киләчәккә карап кулын сузган.
Бер ыргылгач
йөгереп киткән идек...
Өерелеп калды артта тузан.
Туктап калдык.
Инде ни күрәбез,
үзебезгә-үзебез карап баксак?
Атларыбыз юлда ятып калган,
күзләребез тонган,
аяк аксак.
Адашканны дөнья көтеп тормый.
Гомер уза җирдә,
вакыт чаба.
Артта инде юллар җимерелгән.
Сукмак та юк безнең алга таба.
Безне дәшеп торган учак та юк.
Дәртебез дә сыек,
дәрманы да.
Кодрәт бирмәс кебек
Җирдән түгел,
Күктән килгән бөек фәрманы да.
Арынмасмы шулай томаннардан —
атмасмыни инде безнең таңнар?
Караңгыдан чыгып җитә алмый
таралышып бетәрмени җаннар?
Соңгы тапкыр талпынудыр безнең:
хыял кая?

Иман?
Кыйбла кая?
Аяк астын капшап атлый кеше —
аяк тая җирдә,
аяк тая...

1991

## Гафу итсен әни

Мин күрмәдем аны.
Исеме белән
таныштырды кем соң сабыйны?
Бик хәтерлим,
рәсеменә карап
«Ленин бабай» дигән чагымны.
Кем соң миңа аның исемен әйтте?
Кем соң «бабаң» диеп атады?
Ихлас җанга
ихлас дөреслек дип
кабул иттек шушы хатаны.
Әни кушты безгә.
Ул өйрәтте
«Ленин бабай» диеп әйтергә.
Шушы сүзне мәктәптә дә һәр көн
ятлап-ятлап салдык хәтергә.
Тормышта да аның белән бардык
(уйламадык һич тә тукталып),
сыннарына карап горурланып,
үзебезгә-үзебез сокланып.
Ятим идек.
Шуңадыр да еллар
безне Ленин улы иттеләр.
Ә күпмеләр
аның исеме белән
туып,
яшәп,
үлеп киттеләр?!
Мин күрмәдем аны.
Өлгермәдем.
Тарих көтми килер буынын.
Күп өлеше аның исеме белән
үтелгән шул инде юлымның.
Уйларыбыз безнең,
юлларыбыз,
гомеребез безнең,
көнебез,
Мәккәбез дә безнең,
кыйблабыз да,
иманыбыз безнең,
денебез
Ленин иде!
Бөтен хыялларны
багышладык «изге» максатка.
Нинди даһи ялгыш!!
...Яшәүләре
бик читен дә бүген,
ансат та.
Әкренләп безнең күз ачылды.
Заманалар килде ачылып.

Аңлы-җанлы кеше үз-үзенә
хисап бирде уйлап,
ачынып.
Дөреслек тә,
ялгышлык та бездә.
Гафу итсен әни угылын.
...Үз бабасын җуйса әгәр халык,
ят бабалар ала урынын.

1992

## Безнең әкиятләр

Әкиятләр тыңлап туган идек,
әкиятләр тыңлап үстек без.
Тәүге юлыбызны яланаяк,
әкиятләр белән үттек без.
Сихерләде безне әкият сере.
Көчле итте әкият тылсымы.
...Гарьләнмәдек,
безнең ач тамакка
кадалса да арыш кылчыгы.
Мескен итеп безне санаса да,
чукыса да безне карчыга,
без үзебез күктә лачын идек, —
әкият бар иде каршыда.
Әкиятләр матур итте безне,
әкиятләр батыр иттеләр.
Бу дөньяны бераз тарсынганда,
башкасына алып киттеләр.
Дөрес түгел,
тик чын иде әкият!
Тук итәрлек иде ачны да.
...Чын булмаса,
әкиятләрнең сере
кешеләргә бик тиз ачыла.
Без ышандык аңа гомерлеккә.
Тылсым серен ача алмадык.
Алдыбыздан әйдәп әкият барды,
бер адым да аннан калмадык.
Тормышка да әкият белән кердек.
Бик беркатлы идек ул чакта.
Олы итеп каршы алды тормыш,
без беркатлы гына булсак та.
Тормышта да әкият җитә икән.
Сөйләүче дә аны күп икән.
Олылар да әкият тыңлый белә.
Тормыш үзе әкият күк икән.
Тик серләре генә бүтән икән.
Мәгънә башка.
Мәгънә — тирәндә.
Бу әкиятләр күккә алып менми,
җирдә яшәү җаен өйрәтә.
Чын әкиятләр калды балачакта,
хозурлыклар бераз кимеде.
Тыңлыйбыз да
сакал селкетәбез, —
әкияткә дә ышану ким инде.
Сагындыра мине чын әкиятләр.
Сагындыра мине шул чагым.
Сагындыра күккә карый-карый

әкият булып янган учагым.
Ачылмады тылсым,
күпме йөзеп
балачакның әкият күгендә.
Шул чактагы әкиятләрем мине
ышандыра әле бүген дә.
Тик мин һаман шуны
аңлый алмыйм:
яхшымы бу,
әллә яманмы?
Яхшыдыр күк,
әкият төзәтә алгач
әкиятләрдән алган яраңны.

1987

## Ленин мемориалы

### 1

Кодрәт җитсә,
хакимнәре Илнең
берәр һәйкәл җирдә калдырганнар.
Халык ачтан үлгән,
ә патшалар
башкалада чиркәү салдырганнар.
Ничә мең ел тора!
Хан салдырган —
мәчетләре әнә...
манаралар...
Башларына басып фиргавеннәр
пирамидалардан караганнар.
Һәрбер оста тапкан үзенекен.
Бер-беренә охшамаган бер дә.
Шуңа күрә, вакыт-чорны белми,
бөек сәнгать мәңге яши җирдә.
Вакыт үтә.
Патшалар да үлә.
Барып җитә алмый бәхетенә.
Тәхет кала.
Замананың һәрчак
падишаһы була тәхетенә.
Чиркәү...
Мәчет...
Дәүләт эше түгел.
Халык үзе аны сала бүген.
Безнең патшалардан
мәңгелеккә
һәйкәл булып
нәрсә кала бүген?

### 2

Карый Казан иске өйләреннән.
Карый Казан инде хәрабәдән,
җитмеш яшьлек карчык күзе белән
җиргә сеңеп беткән тәрәзәдән.
Фатир көтә меңнәр.
Көтә-көтә
җир астында яшәп гомер үтә.
Атасының фатир чиратлары

оныгына кадәр барып җитә.
Карый Казан мескен күзе белән
чүплектәге такта алачыктан.
Кимсетә бит безне!
Аларны да
җимерергә дигән карар чыккан.
Игенчебез килгән башкалага.
Кунак булып...
Кайда тукталырга?
Кешеләргә түгел,
күселәргә
урын иркен кунак йортларында.
Җимерек сарай ишегеннән карый,
рәссам күзе белән карый Казан.
«Казаным!» дип,
«Башкалам!» дип, шагыйрь
вокзалларда яшәп китап язган.
Бик сагынгач кына татлыдыр ул
иске өйнең иске тузаннары.
Себеркесе юк бит,
себеркесе...
Себерәсе иде урамнарын.
Нурлы Казан!
Моңлы Казан!
Аңа
нужа өстәп еллар узган икән.
Карап тора ярлы күзе белән —
Казан тузган,
Казан тузган икән!
Киң күңелле сәүдәгәрләр дә юк.
Кемнәр керсен аның хәлләренә?!
Түбәтәен сузып акча җыя
Салих Сәйдәшевнең һәйкәленә.

**3**

Бай ул безнең халык!
Дәүләт тә бай!
Моның өчен кемне кемнәр әрләр? —
Миллионнарга төшсә төшсен әйдә —
үсеп чыга бүген мемориаллар.
Мәгънәсезлекләргә акыл җитә.
Булсын бары сылтау-сәбәп кенә.
Һәрбер ташы алтын хакы тора.
Җитми аңа бары сәнгать кенә.
Монда яткан миллион сумнар кайтса,
сүтеп җыйсаң кабат,
шушы таштан
төзеп булыр иде,
Татарстан,
Тукай урамнарын яңабаштан.
Мемориалга бармый бүген кеше.
Барса бара аның каберенә.
Мемориаллар белән кереп булмый,
хаклык керә халык бәгыренә.
...Кырынаеп тора иске йортлар.
Мемориалга алар карап тора.
Талымсыз ул халык.
Аңа бүген

иске йорт та әле ярап тора.
Казан елгасыннан тауга карап,
югарыга таба барам менеп.
Мәрмәр баскычларны саный-саный...
Пирамидаларга менгән кебек.
Кабердәге тынлык мемориалда.
Таш кодрәтле.
Таш куркыта.
Көчле.
...Түбәсенә кинәт ак чапаннан
Фиргавене килеп чыгар төсле.

1990

## Бетон болгата торган машина

Шәп көйләнгән: измә изелгәнче
гел әйләнеп тора салмак кына.
Бер чуерташ сиздермичә генә
бер кырыйга төшеп калмак була.

Төшеп кала. Көрәк мәрхәмәтсез,
элеп алып тагын кире ата.
Әле генә шул измәдән каткан
бетон ташы көлеп карап ята.

1984

## Шипка

Көрәштән соң туа.
Җиңүдән соң.
Гомер иткәннән соң баш булып,
халыкларның,
илнең шәхесләре
мәйданнарга баса таш булып.
Һәйкәлләрнең төрле гомерләре.
Һәйкәлләрнең төрле язмышы.
Берәвендә —
илнең мәхәббәте.
Берәвендә —
илнең каргышы.
Кешеләрне аткан кебек, әнә
һәйкәлне дә кайчак аталар.
Кешеләрне аскан кебек, әнә
һәйкәлне дә кайчак асалар.
Көрәштән соң туа.
Көрәштән соң
мөмкин әле һәйкәл үләргә.
Ялган һәйкәлләрнең бәяләрен
туры килә илгә түләргә.
Изге була көрәш,
илен яклап,
ирек яулап халык көрәшсә.
Изге була җиңү,
онытылмый,
җиңеп чыкса халык көрәштә.

Күпме гомер шаһит булып тора
иминлеккә,
исән-саулыкка!
Мәңгелеккә куелган бу һәйкәл,
мәңгелеккә,
илгә,
халыкка!

1990

## Уяндык та...

Кайларда ул көләч йөзле еллар?
Алкышлары китми колактан.
— Киттегезме? — диләр,—
җиттегезме? —
Яулык болгый еллар ерактан.
Елларны да мандык,
юлларны да,
ыштанны да мандык кызылга.
Уяндык та...
тирән уйга калдык —
йөзләр чытык,
тешләр кысылган.
Тешне кысып гомер итеп булмый.
Инде күптән тешләр әрниләр.
Күпме еллар...
Күпме гомер шулай...
Оят безгә!
Без бит гарьлеләр.
Кодрәт кирәк.
Үтисе бар әле
замананың зарур эшләрен.
Юкса шулай
кысып яши-яши
коелып та бетәр тешләрең...

1990

## Киләчәкне уйлап

Арттагылар инде кыса килә.
Булмый хәзер юлда тукталып.
Кая таба бара —
күрә микән,
белә микән бүген бу халык?

Упкын тирән алда...
Ярлар биек...
Бер ычкынып китсәк түбәнгә,
башлар бетәр безнең —
эз дә калмас,
сөякләр дә калмас күмәргә.

Нигә сөяк?
Нигә мәет?
Кабер?
Кемгә кирәк булсын күмүләр?
Сибелербез тагын томан булып...

Яшәү булып сибелер үлүләр.

Яңа түгел.
Котылгысыз.
Безнең
кич тә булыр,
булгач таңыбыз...
Сыеп булмас Җиргә.
Галәм иркен.
Азат булыр безнең җаныбыз.

1991

## Шифа

**1**

Кирәк була, ләкин сирәк була,
була андый вакыт:
кояш көлеп тора, дөнья якты,
ургып тора шатлык.

Күпләп килгән, йөкләп килгән бәхет —
берүзеңә артык.
Бәхетнең бер тамчысы да әле
кемнәргәдер тансык.

Бер күкрәккә сыеп бетә алмый —
йөрисең ашкынып.
Артыр гамең, тынычланыр җаның —
эшлә бер яхшылык!

**2**

Бик еш була. Шактый авыр була.
Була андый чаклар.
Йә кадерлең телә бәгыреңне,
йә кимсетә ятлар.

Изә кайгы үзәгеңә үтеп,
йөрәгеңә кереп.
Җиңәреңә көчең җитмәс кебек,
мәңге китмәс кебек.

Яхшы беләм — дөм караңгы җаның
китәчәк яктырып:
мохтаҗ җаннар җитә арабызда —
эшлә бер яхшылык!

1991

## Дога

Оныттык без сине, Хак Тәгалә:
гөнаһларга батты адәмнәрең.
Ярлыкавы ансат түгелдер шул
бисмилласыз кылган гамәлләрен.

Догасыннан аерылды кеше.
Миһербанын җуйды —
савапларын...
Бәндәләргә килде авыр көннәр —
бирә инде хәзер җавапларын.

Дөнья тулды угры-карак белән.
Иярләнде яман ришвәт,
фәхеш...
Адәм бүген таныр хәлдә түгел —
үзе сәрхуш,
балалары сәрхуш...

Кая баксаң —
ага кеше каны.
Кая баксаң —
тагын ятим бала.
Кешеләрең генә түгел, Хода,
халыкларың ирсез,
ятим кала.

Кулын сала якын кардәшенә —
туган, дими,
гүя мөэмин түгел.
Имансызлар артты, шәфкатьсезләр...
Болай яшәү, Хода, мөмкин түгел.

Кичер безне!
Борыл безгә таба.
Туктата күр безнең вәхшилекне.
Соңгы өмет синдә.
Тик син генә
коткарырсың безне — кешелекне!

Кодрәтләрен ал син явызларның.
Коткара күр безне угрылардан.
Бир син безгә кабат
көч һәм куәт —
бар бит әле Җирдә тугры балаң.

Үзебезгә хуҗа булалмадык —
без яңадан синең колың булыйк.
Алла сүзе керсен адәмнәргә —
без яңадан синең улың булыйк.

Комсызларның тый син нәфесләрен,
хәрәм азык бирмә бирәннәргә.
Мәрхәмәтле бул син разыйларга —
биргәнеңә шөкер дигәннәргә.

Оятсызны, зинһар, узындырма.
Бирмә ирек артык әрсезләргә.
Тыйнак җаннар шактый кыйналдылар —
сихәт кирәк хәзер хәлсезләргә.

Гөнаһларны безнең кичерә күр.
Алдык бугай инде җәзаларын...
Син күрсәтмә инде яңаларын
без күрмәгән бәла-казаларның.

Шунысын да сорыйм синнән, Хода:
тигезләп үк тәмам бетермә син.
Кеше итеп үзең яраткансың —
мескен итеп аны үтермә син.

Дөньялыкның кырыс кануннары:

канатларны безнең каермакчы.
Иң заруры —
илгә Иман кирәк!
Изге Иманыңнан аермачы.

Какшамасын өмет!
Кодрәт кирәк.
Вакыт җитте безгә уяныргга.
Хак Тәгалә!
Коткар җаныбызны:
ярдәм ит син безгә
инаныргга!

Барып җитсен иде сиңа берүк,
кабул булсын иде шушы догам.
Башларымны күккә бәрә-бәрә
сорыйм синнән,
сорыйм синнән, Ходам!

1992

## Юлда

Арган гына атлар...
Арган гына...
Туарылган әле атларыбыз.
Бөтенләйгә туктап калу түгел,
хәл алырга яткан чакларыбыз.
Сулыш алу гына —
юлда күптән.
Йөз елын да,
мең елын да үткән.
Бара-бара шактый ерак киткән.
Көчне,
тирне,
канны шактый түккән.
Туктый-туктый кәрвансарайларда,
ераклардан килә олы кәрван.
Үтелмәгән әле озын юлы,
үтәлмәгән әле олы фәрман.
Юл газабы авыр.
Маңгайларга
чыккан иде салкын тирләр булып.
Тирләр кипте,
хәлсез чаклар үтте,
малайлар да җитте ирләр булып.
Юллар сикәлтәле.
Йөзәр елга
сабырлыклар тагын кирәк алда...
Атлар түзәр.
Барып җитәр кәрван
мең ел әрнеп янган йөрәк барда.
Кичерелмәс!
Юк та безнең,
булмас
ярты юлда туктар хакларыбыз!
...Кузгалырга вакыт,
юл ташына
тоякларын бәрә атларыбыз.

1991

## Яшик...

Меңәр еллык тарих та бар.
Исем дә бар, ат та бар.
Милләт тә бар, халык та бар,
хокук та бар, хак та бар.

Инде без ярлы да түгел,
үтте бездән фәкыйрьлек.
Инде без мескен дә түгел,
горур диеп әйтерлек.

Барысы да үзебездә.
Бөтенесе бирелгән.
Әллә нәрсә эзләгән күк,
башлар гына иелгән.

Түбән карап эзлибезме? —
Яшик лә ансыз гына...
Милләт бөек, халык бөек,
бары тик сансыз гына.

1989

## Яшел байрак

Зур түземлек биргән безгә Ходай.
Сабырлыклар иңгән безгә Күктән.
Бәлки, безне шулар саклагандыр...
Вакыт җитте ләкин, җитте күптән.
Капка ачып беркем көтеп тормый
бүген безгә бәхет өләшергә.
Соңгы өмет, соңгы талпыну бу —
көрәшергә, бары көрәшергә!
Туры юлдаш булсын эшләребез.
Ихлас була күрсен сүзләребез.
Элсәләр дә алга кара пәрдә,
үтә күрсен безнең күзләребез.
Һәр милләтнең була көчлеләре.
Һәр халыкның була батырлары.
Көрәшләрнең башы гел бертөсле.
Төрле-төрле була ахырлары.
Батырларга гына ышану ялгыш.
Көчлеләргә генә ышану ялгыш.
Зәгыйфьләр дә көрәшергә тиеш —
барыбыздан тора безнең язмыш!
Күтәрелде ил-йорт түбәсенә
барча туганнарга дәшәр өчен.
Без күтәрдек аны туган җирдә
хөр мәмләкәт булып яшәр өчен.
Азат булыр җан да,
тел дә,
ил дә —
ахырына кадәр бергә барсак.
Кадап куйдык туган-үскән җиргә —
җилфердәсен мәңге яшел байрак!

1991

## Кайтыгыз!

Сылтамыйм җилләргә, давылга —
козгыннар канатны каерган.
Язмыш та,
ялгыш та түгел ул —
дошманнар туфрактан аерган.
Кайларда калмаган эзебез?!
Яманат ияреп бармаган.
Саклады нахактан,
яладан —
аңнары булганнар аңлаган.
Тарихка язылган пакь булып.
Без кая барсак та таныrлык.
Исән-сау илебез-җиребез:
үтерә алмады —
тамыр нык.
Ыруы,
нәселе моңнарын
йөрәктә саклаган кайсыгыз?
Читләрдә үксезләр булмагыз —
кайтыгыз, кардәшләр,
кайтыгыз!

Ничә кат егылдык?!
Тордык без.
Ничә кат йөзләрне канаттык?!
Коллыктан котылып барабыз...
Азатлык!
Бары тик азатлык!
Каныбыз,
җаныбыз кушканча
ыруның теләген үтәдек.
Билләрне турайтып бастык та
Дәүләтнең байрагын күтәрдек.
Тел дә бер,
дин дә бер,
ил дә бер —
дөньяга сибелеп ятабыз.
Һәркемгә ирешсен бу хәбәр:
мөстәкыйль дәүләтле татар без.
Исәндер сагыну-сагышлар...
Ватансыз тора алмый кайсыгыз?
Туйгансыз читләрдә каңгырып —
кайтыгыз, кардәшләр,
кайтыгыз!

Авыр юл,
озын юл башы бу.
Өметле булса да тар әле.
Алданган,
урланган җаннарны
яңадан яулыйсы бар әле.
Тапталган телебез,
сүзебез...
Җаныбыз,
рухыбыз таланган.
Тупланып,
берләшеп чыгарга
кирәк шул бу авыр заманнан.
Шулай да
гөнаһлы булырбыз,

бик шөкер бүгенгә, димәсәк.
Үткәнне кадерлик,
дәүләткә
иминлек бирә күр,
киләчәк!
Горурлык яшьләрен тыялмый,
«Илем!» дип куана кайсыгыз?
Киләчәк көнебез хакына
кайтыгыз, кардәшләр,
кайтыгыз!

1992

***

Диңгезләргә күңел ашкына ул.
Тауларга да күңел ашкына.
Нәрсә тарта, диеп карап торам,
бер уйласаң кыя таш кына.

Мәгърур алар.
Чиксез.
Шуңа тарта.
Мин инде аны күптән аңладым.
Аңладым да...
тавын,
кыяларын
һәм диңгезен
болай алдадым:

Килдем, дидем, менә тагын сагынып
тауларыңа,
диңгез ярыңа...
...Ә бер айдан,
чынлап торып сагынып,
кайтып киттем Туган ягыма!

1986

## Татар җыры

Бик өшегән,
туңган еллар булды:
җаныбызга синнән алдык җылы.
Милләтеңә сүнмәс өмет бирдең —
рәхмәт сиңа,
рәхмәт,
татар җыры!

Син — халкымның сагыш-газаплары.
Син — халкымның тирән маңгай сыры.
Кайгыларга баш имәгән өчен
рәхмәт сиңа,
рәхмәт,
татар җыры!

Мәхәббәтле,
саф һәм мәрхәмәтле
күңелләрне җырлар бергә җыйды.

Игелекле иттең халкыбызны —
рәхмәт сиңа,
рәхмәт,
татар җыры!

Саклап калдың җанның азатлыгын —
илебезгә килде ирек чоры.
Моңлы иттең,
уйлы-гамьле иттең —
рәхмәт сиңа,
рәхмәт,
татар җыры!

Байрагыбыз булып яшә һаман:
бушамаган әле көрәш кыры.
Син бүген дә көч бир рухыбызга...
Рәхмәт сиңа,
рәхмәт,
татар җыры!

1992

## Ваклык турында

Йөрәкләргә якын ала калсаң,
бу тормышның җитә чүп-чары.
Барысын да җыя алмый кеше,
тик бер генә яши ул бары.
Яшәеше шундый:
тормыш бара
гаепләнеп яки акланып.
Шуны гына уйлап яши калсаң,
гомерләрең үтә вакланып.
Миңа да бит кагылгалый ул чир.
Хәзер аннан бик тиз тереләм.
Ваклыкларга —
шундый серен беләм —
түләү кирәк икән эредән.

1987

## Шүрәле

Төрле халык монда.
Төрле милләт.
Төрле телләр.
Хисләр төрледән.
Ник зал өнсез? дисәм...
чыгып килә
шүрәлебез сәхнә түреннән.
Гомер итте урманнарда яшәп,
халыкларда бала куркытып.
Урманнардан Тукай алып чыкты,
арык җилкәсенә утыртып.
Күрә торып шуны,
ничек итеп,
гаҗәп могҗиза бит, димисең?!
Дөнья буйлап йөртеп кара әле

гастрольләрдә урман иблисен.
Тагын бер кат карап утырдым мин
халкым, үзем өчен шатланып,
Тукай белән ихлас горурланып,
Тукай белән эчтән мактанып.
Чыдый алмас иде Тукай җаны,
үзе монда булса ул әгәр.
Алкышлардан һава кызды залда,
җилфердәшеп торды пәрдәләр.
Халыкларның изелгәне дә бар.
Бар халыкның түрәлесе дә.
Дөнья сәхнәләрен тота ала
бу халыкның шүрәлесе дә.

1989

## Күптәнге хакыйкать

Үтә икән бөтен кичергәннәр,
вакыт ала икән.
Тик шулай да, алар үтеп киткәч,
нидер кала икән.

Бөтенесе үтә безнең аша
яхшы, яман булып.
Бөтенесе кала яки дәваң,
яки яраң булып.

Мәрхәмәтең, изгелегең кала
җанда балкыш булып.
Җирдә кылган бөек эшең кала
күктә алкыш булып.

Сакламасаң, киткән мәхәббәтең
сагыш булып кала.
Кешеләрне рәнҗетәсең икән —
каргыш булып кала.

Кимсетсәләр сине бер дә юкка —
җанда кала ачу.
Гаепләсә сине кемдер юкка —
җанда кала ярсу.

Кешеләрнең хыянәте кала
синдә нәфрәт булып.
Якыннарның бәхетсезлекләре
кала хәсрәт булып.

Бер яхшылык эшли сиңа кемдер —
рәхмәт кала аңа.
Тик бер шырпы сыза, шул йөрәктә
гомер буе яна.

Аңламасак шуны,
бу хакыйкать күптән таныш булып,
яшәвебез безнең, гомеребез
калыр ялгыш булып.

1987

## Тагын туган як турында

Китэбездер кирэк булган өчен,
сагынулар безне кайтара.
Туган җирләр генә исән булсын,
җаны барлар илгә кайтала.

Көфер тоелса да...
уйлап куям:
мин бит синнән дөрес киткәнмен.
Белмәс идем шунсыз
туган җирне
сагынуның нәрсә икәнен.

1987

## Кабер ташы

Өлге —
күчәр башы.
Биек булса,
тигезләгән —
башны кылыч алган.
Белгән залим,
болгар баласында
атасының җаны,
аңы калган.
Бишектәген сугышчысы иткән —
безгә төбәп шунда мылтык корган.
Киләчәккә җәллад әзерләгән —
Илен,
Җирен,
Телен оныттырган.
Көчләп таккан динен —
кяфер иткән, —
кереп киткән халык бәгыренә.
Аскан,
кискән —
тере халык беткән —
төшеп җиткән халык каберенә.
Кабер ташын —
Болгар һәйкәлләрен,
йолкып үлгәннәрнең күкрәгеннән,
канга манып,
чиркәү ташы иткән,
сөякләрне сытып күтәрелгән.
Нигезенә салган түшәп-түшәп.
Тартынмаган!
Ә бит кабер ташы!
Тотып торсын аның кара данын
Болгар ташы —
мәгърур Татар башы!
Залим кансыз!
Халык та юк аңа,
бала да юк,
ата,
ана да юк!
Ирек бирсәң,
түшәр кемнекен дә —

мәлгунь өчен дин дә,
Алла да юк.
Карап ята сыкрап.
Зиндан сасы.
Болгар ташы чиркәү асларында.
Йолкып атасы бар —
тәре үскән
бабайларның кабер ташларында!

1991

## Изге иман

Без бик озак башны иеп яши килдек.
Мескен идек, ятим идек — дучар идек.
Иманыбыз саналмады мөстәкыймьгә*.
Кайда мөбин**? Догабызны кылыйк кемгә?

Урын бетте горефенә вә гадәткә.
Мәчет тә юк, михраб та юк гыйбадәткә.
...Башыбызны күтәрдек тә тәүбә кылдык —
йә Ходабыз, ярлыка, дип, мәчет кордык.

Интексә дә мөэмин халык, сабыр гавам,
сарыф түгел сабыр заман — сынау, дәвам.
Өмет бирде, суытмады каныбызны —
Хак Тәгалә йолып калды җаныбызны.

Ирешкәндер рухыбызның кыйналуы,
кабул итте тәүбәбезне, инануны.
Зур интизар белән көткән идек күптән:
Ходабызның мәрхәмәте иңде күктән.

Югалмады кыйбла. Кавем адашмады.
Югарыда, күктә бүген карашлары.
Халык тугры дененә дә, диненә дә,
күк капуы ачык газиз иленә дә.

Артта калды денсез көннәр һәм җәһәннәм:
мәчет сала һәрбер авыл, һәр мәхәллә.
Изгелеккә күңел ачык, йөрәк ачык.
Ай-манара күтәрелә күккә ашып.

Хак Тәгалә рухыбызга куйды канат,
барча мөэмин кодрәт ала күккә карап.
Кардәш, инан, адәм, инан, халык, инан!
Шөкрана, исән-имин изге иман!

1993

## Бүген Болгарда

Киләбез дә...
карап уйланабыз...
Бу ташларның нишләп сүзе юк?
Капкалар да ачык.
Ишекләр дә...
Нишләп әле хуҗа үзе юк?

Музейларда нинди хуҗа булсын?
Булмаганны исән йортында...
Болгар нигезләре ни сөйләсен? —
Тыңлаучылар бүген йокыда...

Көннәр аяз.
Күкләр зәңгәр, биек...
Сулар тыныч ага Болгарда.
Төрле уйлар килә
бүген моннан
киләчәккә карап торганда...

Шушы хәрабәләр булганда...

1987

## Акылдан язган рәссамнар күргәзмәсе

Акыл белән туа,
килә кеше.
Акыл белән хаким булып ала.
Реакторда атом янган кебек,
башларында аның акыл яна.
Үлемне дә җиңә акыл белән.
Гомерне дә җиңә —
атыла да.
Акылга да утырта ул яшәү,
яздыра ул кайчак акылдан да.
Бирелсә дә күпме,
үзе генә
бөек итә алмый шәхесләрне.
Беркайчан да алыштыра алмый
җанда ургып яткан уй-хисләрне.
Безнең акыл камил.
Фикерлибез
яшәү, тормыш, дөнья, ил хакында...
Акылыннан язган очракта да,
мохтаҗ түгел даһи бу акылга.
Табигать сау:
үлән, яфрак исән;
язлар, җәйләр —
төсләр уйнап тора...
Бетмәгән бит әле кешеләрнең
гаме-зары —
төсләр уйлап тора...
Көрәшәләр төсләр...
Күңел арган...
Уйларының талган канатлары.
Бер почмакта акыл посып калган.
(Эзәрлекли акыл талантларны.)
Яраларга мөмкин,
үтерергә...
Кадерләрен белми кеше аның.
Акылыннан яздырырга һич тә
мөмкин түгел икән кеше җанын.
Кала икән барыбер үзе белән,
кеше ничек кенә булып үзгәрсә дә.
Акылыннан язган рәссамнарның
ярылып ята җаны күргәзмәдә.

1991

***

Икесе дә әйбер кебек.
Икесе дә хуҗа шуңа.
Яратулар картайсалар,
хуҗа булу хисе туа.
Уйлау туа, минеке, дип:
алып була, куеп була;
бәгырьләрне телеп була,
бер-береңнән туеп була.
Гомерләрнең ахырына
бара алар парлап кына.
Юлда төшеп калмасын дип,
берсен-берсе барлап кына.

1988

***

Көннәр туа.
Безнең көннәр туа.
Үткәннәрен озатып каласың.
Бик беләбез
туган көннәр белән
гомерләрнең кая барасын.
Көннәр безгә,
шөкер,
буш килмиләр,
уйландырмый гына китмиләр.
Йөрәкләргә кирә,
җаныбызга —
кояш нурын әрәм итмиләр.
Гомер безгә күптән бирелгән ул.
Күптән куйган инде исәпләп.
Көннәр алар гомер алып килми,
алып кына китә кисәкләп.
Яна кояш...
яна көннәр,
гомер...
Исәндер без — янып,
яндырып...
Нәрсә ала,
үзе нәрсә таба —
китә барысын да калдырып.
Килер бер көн...
Безне килеп алыр...
Җисмебезне кире кайтармас.
Сез карагыз —
балкып Күктә калыр —
безнең җаннар китмәс,
картаймас!

1987

## Шул ук Туфан

Шагыйрь юлы кереп китә
халыкның юлларына.
Шушы юллар белән менә
бу халык югарыга.

Үзем беләм, үзем уйлыйм:
Туфан үткән юл микән?
Үз-үземә сорау бирәм:
бусы тагын ул микән?

Барлап кара, санап кара —
ышансаң ышан инде.
Гомер дә бер, язмыш та бер —
шул бер үк Туфан инде.

***

Уйлар өермәсе башта.
Уйлар-хисләр тынгысыз.
Дөньялык дип үтә көннәр.
Төннәр-төшләр йокысыз.

Хас түгел шул сабырлыклар
шагыйрьләрнең холкына.
Шигырь тулы йөрәк яна.
Күңел кая талпына?

Аксубай да Казан гына
түгел бит әле илдә.
Такташ йөргән Донбассын да
барып күрәсе килә.

Самолетта түгел Туфан.
Туфан ике аякта.
Җегәр житә, ышаныч бар
кулга тоткан таякта.

Чиксезлеге дәшә җирнең.
Сулар, таулар, далалар...
Сулар ага. Ярларында
төнлә учак ягалар.

Шахтерлар да безнең кебек —
рудалар да тирәндә.
Табып булмый ятып кына
аунап яшел чирәмдә.

Күкрәктә моң. Изүләргә
яңа җилләре тула.
Тар бүлмәдә туа алмаган
шигырьләр юлда туа.

Бу сәяхәт — дөнья күрү.
Тормышны, илне тану.
Кеше гаме — дөнья гаме.
Яшәү бу, яшәп яну.

Белми Туфан, белми әле —
«сәяхәтләр» алда шул.
Язмышлар Алла кулында.
Кемдә власть — Алла шул.

Ә бүген җирнең ямьнәрен,
яшәү гамьнәрен тойган.
Халыкның шагыйре булып
ил гизеп кайта Туфан.

Шагыйре Хәсән Туфан.

***

Кемнәрнең акылы җиткән?
Кем шуны уйлап тапкан?
«Илем! Халкым!» дип янулар
аңа ни булып кайткан?

Җинаятьче син бүгеннән.
Үзең яшереп яткан.
Әз дә түгел, күп тә түгел —
син үз илеңне саткан!

Нинди шагыйрь?! Шпион син!
Илнең явыз дошманы!
...Күпме торган? Күпме тора
илдә шагыйрьләр каны?

Кем ышана ала моңа,
әгәр бер рәткә куйсаң?
Ярлык сугылган. Язылган:
«Шпион Хәсән Туфан.

Сатлыкҗан Хәсән Туфан».

***

Шагыйрьнеме, шигырьнеме —
кемне монда ябалар?
Икесе дә бер җанда шул —
икәү бергә яналар.

Нарасый җан. Эзли, тапмый:
гаепләре нәрсәдә?
Стена нык, ишә алмый,
башын ташка бәрсә дә.

Уйландыра, камерада
төннәрен ялгыз калгач:
Кайда дәлил?! Мохтаҗмыни
дәлилгә берәр палач?

Укылган судның карары.
Шагыйрь йөрәге туңган.
Стенага терәп куеп
атылган шагыйрь Туфан.

Атылган Хәсән Туфан.

***

Дошман көлсә, усал көлә:
башка зәһәр тапмаган,
баш очына өскә аткан,
ә шагыйрьне атмаган.

Бу язмышны каргый-каргый
күпләр инде үткәннәр.
Кайтмаска дип бу юллардан
күпләр инде киткәннәр.

Сөенде микән котылып
үлемнән кичә генә?
Үлем әле килеп китәр
ничәмә-ничә генә.

Бер килеп кенә карасын
синең янынга гына.
Үлем ул әрсез, онытмый,
үлем каныга гына.

Сөенгәндер. Бар бит әле
алда киләсе көннәр.
Шагыйрьдә дә берәү генә,
бер генә бу гомерләр.

...Дошман көлсә, усал көлә:
шагыйрьне илдән куган.
Кичә үлде. Бүген инде
этапта бара Туфан.

Арестант Хәсән Туфан.

***

Каткан ипи катысы да
булган чакта бик тәмле.
Туган яктан искән җил дә
җылытмый суык тәнне.

Кием тузган. Ни җылытсын,
өшеп, бозланып туңсаң?
Әрни-әрни урман кисә
ачыккан, хәлсез Туфан.

Каторжан Хәсән Туфан.

***

Дөнья иркен, дала иркен,
үләннәре дә мулдан.
Сыер көтү — шагыйрь эше,
килә ул безнең кулдан.

Ямаулык та табып була.
Инде ялангач түгел.
Сөте дә бар, ипи дә бар,
шагыйре дә ач түгел.

Карандаш та, кәгазь дә бар.
Күңел дә көр — аз гына.
Күз алдында туган җирләр...
Елый-елый яз гына.

Кем ялгыша? Туфан булып
дөньяга шагыйрь туган.
Ә дөньяга кирәк икән
бары көтүче Туфан.

Көтүче Хәсән Туфан.

***

Дөресли, дөрес йөрмәсә,
төзәтә ватыкларын.
Төзәтеп булмый икән шул
заманын, вакытларын.

Булмый ул көнне, елларны
чыгарып атып кына.
Төзәтә ала бары тик
вакытны вакыт кына.

Бирешми әле бу йөрәк.
Тынгысыз һаман бу җан.
Терелеп китә кулында,
сәгать төзәтә Туфан.

Сәгатьче Хәсән Туфан.

***

Ялгыз башка, ялгыз җанга
болар бик күп түгелме?
Туфаннарның, бу халыкның
яшь җитәрлек түгелде.

Үлчәп кенә агызмады
илнең, халыкның канын.
Турап-турап, телеп-телеп
алды Туфаннар җанын.

Күз яшьләрен сөртеп була,
әгәр яшь кенә икән...
Күз яшьләре белән бергә
милләт җелеге кипкән.

Туфан калды, Туфан кайтты.
Ул бит йөздән бер генә.
Халык дисәм, минем күзгә
кайтмаганнар күренә.

Тарих арбалары авыр.
Аны бар бит тартасы.
Әле ярый Туфаннарның

таза булган аркасы.

Гомер буе изелү бит!
Шуңа чыдап кара әле.
Шуңа чыдап яшә әле.
Шагыйрь булып кал әле!

Узып китсә дә — йөрәктә.
Гомерең буе офтан.
Төяп торганнар. Күтәргән
шул бер үк шагыйрь Туфан.

И Бөек Хәсән Туфан!

1989

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

## БӘЙЛӘМЕ

IX

*Йөрәгеңне йөрәгемә куеп,*

йөрәгемне тыңлап кара бер...

*«БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР» җыентыгыннан*

***

Кеше күңелен тирән диңгез диләр,
диңгез төбе безгә сер түгел.
Җирләр, сулар, ай-кояшлар сыя,
бар нәрсәдән тирән ул күңел.

***

Көннәр оча,
оча, оча...
Ә мин көчсез.
Язам өч сүз,
сызам өч сүз,
калмый бер сүз.
Кеше көлә,
көлә, көлә...
— Ул бит көчсез!
Тукта! Бер сүз!
Яздым бер сүз,
сызмыйм бер сүз.
Минме көчсез?!

*«ӘМАНӘТ» китабыннан*

## Куәт

Көч-хәл белән пычкы сабын тарта
пычкы сабы хәтле ике малай.
Тамак кырып куәт биреп тора

тешен кысып туксан яшьлек бабай.

1970

## Гайбәтчегә

Әле генә син янымнан үттең,
гайбәт сатып үттең юлымнан.
Шатлыгымны бүген урлап киттең,
шуңа бераз йөрәк суынган.

Ишеттем дә синең гайбәтеңне,
ярар, дидем, бәла-казамы...
Ертык иләк кенә каплый алмас
кояшларын безнең заманның.

1968

## Шартлар әйбәт

Урамда буран.
Туза кар.
Иркенлек,
хозурлык.

Өйдә «буран».
Бүлмә тар.
Урын юк тузынырлык.

## ***

Күңел кылын уйнап чиртсәң,
сизмәс бу димә.
Сөеп уйна, сөеп шаяр,
шаярып сөймә.

## Без тыйнак

Чибәрләрнең бере, чибәре син,
кайчак күрсәм, каушыйм, ис китә.
...Чибәрләрне чибәр кеше сөйсен,
сөйкемлесе безгә бик җитә.

1967

## Яшьлек истәлеге

Күзләрендә сабыр караш,
ике якта ике улы.
...Шаян кызлардай уйнаклый
ике тездә ике толым.

1971

## Өлешең

Гел сагынып була, гел көтеп,
еллар түгел, яшьлек үтсә дә.
Тик килерлек кенә булсын ул,

йөрәк түзә ала күпкә дә.

Килмәсен дә белеп торасың,
яратасың һаман, түзәсең.
Олы бәхет белән зур кайгы
өлешеңдер инде, күрәсең.

## Үтеп барышлый

Туктап калдың әле нигә син?
Уйларымны бүлдең... көләсең.
...Туктаганмын икән үзем дә,
әллә нәрсә бар күк күзеңдә.
Юк,
игътибар итмә,
ялгыш бу.
Болай гына үтеп барыш бу.
1968

*«ГАМЬ» китабыннан*

***

Берәү әйтә: тормыш үзсүзле.
Берәү әйтә: кеше үзсүзле.
Мин үземчә аңлыйм бу сүзне:
үзсүзлегә каршы үзсүзле.
1969

## Кар

Көлә-көлә кар ява...

киселмәгән утынга,
ябылмаган түбәгә,
көрәлмәгән карга.

Көлә-көлә кар ява...

Эшләнмәгән эшләр бетмәс,
төкер!
Миңа гына түгел,
күршегә дә ява,
шөкер...

Елап түгел,
көлә-көлә ява!
1972
*«АВАЗЛАР» китабыннан*

***

Кара була көнең,
кара була күгең.
Ләкин аңа карап
дөнья кара түгел.
Үз-үзеңә генә

ямьсездер син бүген.

1976

***

Капкаларга типмә,
үткән гомер биктә.
Таш ыргытып ватсаң,
тәрәз яме үчәр.
Үткәнгә дип атсаң,
киләчәккә төшәр.
Үткән гомер биктә,
капкаларга типмә.

## Якын кешемә

Кайгыларың булса, миңа кил син,
җиңел булыр бергә үткәрү.
Шатлыкларым артса, сиңа барам,
берүземә кыен күтәрү.

1973

## Мәкерле кешегә

Бәя бирү сиңа кыен түгел,
биргән бәя булыр аз кебек:
күңелең иркен,
җәйге челләләрдә
боз сакларлык салкын баз кебек.

1973

*«ХЫЯЛ» китабыннан*

***

Йөзен сытып, тешен кысып йөри
әллә кемгә, әллә нигә үчле кеше.
Әллә нигә, әллә кемгә карап
көлеп йөри, балкып йөри көчле кеше.

1975

***

Йөз дусың юкта —
йөз сумың,
йөз сумың юкта —
йөз дусың
булуы кирәк икән.

Йөз дусың да,
йөз сумың да

булган чак сирәк икән.

1975

*«ИНАНУ» китабыннан*

***

Язмыш белән түгел,
ялгыш белән
очрашканбыз икән заяга.
Иләсләнеп китеп, бәхет дидек,
ялганламыйк,
җитте,
шаярма.

Йөрәкләргә түгел,
йөрәкләрдән
юллар ачык чыгып китәргә.
Инде синнән бәхет өмет итмим,
бәхетсезлек кенә китермә.

1969

***

Кимесә дә сиңа хөрмәтем,
мин яратам сине әле дә.
Үзгәрүең миңа кирәкми,
мин яратам шушы хәлеңдә.

Алып булмый торган ук булып
бәгыремә инде кадалган.
Күралмавым сине бик мөмкин,
тик битараф булып калалмам.

1985

***

Йөрәгеңне йөрәгемә куеп,
йөрәгемне тыңлап кара бер.
Бәлки, минем йөрәк урынында
инде күптән тоташ ярадыр.

1969

***

Аңламыйсың, дисең, мине бер дә.
Ә мине соң инде кем аңлар?
...Мин сандугач эзләп йөрим,
монда
корып беткән икән ул таллар.

1969

***

Син сабырсыз, дидең бугай миңа.
Син түземсез, дидең...
Түзмәдем.
Көнләшсеннәр безнең шушы кичтән
сөя белмәүчеләр үзләрен!

Кыска гына булды бу ярату.
Вакландык дип ләкин үкенмим.
Сөюләрне бөтен итәр өчен
сагынулары калыр бу көннең.

1969

***

Җитә кебек: гамәл төгәл,
фикер зирәк.
Тормыш әйтә: зирәккә дә
йөрәк кирәк.

1983

***

Бөтен кеше бүген шундый әйбәт,
бөтен кеше шундый мөлаем!..
Кичә әле мондый түгел иде,
Үзгәргәндер дөнья, мөгаен.

Дөнья хәтле дөнья үзгәралмас,
бүген, бәлки, үзем үзгәдер?
Дикъкать белән карап йөрим әле,
бөтен хикмәт минем күздәдер.

1985

## *«ТАҢНАР, КИЧӘЛӘР» китабыннан*

***

Тормыш музей түгел.
Карап кына
булмый үтеп китеп...
Картаерга кирәк әле анда,
башта үсеп җитеп.

1986

***

Тимер кебек каты кешеләр бар.
Күкрәк тә киң,
таза җилкә дә...
Йөрәгенә чиртсәң —
чыңлап тора,

чаң сугалармыни чиркәүдә.

1987

## *«ГОМЕРЕМ ДУЛКЫННАРЫ» китабыннан*

***

Берәү генә бу Җир барыбызга!
Тели икән әгәр җаныгыз,
хәлегездән килсә,
тотыгыз да
өлешегезне ярып алыгыз!

Ә калганы миңа.

## *«ӘЙТТЕ ШАГЫЙРЬ...» китабыннан*

***

Гел өскә таба ашкына.
Югары менә кеше.
Каядыр үрмәләп менү
әйтерсең бөтен эше.

Карыйсың, кабат түбәндә...
Ник түккән, дисең, көчен.
Биеклек кирәктер кайчак
егылып төшәр өчен.

1989

***

Даһи булдым диеп уйласа да,
курка ул алкышлардан.
Андыйлар да азат түгелдер шул
гениаль ялгышлардан.

1983

***

Орден алды, күкрәгенә такты
нәкъ йөрәк турысына.
Инде гомерлеккә батты
гражданлык бурычына.

1983

***

Кыскалары, озыннары,
чыкты уртачалары.
Шаккаталар: төгәл егет,
төгәл шагыйрь... чамалы!

1987

***

Язган ул кешелеклелек,
гаделлек турында да.
Өйрәткән сабыр, түземле,
намуслы булырга да.

Олылар өчен дә, дигән,
балалар өчен, дигән.
Ә чынлап укып карасаң —
тик үзе өчен икән.

1984

***

Яшәү булгач,
һич тә булмый калмас
аның белән бергә кыямәт.
Мәхәббәт тә шулай:
яратуның
күләгәсе кебек хыянәт.

***

Әй сүгәләр: ышаныч юк сиңа,
бөтен эшең беткән.
Тәмам чыгып җиттең бит син, диләр,
инде кешелектән.

Аңламасаң, диләр, ничек итеп
аңлатырга тагын?
Аңлыйм, ди ул, минем дә бар иде
кеше булган чагым.

1989

***

Бер күрәм дип,
үкенмәм дип,
көтәм каен кочаклап.
Бүтәннәрдә үткәндер дә,
миндә үтми ул чаклар.

Инде мин йөз кат терелеп,
йөз кабат үлгән идем.
И бу җанымның дәвасы,
и бетми торган чирем.

1978

***

Күгәрченнәр гөрләшүе кебек,
тыныч кына,
матур көй булып,
әкияттәге камчылары белән
уйный-уйный килде яшь болыт.

Шаян җырдай явып үтте яңгыр.
Җырлый-җырлый акты сулары.
Яңгыр суларына кушылды да
агып китте авыл юллары...

1970

# КИТАПЛАРГА КЕРМӘГӘН ӘСӘРЛӘР

# Х

*Өндә күрсәң төшкә кererлек*
*җирдә туган тиңсез музей бар.*
*Килер көнгә,*
*килер буынга*
тумасыннар андый музейлар.

## Бурыч

Гаҗәпләнеп шуны уйлап йөрим
(яңа килде уйга — томана!):
Тик бер генә сүзне хәтерләп тә
яшәп була икән дөньяда.
«Бурыч» дигән матур сүз бар икән,
матур итеп әгәр кулласаң.
Күзләреңне җүнләп ачып йөрсәң,
төшеп калган бәндә булмасаң.
Кеше бурычларын кеше белми,
кешенекен кеше түләми.
Һәркем үзе билгеләргә тиеш
бирер бурычлары күләмен.
Бурычлы мин, диеп йөри кеше,
бурычлы, ди, анам-атама.
Ул бурычлы икән кешеләргә,
ул бурычлы Илгә,
Ватанга.
Фикер туа:
бу — намуслы кеше,
тыйнак кеше,
уйлы-хәтерле;
җәмгыятькә безнең әнә шундый
аңлый торган кеше кадерле.
Ялгышы да күптер —
тормыш бит ул.
Эшләр һаман булмый уңышлы.

Ул үзе дә һаман әйтә тора:
бурычлы бит егет,
бурычлы...
«Бурычлы мин», — диләр гомер буе,
«зур бурычлы мин», — дип яшиләр.
Бурычларны түләр вакыт җиткәч,
бурычлылар бер сүз дәшмиләр.

1987

***

Калай кыза,
аңа җылы, рәхәт,
күптән шуны көткән ул, күрәсең.
Үзен-үзе белми,
шатлыгыннан
елап ята безнең өй түбәсе!

1978

***

Төнге ике, өстәл, кәгазь, кара.
Яз, дим үземә, нигә тукталдың?
Яз, язмау бит оят —
Тәрәзәдә уты янган чакта
Туфанның.
*С.Хәким*

Балкып тора Туфан тәрәзәсе,
бар кешегә кирәк уты аның.
Оят булмас
безнең шигърияттә
шигыре бар чакта Туфанның.

1984

## Тиңсез музей бар

Музейларның була төрлесе,
ә мондые сирәк,
бер генә.
«Заллары»ннан үтсәң,
Бухенвальд
хәтерләтер үзен гомергә.
Сукмакларда үсми үлән дә,
Тапталуы җиткән, күрәсең.
Бетмәс эзләр бу.
Изге урын дип ятып үбәрсең.
Канга сеңеп
туфрак, ташында
тарих туган,
меңнәр югалган.
Гади сукмак.
Һәрбер тузаны
мең кат изге бөек юллардан.
Рус солдатын,

чехын,
латышын
күкрәгеннән сыкрап үткәргән.
Әсир моңын,
үлем тавышын
батырларча ул да күтәргән.
Маңгаенда сырлар,
бүген дә
үлән япмый әле аларны.
Сукмак саклый,
саклый гомергә
әсир чакта алган яраны.
Кояш төшкән, аяз көн булса,
яңгыр яуса, аккан юлланып.
Хыялыннан йөз кат үткәреп
күңел кошын,
газиз улларын,
кеше яткан сасы баракта.
Тәмуг аша күргән бәхетне,
күңел күзе белән карап та.
Үлем көткән,
барак түбәсен —
соңгы кабат кайчан күргәндер?
Тормыш көткән,
сөйгән ул аны.
— Яшәү матур, — диеп үлгәндер.

Иске барак.
Күптән хуҗасыз.
Колагыңны куеп тыңласаң,
сыкрый әле,
һаман көрсенә.
Якын килеп дәшсәң,
ымласаң,
дүрт стена очып дүрт якка,
ташып чыгар кебек әсирләр.
Кочып алып хәлсез күкрәккә:
— Саумы, якташ, — диеп дәшерләр.
Эх!
Ачасы иде каерып,
йолкыйсы иде кабер ташларын.
Кайтсын иде илгә туганнар,
биек тотып горур башларын.

Өчәү алар рәткә куелган.
Күз күрергә тыйнак кебекләр.
Учагында шушы мичләрнең
кабер тапты күпме егетләр.
Юк ялкыны,
инде көлен дә
еллар алган җыеп хөрмәтләп.
Якмаганнар утын,
ялгыш та
салмаганнар күмер көрәкләп.
Ә ялкыны ерак күренгән.
Тик янмаган теләк, хыяллар, —
шушы нурны,
шушы җылыны
сабыйлар да бүген тоялар.

Тимер арба —
такси тәмугка.
Җәһәннәмгә рельс тимердән.
Йөкче, мескен, үзе кочегар,
ул меңенче булып сикергән.
Тәүлек буе шушы арбалар
кызган мичкә кеше ташыган.
Аждаһаның җиргә бурычы —
меңәр кеше һәрбер ташыннан.
Шаһит булып, җанга боз салып
рельсларда тора арбалар.
Мичләр тора.
Килеп күз салсаң,
чатнап куя иске яралар.
Өндә күрсәң төшкә керерлек
җирдә туган тиңсез музей бар.

Килер көнгә,
килер буынга
тумасыннар андый музейлар.

1966 ел, 9 май

## Зифа килен

*(Поэма)*

Кайсы аның алдан туган —
кешеме, мәхәббәтме?
Тудыра, саклый, яшәтә
кешене мәхәббәте.

Сөя белгәннәр таяна
мәхәббәт кодрәтенә.
Кереп-чыгып йөреп булмый
андыйлар йөрәгенә.

Мәхәббәтенә сыена
тормышның чатларында.
Яратуы бәхетле итә
бәхетсез чакларында.

Берәүгә дә ансат түгел
тормышка чыдаулары.
Аралый, ләкин аямый
мәхәббәт сынаулары.

Сүндерә тормыш, сындыра
җаныңны сыный-сыный.
Мәхәббәтен җуйган җаннар
көн итә елый-елый.

Мәхәббәте исән булса,
кеше башы иелми.
Гомергә җитәрлек сөю
һәркемгә дә бирелми.

Бар икән андый ярату —
сүнми-сүрелми торган.
Йөрәк ургылып янса да,
күзгә күренми торган.

Яна бердәнбер мәхәббәт.

Бара гомер-гомергә.
Зар булып яши сөйгәнен
гомергә бер күрергә.

Белә күрмәячәген дә.
Күңелдә тик, хәтердә.
Тел бармас андый кешегә,
оныт, диеп әйтергә.

Әйтсәң дә сине тыңламас.
Үз йөрәге бар аның.
Табибы юк, дәвасы юк
йөрәктәге яраның.

Мәңгелек ут кебек яна.
Гомере буе яна.
Яшәтә шушы мәхәббәт,
яшәтә шушы яра!

**1**

Фатирга керүчеләр без.
Килмәдек кунак булып.
Оялып кына киләбез,
тартынып, тыйнак булып.

Ачабыз йортның капкасын,
үтәбез ишекләргә.
...Әле бит үзен күрмәгән,
тавышын ишетмәгән.

Кемнәр чыгып каршы алыр
безне — өч мосафирны?
Андый чакта сайламыйлар
хуҗаны һәм фатирны.

Килеп чыкты хуҗа апа
тулган ай яктысыдай.
Кемнәрнең җанын эретмәс
якты йөз, якты чырай!

Кигән күлмәге — балитәк.
Ак яулык — башларында.
Ай-кояшның нуры бардыр
җылы карашларында.

Аллы-гөлле алъяпкычы
җемелдәп, балкып тора.
Эчкерсез елмаюлары
күңелне тартып тора.

Елмаюы күчте безгә,
югалды тартынулар.
Әйтерсең безнең күңелгә
бөркелде якты нурлар.

Күрештек, танышып киттек,
чишелде телләребез.
Тагын да яктырып китте
бу җәйге көннәребез.

Таныштырды үзе белән:
— Булам Зифа апагыз.
Оялмагыз, җайлы булса,
әби диеп атагыз.

Әби булмый, кем буласың?
Күптән яшенә җиткән.
Җиденче дистәм дә тула,
үтәсе гомер үткән.

Исән булгач яшим әле.
Ялгызын ялгыз инде.
Гомер буе берүзем мин —
өлешем, язмыш инде.

Гел миңа керә кунарга
колхозга килгән кеше.
Зифа килен, диләр миңа
авылда бөтенесе.

**2**

Юдык бит-кулларыбызны
чишмә сулары белән.
Акты юлларның тузаны
ару-талуы белән.

Зифа апаның әйрәнен
эчтек чүмеч тотырып,
ишегалды чирәмендә
аяк сузып утырып.

Яшәүнең артты ямьнәре,
яшәреп китте йөрәк.
Яшәү ямен тояр өчен
Зифа апалар кирәк.

Чистартып алды күңелне
бу чирәм, шушы сулар.
Шифалы дару шикелле
шушындый очрашулар.

Шушы җылы карашларны
мин инде күпме тойдым!
Зифа апаны күргәч тә
мин шуны уйлап куйдым:

«Исәнмесез!» — дип керәләр.
Китәләр: «Сау булыгыз!»
Каршы ала, озатып кала:
«Уңай булсын юлыгыз».

Гомерендә бу сүзләрне
инде күпме ишеткән...
Күпме кеше кереп чыккан
шушы ялгыз ишектән...

Гомергә бер кат күрәсең,
туган-тумача түгел.
Кайлардан килә икән бу
олы җан, олы күңел?

Күңелләре берме әллә
толларның, ялгызларның?
Сугышлардан ятим калган
хатыннарның, кызларның?

Сизелә толлар чалымы
картайгач та, хәзер дә.
...Зифа апаны күрүгә,

әни төште хәтергә...

Шул хакта торам уйланып...
Һәм уйлап куйдым тагын:
ни өчен Зифа килен дип
атыйлар икән аны?

**3**

Ул кичне озак утырдык.
Тынмады самавыр да.
Беребез дә уйламады
сәгатькә карарга да.

Зифа апаның сыеннан
сыйландык, оялмадык.
Ашаган саен ризыгын
без ашап туялмадык.

Сөенде Зифа апа да,
аңа да рәхәт иде.
— Бик гади кеше икәнсез,
күңелем булды,— диде.

Сөйләде чәй арасында
тормышын, язмышларын.
Без тоеп утырдык аның
гомерлек сагышларын...

...Яраткан алар бер-берен,
эчкерсез сөю булган.
Ике яшь йөрәк мәхәббәт,
кайнар хис белән тулган.

Саф булган яратулары,
сөешеп туймаганнар.
Гомергә бергә булырга
дип кенә уйлаганнар.

Тик сугыш керә арага
аерылу, сагыш булып,
Зифаларның язмышында
коточкыч ялгыш булып.

Гариф та инде фронтта.
Ышанулары читен.
Кайтмаса әгәр Гарифҗан,
яшәрсең ничек итеп?!

Зифаның исенә төшә
Гарифның әйтүләре.
Риза булмады шул аңа
әнисе-әтиләре.

«Миңа кияүгә чык», — диде
китәргә бер ай кала.
Зифа соң каршы киләме?!
Бик риза иде аңа.

Әнисе каршы, әтисе:
«Сугышта кем өйләнә?!
Исән йөреп кайт, Гарифҗан,
хәзер юкны сөйләмә!»

Дәшмәде бүтән. Моңайды.
Аңлады. Сабыр итте.
Мәхәббәтләрен язмышка
тапшырып Гариф китте.

Үзенә урын табалмый.
Зифа гел җәфалана.
Үпкәләп киткәндер кебек
тоела Гариф аңа.

«Тыңларга иде Гарифны.
Китте күңеле тулып.
Кәтәсе иде сугыштан
хәләл хатыны булып.

Утларга керергә китте.
Чыгармы исән килеш?
Мин аңа исән калырга
ярдәм итәргә тиеш.

Сүрелмәс мәхәббәтләрнең
бүген бит кирәге дә!
Булырга тиеш мин аның
җанында, йөрәгендә!»

Исенә төште Зифаның
китаптан укыганнар:
кемнәрдер сөйгәне белән
төрмәгә утырганнар.

Юлларга чыккан хатыннар
кайтмаска, югалырга.
Ирләре көткән Себердә,
үлеме — юлларында.

Ул заман хатыннарыннан
кайсы җире ким аның?
Аларның мәхәббәтенә
мәхәббәте тиң аның!

Борчылу артты көннән-көн.
Тынычлык тапмады ул.
Бер генә кич тә йокларга
еламый ятмады ул.

Укыды Гариф хатларын
төн буе, кабат-кабат.
Үз-үзен тиргәп елады
көнбатышларга карап.

Ә беркөнне арды елап,
сөртте ул күз яшьләрен.
Елмаеп йөрде көн буе,
беркемгә сүз дәшмәде.

Төне буе язды бер хат.
Таң аткач кына ятты.
Менә ул төндә Зифаның
Гарифка язган хаты:

«Бу хакта уйлап торырга
вакыт та юктыр анда.
Шулай булса да, Гарифҗан,
син мине дөрес аңла.

Эчкерсез язам, ихластан,
йөрәк кушканны тыңлап.
Саташкан бу диеп уйлама,
мин язам уйлап, чынлап.

Буталган булган уйларым
син киткән минутларда.
Бүген менә синең белән
керер идем утларга.

Ник мине хатының итеп
калдырып китмәдең син?
Гомергә, мәңгелеккә дип,
юлдашың итмәдең син?

Үзем гаепле. Ул чакта
мин уйлап өлгермәдем.
Алып кайт мине бүген, дип,
артыңнан йөгермәдем.

Син киткәч кенә аңладым.
Тоймаган бергә чакта.
Бу дөньяда ничек кенә,
кайда гына булсак та,

син генә минем язмышым —
бүгенем, киләчәгем.
Синең белән яшим менә,
күрермен күрәчәгем.

Икебез дә исән әле.
Хак безнең сөюебез.
Бүгеннән үк уртак булсын
бар янып-көюебез.

Карарым нык. Күчеп киләм
сезнең өйгә бүгеннән.
Мин синең хатының инде,
Гарифҗан, шушы көннән.

Исән калсаң да, үлсәң дә...
(Ходаем, язма гына!)
бергә барырбыз, Гарифҗан,
гомернең азагына.

Алдамас минем йөрәгем,
без бергә инде күптән.
Сугышлар бетәр, кайтырсың,
мин сине өйдә көтәм.

Гаризаңны язып җибәр.
Командир кулын куйсын.
Безнең кавышуыбызның
шаһиты сөю булсын!»

**4**

Авыл Советы рәисе
бер елмая, бер көлә.
Йөзеннән әле борчылу,
әле шатлык бөркелә.

Акыллы кеше, җор кеше.
Дөньяны шактый күргән.
Әле теге сугыштан ук

аяксыз кайтып кергән.

Аптыраган Бәдри абзый.
Курыкмый, шүрләми ул.
Тик мондый хәлне гомердә
белгәне, күргәне юк.

Кирәкми аңа закон да,
кирәкми аңа вәгазь.
Укый да тагын елмая:
алдында бер уч кәгазь.

Менә Гариф гаризасы...
Командир хаты ята...
Шаһит итеп санагыз, дип,
тулы бер взвод яза.

Елмая: «Бетми ул тормыш
сөю-мәхәббәт барда.
Килен — монда, кияү — анда,
туйны ясыйбыз кайда?

Үгетләүнең файдасы юк.
Артык монда киңәшләр.
Гомерегез генә булсын,
и балалар, и яшьләр...»

**5**

Авыл Советыннан Зифа
никах кәгазе алган.
Шул ук көнне Гарифына
озын хат язып салган.

«Көтәбез,— дигән,— сау булсаң,
көтәргә генә әзер.
Әниең мине, Гарифҗан,
кызым дип йөртә хәзер».

Берәүләр көлгән Зифадан.
Берәүләр мактаганнар.
Шул вакыттан Зифа килен
дип аны атаганнар.

Зифа килен, дигән картлар,
яратып, матур итеп.
Зифа килен, дигән яшьләр,
сокланып, батыр итеп.

Ә Зифа... Зифа нишләсен?
Бер елмайган, бер көлгән.
Бик тату яшәп киткәннәр
Гариф әнисе белән.

Ә сугыш әле тынмаган,
өченче елы киткән.
...Көтмәгәндә, кинәт кенә
Гарифҗан кайтып җиткән.

Кайтмаган Гариф. Гарифның
шәүләсе генә кайткан.
Кайтарганнар госпитальдән.
Кайтып түшәккә яткан.

Бер аягы, бер кулы юк.
Сызлана ярасы да.
Әз генә дә нур калмаган

күзләре карашында.

Әйткән озата килүче:
«Гомере кыска аның.
Шуңа кайтардык. Өендә,
түрендә бирсен җанын».

Ышанмаган моңа Зифа.
Ансатмы ышанырга?
...Гарифның күзе түшәмдә...
Хәле юк кымшанырга.

Уйлый Зифа:
Тере бит ул!
Бәлки, ул яшәр әле.
Килеп ят янына, диеп,
бәлки, ул дәшәр әле.

Бирнә сандыгын ача да
чыгара бөтен барын.
Элә тәрәз пәрдәләрен,
элә кашагаларын.

Чәчәкле тышлар кидерә
(яраклык кемнәргә дә)
бер тапкыр да баш тимәгән
өр-яңа мендәрләргә.

Чиккән сөлгеләрне элә,
җәя ашъяулыкларын.
Килен бит ул: өеп куя
пешкән ашамлыкларын.

...Мендәргә куйган башыннан
сыңар кул сыйпап ала.
...Сүрелеп барган учакта
соңгы күмерләр яна.

**6**

Бер атнадан җирләгәннәр
солдат киеме белән.
Әсма апа торып калган
Зифа килене белән.

Гомерлек сагыш утырган
Зифаның бәгыренә.
Инде ул карап елаган
Гарифның каберенә:

«Язмышым болай булыр дип
һич кенә уйламадым.
Сөйгәнең булсам да синең,
хатының булалмадым.

Язмыш үзенчә хәл итә,
безгә карамый икән.
Артык бәхетле булырга
безгә ярамый икән.

Әниең белән калам мин
тугры килен булып.
Янда — кабереӊ. Күңелдә —
яшәрсең ирем булып».

**7**

Таң ата. Уйланып ятам.
Таңнарда уйланыла...
Зифа апа сөйләгәннәр
чуала уйларымда.

Гарифҗанның әнисе дә
гүрләрдә инде күптән.
Зифа апа яшьлеге дә
бик күптән үтеп киткән.

Килешкән язмышы белән.
Дуслар-ярлар тапмаган.
Ялгыз булган. Йөрәгендә
Гарифҗанын саклаган.

Кырык елда бу дөньялар
кырыкка төрләнгәндер.
Зифа апа да гел болай
елмаеп йөрмәгәндер.

Җитәрлек булган нужасы,
тормышның азаплары.
Әрнетмимени күңелне
ялгызлык газаплары?

Кемнедер яры итүне
китерми уйларына
саклый алган мәхәббәтен
гомере буйларына.

Бер генә сөйгән. Башканы
уйламаган, күрмәгән.
Гариф үлгән. Ләкин Гариф
Зифа өчен — үлмәгән.

Ялгызлар... толлар буыны...
Язмышы әниләрнең...
Без гомер буе тоябыз
аларның әрнегәнен.

Берни дә сорамаганнар,
бернәрсә алмаганнар.
Гомер итүне, вакламый,
зур итеп аңлаганнар.

Сугыштан соңгы елларның
ялгызлары, толлары...
Фәрештәләр, — солдатларның
тугры хатыннары!

**8**

Сайраша кошлар бакчада
һәркайсы үз көенә.
Таң атып килә, яктыра
Зифа апа өендә.

Мин карап ятам сокланып.
Таныйм. Танырга тиеш!
Кырык ел буе сакланган
ул үзгәрмәгән килеш.

Бала чагыма кайттым да,
мин өйдә ятам кебек.
Безнең өй дә шундый иде

моннан кырык ел элек.

Гарифҗан кайткан чакта да
бу өй нәкъ шундый булган.
Һәрбер нәрсә үткән монда
Зифа килен кулыннан.

Ак пәрдә тәрәзәләрдә.
Элгәнме яңаларын?
Чиккән сөлгеләре бизи
тәрәзә араларын.

Әйтерсең лә болыннарда
чәчәктән ясаганнар:
тәрәз өсләрен ураган
чәчәкле кашагалар.

Өелеп тора мендәрләр
алсу тышлары белән.
Ачылмаган чаршаулары
җәе-кышлары белән.

Күзләрең камашыр кебек
миченең аклыгына.
Бу өйгә ямь кереп калган
күңелнең сафлыгыннан.

Бүген дә Зифа апаның
мендәрләре тузмаган.
Аның гомере шушы өйдә,
аның гомере узмаган.

Тузмаган аның туйларда
киясе киемнәре.
Тузмаган кашагалары...
Ул һаман килен әле...

***

Һәр кешенең үз хисләре.
Һәркемнең үзгә күңел.
Мәхәббәтләрнең сагышы,
моңнары уртак түгел.

Һәр кешенең яратуы,
яшәве йөрәгенчә.
Бер мәхәббәт көлгә кала,
берсе җырларга күчә.

Мәхәббәтсез кешеләр юк.
Мәхәббәтсез тумыйлар.
Мәхәббәт була торып та
гел бәхетле булмыйлар.

Мәхәббәт тулы күңелнең
ятлар белми халәтен.
...Бәхетлеме, бәхетсезме
Зифаның мәхәббәте?

Кемнәр әйтсен? Беркем белми.
Зифа да белми аны.
Бүтән бәхет таба алмый
андый кешенең җаны.

Бәхетлеме, бәхетсезме —
Зифалар шулай яна.
Изге җаннар яшәп китә,
олы мәхәббәт кала!

1987

# Эчтәлек

**«Әманәт» китабыннан**
*(1963 —1971)*

Әманәт ...
Ике сүз ...
Кырларым күмелгән рәшәгә ...
Эзләмәгез әллә кайлардан ...
Туу ...
Бәхеттер ...
Авылым ...
Таң алдыннан агачларның шавы ...
Өлкәннәр ...
Иске ярда ...
Имән ...
Иргә чыкмый калган апалар ...
«Карга оялары...» ...
Кыйшык йорт тәрәзәсе ...
Кызлар ташу карый ...
Мәҗнүн ...
Җәйге төн ...
Имәннәр әле көтә ...
Әйт әле ...
Кадерлем ...
Саубуллашу ...
Көтәм әле ...
Кама ярларыннан эзлим сине ...
Көзге күктә болыт бар... ...
Мәхәббәт ...
Тамчылар ...
Син кирәк ...
Әйтегез, кешеләр! ...
«И чабабыз...» ...
Заман көтә ...
Үземә ...
Кар яуганда ...
Усаклар ...
Энеләр ...
Замана ...
«Кемнәрне еллар...» ...
Язылыз хатлар ...
Әтисезләр болар димәгез ...
Чит илдән хат ...
Ирләр ...
Кайнар җилләр ...
Утлар ...

**«Гамь» китабыннан**
*(1972 —1974)*

Көрәш ...
Кырым сукмаклары ...
Сабан туйлары икән... ...
Атлар көтте авыл малайлары ...
Юлда үскән арыш ...
Күзгә карагыз ...
Без синеке инде ...
Граф паркы ...
Араукария ...
Игенче ...
«Чәчәкләрдән күп нәрсә...» ...
«Башак шавы...» ...
Кара диңгез ...
Яулык болгаулары ...

Кибәнче карт ...
Кар сулары ...
Озату ...
Давыл ...
Давылдан соң ...
Саллар ...
Бозлар ...
«Үрсәләнеп...» ...
Тантаналы сагыш ...
«Кабатлама, кат-кат...» ...
Язмыш ...
Чамалап үт ...
Йөрәгең яна торсын ...
Миләшле йорт ...
Югалткан, тапкан чагым ...
Үзәннәрдә калды томаннар ...
«Бу юллардан инде...» ...

**«Авазлар» китабыннан**
*(1970 —1979)*

Шигырь ...
Һәйкәлләр ...
Картлар ...
«Кешеләрнең барын...» ...
Авылдашым ...
Әкиятче ...
Диңгездә таң ...
Кар шыгырдый... ...
Апрель ...
Инвалидлар ...
Урман ...
Соңгы чабатачы ...
«Шота Руставели» ...
Яшел килеш яфрак коела ...
«Зар ишетсәм...» ...
Арта бара ...
Корылык ...
Бер эздән ...
Сыерчык бураны ...
Эскәмиядәге карт ...
Юкәләр ...
Борчак ашы ...
Карурман ...
Авыл урыны ...
«Шөкер дөньяларга...» ...
Атыла йолдыз ...
Таңнарым ...
Күзләр җитте ...
«Пыскып утырасың...» ...
Тормыш чире ...
«Нинди генә булсын...» ...
«Җиңә алмый ирне...» ...
Күңел ...
Әйтер иде кеше ...
Әбием ...

**«Хыял» китабыннан**
*(1969 —1984)*

Офыкларга карап ...
Яңа елга ...
«Су буйлары безнең...» ...
Быел яз... ...
Яза халык ...
Мәчет мәйданы ...
Пошилар ...
Сагыш ...
«Яшь белән дә...» ...
Күгәрчен үлеме ...
Язмышка ...
Авырганда ...
Хәбәр ...
Сиреньнәр ...
«— Саклан...» ...

Ялгызлар ...
Трамвайда хат укучы кыз ...
«Син кош булып...» ...
Хыял ...
Уел ...

**«Инану» китабыннан**
*(1968 —1985)*

Авыл, чишмә, инеш... ...
Шимбә өмәсе ...
Шәһәргә ...
Шул бер ишек ...
Якташларга хат ...
Үз йортын сала кеше ...
«Инде кич...» ...
Дустыма, яшьтәшемә ...
Көзге яз ...
Алмалы ел ...
Карлар ...
Яраннар ...
Мәгънә киңәйгәндә ...
Яшел сагыш ...
Йөрәк турында ...
«Мин сиңа чәчәк...» ...
«Хискә дә бай тормыш...» ...
«Кал кошларың белән...» ...
Борынгы җыр ...
«Көзләр җитәләр...» ...
«Җырга-моңга мохтаҗ...» ...
Декабристлар хатыннары ...
Сагыну ...
Болыт ...
«Ни гомер күрмичә...» ...
«Аның белән бөтен...» ...
Көчсезлегең белән ...
Ләйлә ...
Ышану ...
Уен ...
«Әле кошлар китә...» ...
Гөлләрең шау чәчәктә ...
«Ник сабырсыз...» ...
«Бәйрәм итә берәү...» ...
«Сөйләшәләр кайчак...» ...
Саҗидә Сөләймановны юксыну
...
Роботлар турында гына ...
Парадокс ...
«Дөреслектән узып...» ...
Бүген төнлә... ...
Каен җаны ...
Туфан белән сөйләшү ...

**«Таңнар, кичәләр» китабыннан** *(1977 —1987)*

«Җырлый-җырлый...» ...
Кифая ...
«Көннәре Кояшлы...» ...
Кыңгыраулы яшел гармун моңы
...
Сокланам ...
Бишек җыры ...
Туган йортта ...
Әни ...
Ветераннар күрсәм ...
«Җылы мамык булып...» ...
Рәхмәт, әби! ...
Тора дөнья ...
«Бер ялгышсыз гомер...» ...
Улымның анасына ...
«Гомергә киткән...» ...
Пристаньнар ...
Син төшләргә алай кермә бүтән...
...

Төшләргә кереп йөдәтә... ...
Кеше ...
Карап торам җирдән... ...
Глобус ...
Малах курганы ...
Кара болыт ...
Хәзергә исән-сау
Без сугышта һаман ...
Тарала картлар җомгадан ...
«Уйланып йөри...» ...
Дөнья ...
«И акыллы булып...» ...
Хөкемдар ...
«Юл куймады язмыш...» ...
Чишмәләр ага тора... ...
Көньяк аты ...
Бер күкләргә менеп... ...

**«Гомерем дулкыннары» китабыннан** *(1966 —1988)*

Сандугачлы өч таң
«Агым сулар ага...» ...
Илһам Шакировның юбилей кон-
церты ...
Сары моң ...
Зираттан чыккач ...
Исемнәр хакында ...
Күке тавышын ишеткәч ...
«Мин йокыдан...» ...
Урман күгәрчене ...
Халыкара кыргый хайваннар ...
И Табигать ...
«Үзәкләрең өзелеп...» ...
Бер тау янында ...
Абага чәчәге ...
Кәкре нарат ...
Каф тавы ...
Үзебез турында ...
Сөяркәләр ...
Балдыз йоклый ...
Җылы яктан язган хат ...
Орган залында ...
Иман ...
«Яратуның күзе...» ...
Риза түгел ...
Есенинны уйлап ...
«Мин генәме әллә...» ...
Коммунистлар баш төзәтә ...
«Минем шатлык...» ...
Гаеп ...
Бер нөсхәдә ...
Ашкын ат ...
«Кайнар, диләр...» ...
Бигрәк тә куркам ...
«Моңаеп кына...» ...
Бер ноктада ...

**«Әйтте шагыйрь...» китабыннан** *(1970 —1993)*

Әле ярый ...
«Мин икенче кабат...» ...
«Хыялларда туа...» ...
Безнең моңнар ...
«Безнең инде азмы...» ...
Алай димәгез ...
Борынгы башкорт җыры ...
Таныш кеше ...
Намус ...
Хатын-кыз мәсьәләсе ...
Әйбәт кеше ...
Һәвәскәр астроном ...
Көтеп алган яз ...
«Яратырга акыл кирәкмени...»

...
Син ...
Гомер буе ...
Син яратсаң... ...
Күзләреңнән күкләр карый ...
Ике кеше ...
Чәчәк яши ...
Мин танымыйм сезне ...
Казлар ...
Чыпчык ...
«Очрашты сабакташлар...» ...
Балык балалары ...
Бердәнберең ...
Кабердәге чәчәкләр ...
Кемнәр дәшә безгә ...
«Җиттеләр китәсе...» ...
Картлар йорты. Сентябрь ...
Һаман шул җир ...
Кая таба... ...
Килгән иде болыт ...
Адашкан поши баласы ...
Көзге зират ...
И Тәңре ...
Арык ...
Безнеке ...
«Әллә нигә күңел...» ...
Егерме ике күл ...
Җан тарта ...
Арал ...
Мәләкәс буе ...
Җәй ...
Сары чәчәк ...
Шишкин наратлары ...
Тетрәгән җир ...
Ирләр елый ...
Каргыш ...
Гомерлек сорау ...
1991 ел язы ...
Уй ...
Ямьсез көннәр ...
Кайтабыз... ...
Татар көрәше ...
«Мөстәкыйль һәм үзебезгә...»
...
Гомерлек томан ...
Уйлап баксаң... ...
«Бу күкләрне нигә...» ...
Аяк тая ...
Гафу итсен әни ...
Безнең әкиятләр ...
Ленин мемориалы ...
Бетон болгата торган машина
...
Шипка ...
Уяндык та... ...
Киләчәкне уйлап ...
Шифа ...
Дога ...
Юлда ...
Яшик... ...
Яшел байрак ...
Кайтыгыз! ...
«Диңгезләргә күңел...» ...
Татар җыры ...
Ваклык турында ...
Шүрәле ...
Күптәнге хакыйкать ...
Тагын туган як турында ...
Кабер ташы ...
Изге иман ...
Бүген Болгарда ...
Акылдан язган рәссамнар күргәз-
мәсе ...
«Икесе дә әйбер кебек...» ...

«Көннәр туа...» ...
Шул ук Туфан ...

**Кыска шигырьләр бәйләме**

«Кеше күңелен тирән...» ...
«Көннәр оча...» ...
Куәт ...
Гайбәтчегә ...
Шартлар әйбәт ...
«Күңел кылын уйнап...» ...
Без тыйнак ...
Яшьлек истәлеге ...
Өлешең ...
Үтеп барышлый ...
«Берәү әйтә...» ...
Кар ...
«Кара була көнең...» ...
«Капкаларга типмә...» ...
Якын кешемә ...
Мәкерле кешегә ...
«Йөзен сытып...» ...
«Йөз дусың юкта...» ...
«Язмыш белән түгел...» ...
«Кимесә дә сиңа...» ...
«Йөрәгеңне йөрәгемә...» ...
«Аңламыйсың, дисең...» ...
«Син сабырсыз...» ...
«Җитә кебек...» ...
«Бөтен кеше бүген...» ...
«Тормыш музей...» ...
«Тимер кебек каты...» ...
«Берәү генә...» ...
«Гел өскә таба...» ...
«Даһи булдым...» ...
«Орден алды...» ...
«Кыскалары...» ...
«Язган ул...» ...
«Яшәү булгач...» ...
«Әй сүгәләр...» ...
«Бер күрәм дип...» ...
«Күгәрченнәр гөрләшүе...» ...

**Китапларга кермәгән әсәрләр**

Бурыч ...534
«Калай кыза...» ...
«Балкып тора...» ...
Тиңсез музей бар ...
Зифа килен ...

Литературно-художественное издание

***Сибгатуллин*** *Кадир*
***(Сибгатуллин*** *Минкадир Идиятович)*

**НА ОДНОЙ ТОЧКЕ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Сибгатуллин*** *Кадыйр*
***(Сибгатуллин*** *Минкадыйр Һидиятулла улы)*

**БЕР НОКТАДА**

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Т.В.Пашагина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.03.2007. Форматы $70 \times 108\,^{1}/_{32}$.

Офсет кәгазе. «Arial» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 24,50. Шартлы буяу-оттиск 24,85. Нәшер-хисап табагы 22,63. Тиражы 2000 экз.
Заказ С-271.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru   e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.